**БУ САНДА**

Баш редактор сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

ТЕЛ БЕЛЕМЕ

*Бәширова И.Б.* XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар сәнгатьле прозасында хикәяләү стильләре . . . . . . . . . . . . . . . . 9

*Миңнуллин Б.К.* Массакүләм мәгълүмат чарасы буларак газета теле һәм публицистик стиль . . . . . . . . . . . . . . . . 15

*Нәбиуллина Г.Ә.* Татар тел гыйлемендә экспрессив синтаксик төзелмәләрне өйрәнү мәсьәләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22

*Рамазанова Д.Б.* Татар-монгол уртак лексикасы турында . . . . . 26

*Гайнетдинова Г.Р.* Төрки-татар язма истәлекләре лексикасын өйрәнү тарихыннан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

*Миңнегулов Х.Й.* Абай һәм татар әдәбияты . . . . . . . . . . . . . . 41

*Хасавнех А.А.* Татар шәехе Мөхәммәд Закир әл-Чистави турында яңа мәгълүматлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47

*Нигъмәти И.* Чорлар чатындагы үзгәрешләргә кабат тукталып *(Г. Гыйльманов һәм Ф. Бәйрәмова әсәрләренә күзәтү)* . . . . . 52

*Әхмәтҗанов М.И.* С.-Петербургның татар зиратындагы ташбилге текстлары (1843–1986) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60

ХАЛЫК ИҖАТЫ

*Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Татар телле «Каһарман Катил» дастанының килеп чыгышы һәм таралышына карата . . . . . . 69

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ

*Беккин Р.И.* 1917–1991 елларда Петроград-Ленинград мөселман татарлары тормышы (*шәхси фотоархивлар турында уйланулар*) . . . . . . . . . . . . . . 76

*Мәхмүтова А.Х.* Акчуриннар нәселе хатын-кызлары . . . . . . . 87

ИҖТИМАГЫЙ ФИКЕР

*Исмәгыйлева К.К.* Социаль челтәрләрне тәрбия максатларында файдалану . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .104

МИЛЛИ МӘГАРИФ

*Яруллина Л.И., Яруллина Э.Р.* Р.З. Хәйдәрова эшчәнлегендә рус телле балаларга татар телен өйрәтү проблемалары . . . . . . . .113

ГАБДУЛЛА КАРИЕВКӘ – 130

*Арсланов М.Г.* Габдулла Кариев – «Татар театрының атасы» . . 120

## ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ

*Кадыйрова Э.Х.* Тынгысыз галимә . . . . . . . . . . . . . . . . 132

## ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР ЭЗЕННӘН

*Булатова М.Р.* Татар теленең яүштә-чат сөйләше (*2015 елда Томск өлкәсенә булган экспедиция материаллары буенча*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137

## СӘНГАТЬ

*Солтанова Р.Р.* Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей тыюлыгындагы «Болгар цивилизациясе. Меңьеллыкка сузылган юл» инсталляциясе . . . . . . . . . . . . . . . . . 151

*Улемнова О.Л.* Рәссам Тавил Хаҗиәхмәтовның иҗат юлы (*тууына 80 ел тулу уңаеннан*) . . . . . . . . . . . . . . . . . 155

*Шкляева Л.М.* Казан сөлгесе – тимер һәм агачтан (*рәссам Ринат Әхмәтов иҗатына күзәтү*) . . . . . . . . . . . . 160

*Галимова Э.М.* Таҗи Гыйззәт драмаларының музыкаль бизәлеш үзенчәлекләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162

## ЯҢА КИТАПЛАР

Әдәби мирасыбыз тагын йөз елга якынайды («Татар әдәбияты тарихы»ның 3 нче томы басылып чыгу уңае белән) . . . . . . . 166

Валиева Л.Г. Каузальность в татарском литературном языке (Казань: ИЯЛИ, 2015. 174 с.) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172

Яруллина Л.И. Татар телендә сузык һәм тартык авазларның (вокализм, консонантизм) язуда бирелеше: XIX гасыр һәм XX гасырның I чиреге (Казан, 2014. 335 б.) . . . . . . . . . . 173

## ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН

**В НОМЕРЕ**

От главного редактора . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Баширова И.Б.* Повествовательные стили в татарской художественной прозе конца XIX – начала XX века . . . . . . . . . . 9
*Миннуллин Б.К.* Публицистический стиль и язык газет как средства массовой информации . . . . . . . . . . . . . . . 15
*Набиуллина Г.А.* Вопрос изучения экспрессивных синтаксических конструкций в татарском языкознании . . . . . . 22
*Рамазанова Д.Б.* Об общей тюрко-монгольской лексике . . . . . 26
*Гайнутдинова Г.Р.* Из истории изучения лексики тюрко-татарских письменных источников . . . . . . . . . . . . . . 37

ЛИТЕРАТУРОВЕДЕНИЕ

*Миннегулов Х.Ю.* Абай и татарская литература . . . . . . . . . . 41
*Хасавнех А.А.* Новые сведения о татарском шейхе Мухаммаде Закире аль-Чистави . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
*Нигмати И.* На перекрестке эпох *(обзор произведений Г. Гильманова и Ф. Байрамовой)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
*Ахметзянов М.И.* Тексты эпитафий татарского кладбища С.-Петербурга (1843–1986) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60

НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Мухаметзянова Л.Х.* О возникновении и распространении дастана «Кахарман Катил» на татарском языке . . . . . . . . 69

СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Беккин Р.И.* Повседневная жизнь татаро-мусульманской общины советского Петрограда-Ленинграда (*размышления над частными фотоархивами*) . . . . . . . . . . . . 76
*Махмутова А.Х.* Женщины рода Акчуриных . . . . . . . . . . 87

СОЦИОЛОГИЧЕСКАЯ МЫСЛЬ

*Исмагилова К.К.* Использование социальных сетей в воспитательных целях . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104

НАЦИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ

*Яруллина Л.И., Яруллина Э.Р.* Проблемы обучения русскоязычных детей татарскому языку в педагогической деятельности Р.З. Хайдаровой . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 113

ГАБДУЛЛЕ КАРИЕВУ – 130

*Арсланов М.Г.* Габдулла Кариев – «Отец татарского театра» . . 120

## ПЕРСОНАЛИИ

*Кадирова Э.Х.* Трудолюбивый ученый . . . . . . . . . . . . . . . 132

## ПО СЛЕДАМ ЭКСПЕДИЦИЙ

*Булатова М.Р.* Эуштинско-чатский говор татарского языка (*по материалам экспедиции 2015 г., предпринятой в Томскую область*) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137

## ИСКУССТВО

*Султанова Р.Р.* Инсталляция «Болгарская цивилизация. Дорога длиною в тысячелетия» в Болгарском государственном историко-архитектурном музее-заповеднике . . . . . . . . . . . 151

*Улемнова О.Л.* Творческий путь художника Тавиля Хазиахметова (*к 80-летию со дня рождения*) . . . . . . . . . . 155

*Шкляева Л.М.* Казанское полотенце из металла и дерева (*обзор творчества художника Рината Ахметова*) . . . . . . . 160

*Галимова Э.М.* Особенности музыкального оформления драм Тази Гиззата . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 162

## НОВЫЕ КНИГИ

Ближе еще на сто лет (к изданию 3-го тома истории татарской литературы) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166

Валиева Л.Г. Каузальность в татарском литературном языке (Казань: ИЯЛИ, 2015. 174 с.) . . . . . . . . . . . . . . . . 172

Яруллина Л.И. Татар телендә сузык һәм тартык авазларның (вокализм, консонантизм) язуда бирелеше: XIX гасыр һәм XX гасырның I чиреге (Казан, 2014. 335 б.) . . . . . . . . . 173

## БАШ РЕДАКТОР СҮЗЕ

Хөрмәтле галимнәребез!
Мөхтәрәм авторларыбыз һәм укучыларыбыз!

Республикабыз Хөкүмәтенең ярдәме, Татарстан Дәүләт Советы, Мәгариф һәм фән министрлыгының хуплавы һәм ТР Фәннәр академиясе тарафыннан гамәлгә куелган «Фәнни Татарстан» журналы чыга башлауга 2 ел вакыт үтеп китте. Журналның 8 саны укучыларыбыз кулына барып иреште. Чагыштырмача кыска вакыт эчендә басманың структурасы тәгаенләнде, тематик юнәлешләре билгеләнде, авторлар даирәсе тупланды, кыскасы, ул үз йөзен һәм укучыларын табып килә дип әйтә алабыз.

Журналның төп максаты – гуманитар фәннәр белгечләрен татар телен, әдәбиятын, тарихын, мәдәниятен, милли мирасны өйрәнү ягыннан берләштерү; Россия һәм чит ил галимнәренең төрле фәнни юнәлешләрдәге ачышларын татар дөньясына ирештерү; татар теленең җәмгыятьтә кулланылыш даирәсен киңәйтү, фән теле буларак үсешен гамәли яктан тәэмин итү. Басманың «2014–2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителүе дә нәкъ менә шуны дәлилли.

Ике ел эчендә журнал битләрендә барлыгы 190 публикация дөнья күреп, аларның 170 ен фәнни мәкаләләр, 20 сен яңа китапларга, басмаларга, җыентыкларга бәяләмәләр һәм күзәтүләр алып тора. Географик яктан караганда, авторларыбызның төп өлеше – Татарстаннан (157 мәкалә), Россиянең башка төбәкләреннән (7 мәкалә), чит ил авторларының исә 6 мәкаләсе тәкъдим ителде. Мәкаләләрнең тематик диапозоны да күптөрле. Алар, нигездә, гуманитар юнәлештәге мәкаләләр: 170 мәкаләнең 137 се татар теле, әдәбияты, тарихының тегe яки бу мәсьәләләрен яктырта. Төгәлрәк әйткәндә, тел буенча 42 мәкалә, әдәбият белеме буенча шулай ук – 42, татар тарихына караган – 17, сәнгать буенча – 16, фольклорда – 11, иҗтимагый һәм фәлсәфи фикер үсешенең мөһим мәсьәләләрен яктырткан 4 мәкалә укучыга барып иреште. «Милли мәгариф» рубрикасында 5 мәкалә, «Шәхесләребез» өлешендә – 13, «Фәнни ядкәрләр» бүлегендә 5 мәкалә дөнья күрде. 11 мәкаләдә төрле төбәкләргә, районнарга оештырылган комплекслы экспедицияләр нәтиҗәсе буларак, аларда эзләнелгән, өйрәнелгән мөһим табышларны халыкка җиткерүдә, саклап калуда авторлар үз өлешләрен кертте.

Мәкаләләрнең журналда басылуына куелган төп таләп – аларның фәнни нигезле һәм татар телендә язылган булуы. Кызганыч ки, ике еллык тәҗрибә шуны күрсәтә: татар телендә язучы авторлар көннән-көн сирәгәя бара, ә фәннең аерым бер тармакларында исә, әйтик, төгәл яки техник фәннәр юнәлешләрендә, гомумән юк дәрәҗәсендә. Бу, әлбәттә, күп төрле сәбәпләр белән бәйле. Шулардан берсе – татар теленең фән теле буларак гамәли кулланылыш мәйданы тарая бару,

югары уку йортларында (шул исәптән техник вузларда да!) элегрәк актив һәм максатчан рәвештә алып барылган татарча белем бирү системасының инде бүген бик тә катлаулы этапка керүе турында сөйли.

Бу һәм башка мәсьәләләр журналның февраль аенда уздырылган редколлегиянең киңәйтелгән утырышында да күтәрелде. Дәүләт оешмаларыннан, югары уку йортларыннан, нәшриятлардан вәкилләр, журналистлар катнашында узган әлеге чарада яңгыраган фикерләр килеп туган вәзгыятьнең никадәр катлаулы һәм четрекле булуын ачык күрсәтә. Шул җәһәттән без дә коллегаларыбызны журнал тирәсенә ныграк тупланырга чакырабыз һәм алардан да саллы хезмәтләр көтеп калабыз. Шулай ук яшь коллегаларыбыз – аспирантларның шундый бәрәкәтле мәйданнан тиешенчә файдалана алмаулары татар телендә фәннең алга үсеше турында борчылу хисе уятмый калмый.

«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе 2015 елда, Россиядә әдәбият елы уңаеннан, яшь галимнәрнең милли әдәбият белән кызыксынуларын көчәйтү, иҗади активлыкларын, яңалыкка омтылышларын арттыру, аларның фән дөньясында уңышка ирешүләренә ярдәм итү максаты белән фәнни мәкаләләргә конкурс игълан иткән иде.

Әлеге бәйгегә йомгак ясалып, җиңүче дип табылган мәкаләләр журнал битләрендә дөнья күрде. Шундыйлардан филология фәннәре кандидаты, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты өлкән фәнни хезмәткәре Каюмова Гөлия Илдус кызының «Ризван Хәмид драмаларында конфликт һәм характерлар гәүдәләнеше», филология фәннәре кандидатлары, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәрләре Булатова Миңнира Рәсим кызының «Башкортстанда туган татар язучылары иҗатындагы телбизәкләр», Хәбибуллина Лениза Газинур кызының «Әдәби тәрҗемә мәсьәләсе» (Анна Ахматованың «Сайланма әсәрләре» мисалында), Хаҗиева-Демирбаш Гүзәлия Сәйфулла кызының «Рафаил Газиз хикәяләренең поэтик ономастикасы» исемле фәнни хезмәтләрен әйтеп үтәргә мөмкин. Шулай ук Казан шәһәре Яңа Совет районы «7 нче интернат лицей»ның татар теле һәм әдәбияты укытучысы, Тел, әдәбият һәм сәнгать институты аспиранты, яшь язучы Мансуров Алмаз Илдар улының «Р. Гаташның “Ирләр булыйк” шигыренә салынган фәлсәфи фикер» исемле мәкаләсе дә журнал редакциясе тарафыннан югары бәяләнде.

Бәйгедә катнашкан барлык авторларга да олы рәхмәтебезне җиткерәбез, җиңүчеләрне ихластан тәбриклибез, алга таба да дәвамлы һәм нәтиҗәле хезмәттәшлеккә өметләнеп калабыз.

Журналыбызның өч еллыгын да күркәм хезмәтләребез, әтрафлы фәнни ачышларыбыз, саллы яңалыкларыбыз белән каршы алырга һәм бер-беребезнең уңышларына куанып яшәргә язсын!

«Фәнни Татарстан» сәхифәләренә рәхим итегез!

УДК 811.512.145′38

***И.Б. Бәширова***

# XIX ГАСЫР АХЫРЫ – XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР СӘНГАТЬЛЕ ПРОЗАСЫНДА ХИКӘЯЛӘҮ СТИЛЬЛӘРЕ

В татарской художественной прозе конца XIX – начала XX в. наблюдается три стиля повествования. Первый основывается на письменно-литературных традициях прошлого и представляет собой пересказ исторических легенд. В конце XIX в. формируется новый стиль – авторы начинают рассказывать о повседневной жизни своих современников. При этом они могут вмешиваться в ход событий, а основная идея произведения преподносится как личное мнение автора. Наряду с этим в произведениях татарских классиков начала XX в. прослеживается и третий стиль повествования, в котором на первый план выходит образность, т.е. содержание передается при помощи средств художественного описания.

**Ключевые слова:** старотатарский письменно-литературный язык, язык художественной прозы, стили повествования, письменно-литературная традиция, речь автора, речь персонажей, средства художественного описания.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар сәнгатьле прозасында, берсе икенчесенең дәвамы булып барлыкка килә торган, өч төрле хикәяләү ысулының хәрәкәттә булуы күренә.

**Беренче төр хикәяләү белән** К. Насыйриның «Кырык вәзир кыйссасы» (1868) «Кырык бакча» (1880), «Әбүгалисина кыйссасы» (1881), «Фәвакиһел җөләса фил-әдәбият» җыентыгында (1884) кырык рауза дип тупланган хикәятләр языла. «Әбүгалисина»-дан башкалары 40 өлешкә бүленә, барлык бүлем дә «хатын әйтте», «вәзир әйтте» дип, кырык вәзирнең авызын бер хатынның томалап баруы рәвешендәге хикәятләрдә, яисә Локман Хәким әйтте, Нәүширвангә әйттеләр, бер кеше әйтте, Арсту әйтте, бер гарәп әйтте, Әкълидис димештер ки, Сәһел бине Һарун әйтте, Әюб бине Гасан әйтте... дип, башлана торган аерым хикәятләрдә, укучыга тарихтан мәгълүм булган бер хакыйкать җиткерелә. Әлеге хикәятләрне укыган, яисә сөйләгән кеше автор буларак кабул ителә, аерым бер авторның йөзе-үзе күренми, мөнәсәбәт белдерүе сизелми. Әлеге үзенчәлекне К. Насыйри: «Ошбу Гыйлме мөхазара» гарәпчә, гыйлемнәр һәм әдәбият фәне җөмләсеннән бер фәндер ки, мәҗлесләрдә вә сохбәтләрдә җөмлә арасында сүзнең җаена туры китереп, хикәяләү рәвешендә икенче бер кешенең фикерләрен дә кертеп сөйләүдән гыйбарәттер», – дип, «Фәвакиһелҗөләса фил-әдәбият» китабының сүз башында теоретик яктан дәлилләп тә бирә [Насыйри, 1975, б. 250–280].

Төрки-болгар әдәбиятында әсәрне кырык өлешкә бүлеп язуның максаты, Мөхәммәд пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вәс-сәламнең «әгәр берәү пәйгамбәрнең кырык хәдисен башкаларга өйрәтсә, ул кеше галимләр җөмләсендә санала, ә үлгәч шәһитләр хисабында булачак» дигән хәдисенә

нигезләнеп, Мәхмүд әл-Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрендә аңлатыла (1357). «Оҗмахларга ачык юл» дип атала торган бу әсәрен автор унар фасылга бүленгән дүрт баб итеп төзи, ягъни ул пәйгамбәрнең кырык хәдисен укучыларына җиткереп, үзенә дә, укучыларына да оҗмахларга юл ачуына ышанычын белдерә [Болгари, б. 9–10; Нуриева, б. 30–32]. Димәк, XIV гасыр уртасында язылган әсәрнең төзелеше, К. Насыйри әсәрләре белән XIX йөз ахырына кадәр дәвам итә. Әмма максат үзгәрә, хәдисләр тәфсилләнми, «...тәварих китапларында риваять кылып язалар ки ...», – дип, [«Кырык вәзир кыйссасы», 1896], тарих китапларыннан күчә-күчә риваятьләр булып әверелгән, ягъни сөйләнәчәк хәлләрнең тарихи язмалардан күчереп алынганлыгы искә төшерелеп башлана да, хикәя фигыльнең үткән заманы формалары белән, «хатын әйтде», «вәзир әйтде» дип дәвам ителә: «Хикәят. Хатын әйтде: җиһан сараенда бер падишаһ бар иде вә ул падишаһның өч данә угълы бар иде. Бу падишаһ көннәрдә бер көн әҗәл ястыгына башын куйды. Угылларын янына чакырып әйтде...». «...Хикәят. Вәзир әйтде: җиһан сараенда бер патша бар иде. Аның ике вәзире бар иде. Бере бик галим вә бере бик надан иде. Бер көн надан вәзир әйтер иде. ...дияр иде. Бу сүзләр патшага хуш күренер иде..», – дип, кырык вәзирнең хикәятләрендә сөйләнелә торган хәлләр, хатын сөйләмендәге хакыйкать белән юкка чыгарыла бара [Насыйри, 1975, б. 221–250].

К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы» [1881, 1898, 1974] кырык өлешкә бүленми, хәдис китерелми, әмма «Равияне әхбар вә накыйляне асар ошбу тарикъ үзрә риваять кыйлыр ки ...» дип, ягъни алга таба хикәяләнә торган вакыйга-хәлләрнең хәбәрләр сөйләүчеләр һәм әсәрләр күчерүчеләрдән ишетелгән нигездә баруы ассызыклана [1898, б. 3]. Әсәрнең икенче хыялы да мөкаддәмәдәге штамп белән ачыла: «Равияне ширин кәлям, ягъни тәмле-тәмле хикәятләрне риваять кыйлгучылар шу илә риваять кыйлурлар ки...» (1898, б. 17), өченче хыял – әлкыйсса дип (76), дүртенче хыял «Равияне әхбар вә накыйляне асар шу илә риваять кыйлыр ки...» (89), әсәрнең хатимәсе: «Әбүгалисина вафаты хакында, вә кабере кайда икәне хакында күп риваятьләр бардыр...», – дип, шул риваятьләрнең эчтәлеге сөйләнелә. Шулай итеп, тасвирлана торган вакыйгалар, әсәрнең мөкаддәмәсеннән башлап, төп өлеше булган дүрт хыялда һәм хәтимәсенә кадәр, риваять сөйләүчеләрнең сүзен, «ул әйтте – диде» шәкелендә кабатлап сөйләү нигезендә укучыга җиткерелә [Насыйри, 1898, 1974, б. 207–333]. Хикәяләүнең әлеге ысулы белән Г. Фәизханның «Тутыйнамә китабы» язылуы мәгълүм [Фәизхан, 1887, 1896].

К. Насыйриның «Әбүгалисина кыйссасы»ннан соң дүрт ел үткәч, **Муса Акъегетзадәнең** (1870–1923) «Хисаметдин менла» дигән, автор үзе билгеләгәнчә, милли романы басыла. Болай дип башлана: «Русия уртасында Идел нәһерүндән озак дәгел бер татар аулы мәүҗүддер. Карьяның әһалисе ике йөз кадәрү улуб, адыны фаш идмәгендән чикийү-

рүз, анчак хикәйәмези йеңел аңлатмак ичүн адыны Н хәрфилә ишарәт идәмез» [Акъегетзадә, б. 3]. Күренә ки, М. Акъегет әсәрнең авторы буларак, хикәяләүне без дип үз исеменнән, үзенең карашын белдереп сүзен башлый. Шулай итеп, төрки-татар телендә, 500 елдан артыграк дәвам ителеп килә торган хикәяләүнең ысулы яңа юнәлешкә күчерелә, сәнгатьле чәчмә әсәрләрдә вакыйганы сөйләп **хикәяләүнең икенче төре, икенче стиле башлана.** Әлеге ысулның яңалыгы дигәндә, түбәндәге үзенчәлекләр истә тотыла:

1) «Хисаметдин менла»да, «Нәһҗел-фәрадис» фасылларындагы кебек «бер шәех бар ирде», бер галим бар ирде», «бер салих кем ирсә бар иде», яисә К. Насыйри тәрҗемәләрендәге кебек, «хатын әйтте», «вәзир әйтте», яисә «хикәятләрне риваят кыйлгучылар шу илә риваять кыйлурлар ки...» кебек әсәрне башлаудагы штамп юкка чыга.

2) Автор, реаль шәхес буларак, әсәрендә сөйләнәчәк хәлләрнең кайда, кайчан баруын конкрет әйтеп сүзен башлый.

3) Хикәядәге вакыйганы сөйләүче бердәнбер кеше буларак, аларның тәртибен (сюжет барышын) билгели, укучысына эндәшеп, хәрәкәтне тизләтә, аңлатма бирә: «Н» карьясына кайтамыз, хөрмәтле укучыларым!», яки «Кыш әсналәрендә хикәямездә язылган затларның мәгыйшәтләре гадәтенчә кичеп, дикъкатә лаек бер шәй юк иде», яисә: «Хөрмәтле укучыларым, хәзердә, әлбәттә, аңладыгыз ки, бу ике яшь бер-беренә гашыйк иде» һ.б.

4) Сөйләнә торган вакыйгахәлләрне җанлы итеп укучыга җиткерү өчен, әсәрдәге персонажлар, авторның идеалын күрсәтер дәрәҗәдә уңай һәм аларга каршы куелып, кире итеп бирелә. Уңай персонажлар, аларның өстебашы, уй-фикерләре, эш-гамәле турында автор фәкать мактап кына сөйли: «Йөзенә баксаң, бу егерме биш яшьлек егеткә тәгажәпләнерсең. Йөзе гүзәл ачык. Яңадан чыкмыш кечек сакалы вә мыеклары вә кечек чәче коңгырт рәңдә улып, җамаләте йөзенең гүзәллеген дәһа зиядәләштерерләр». «Гүзәл вә күркәм Хәнифә туташның» чибәрлеге тагын тәфсилләнебрәк бирелә. Бу персонажларның эш-гамәлләре дә үзләре кебек үк уңай һәм матур: алар гыйлемле, «пәк күркәм вә уңган», эшчән, милләтен сөя. Кире персонажлар, киресенчә, «Сибгатулла әфәнде, менла Хисаметдин кеби яшь улса да, күркәмлеге юк иде», Бикбулат менла гайбәтче, хәсәдле-көнче һ.б. Уңай һәм кире персонажлар турында сөйләгәндә, автор мөнәсәбәте төрлечә белдерелә. Уңай персонажга бәйле рәвештә, авторның максатына туры килә торган хакыйкать әйтелә. Ул, гадәттә, персонажның уе-фикере булып бирелә: «...Әмма мәгълүматлы улмак өчен нә лязем? Укымакны сәүмәк лязем дия фикерләнә-фикерләнә, Хисаметдин менла кинә утасында йөзмәгә башлады». Яисә «Шәрхе шәригател ислам» китабында язылмышдыр: хәзрәте рәсүл саллалаһы галәйһи вә сәллам хәзрәтләре димешләрдер ки...» дип, югары дәрәҗәдәге шәхеснең сүзе буларак кабатлана. Димәк, беренче төр

хикәяләүнең аерым традицияләре дә дәвам ителә.

Кире персонажына карата авторның фикере төрле чаралар белән ирониягә төрелә: а) сүзнең туры мәгънәсе белән: «...хәтта ки мөдәррис хәзрәтләре йортка гизмәгә чыкканда, майлы ашларның кухусы вә исе ашханәдән борынына җитешеп, ләззәт хис улынып, деле тирәсендән төкерек чыкты»; ә) чагыштыру, метафора кебек сурәтләү чаралары белән: «Белешемез Бикбулат менла ... аучы куян вә үрдәкне өмет итеп сакладыкы кеби, бу да никахлар өмет итеп сакламакта иде» һ.б. Сөйләмне бизәкләү тискәре персонажны тасвирлырак-җанлырак итә [Нуруллин, б. 12].

5) Персонажларның үзара сөйләме диалог формасында бара, дигәч, диде, дип кебек ярдәмлекләрдән башка да бирелә. Авторның угыз-төрки элементлары белән чуарланган үз сөйләменнән аермалы буларак, персонажлар, бигрәк тә хатын-кызлар, халыкчан, җанлы, шул исәптән, мишәр сөйләменә хас булган сүз һәм сүзформаларны иркен кулланалар. Урыны-урыны белән автор сөйләменең персонаж тарафыннан дәвам ителүе күренеп китә: «Бу нәзек бил вә җәмилә кыз менланың күзенә тәмамән күренде.... Нийә Алла бөйлә җәмиләләр ярата икән!?». Эмоциональ кичерешле җөмләләр, хат формасындагы өзекләр персонажларның сөйләме итеп бирелә, билгеле бер дәрәҗәдә характерлары ачыла, димәк, авторның җанлы булуы персонажга да тәэсир итә. Әмма бу өзекләр, сюжетны алып баручы зат буларак, авторның тулы хокукына зыян китерми, ул әсәренең тулы хәкиме булып, башка барлык чаралар аның ярдәмчеләре булып кала. Әдәби әсәр бер үзәккә туплана [Виноградов, б. 118]. «Нәһҗел-фәрадис» һәм К. Насыйри хикәятләреннән аермалы буларак, укучыга җиткерелергә тиеш сәнгатьле фикер, тарихи гомумилегеннән котыла, авторның үз фикере буларак бирелә. «Хисаметдин менла» романының, иҗтимагый тормыш шартлары яктылыгына куеп карала һәм прогрессив дип санала торган яңалыклары турында Г. Ибраһимов, М. Гайнуллин, Х. Миңнегулов, Ф. Мусин, А. Хәлим, Р. Мостафин кебек галимнәр һәм язучыларның фикер әйтүе мәгълүм. Әдәбиятчылар ассызыклый торган барлык билгеләрнең дә романны сәнгать әсәре ясый торган хикәяләү ысулының табигатенә бәйле булуы күренә.

Әсәрдә тасвирлана торган вакыйга-хәлләрне укучыга җиткерүдә, М. Акъегетнең «Хисаметдин менла» романы белән башланган әлеге яңарыш, билгеле бер үзенчәлекләр белән, З. Бигиев, Р. Фәхретдин, Ф. Кәрими, Ш. Мөхәммәдов, З. Һади, М. Гафури кебек мәгърифәтче әдипләребезнең иҗатында дәвам ителә [Бәширова, б. 7–41].

Шуның белән бергә, XX гасырның беренче елларында, **татар халкының классик әдипләре иҗат итә башлый.** Г. Исхакый үзенең «Кәләпүшче кыз» хикәясенең «Хөрмәтле укучым» дип башланган керешендә, «...әдәбият нәдән гыйбарәт идекене» аңлату максатыннан болай дип белдерә: «...Һәр язылган сүз үз вакыйгала-

рын тасвир, үз хәлләрен бәян улмаз! Хосусән, мөхәрририләр, шагыйрьләр ни язсалар, кемне тасвир кылмакчы булсалар, шул кеше булып күп сүзләр сөйләрләр һәм сөйләтерләр. Бу сүзләрнең бәгъзеләре әшәке улсалар да, мөхәррирнең үзенең фикеренең шулай булуын белгертмәйдер» [Исхакый, 1902, б. 2]. Аңлашылганча, әдәби әсәр эчтәлегендә әйтелә торган фикер һәм сөйләүче шәхесенең фикере белән бер үк тәңгәл күренеш булмавы ассызыклана. Г. Исхакый бу хакта «Бай углы» әсәренең керешендә дә искәртә: «Яздыгым романында бай угылларыбызның тәрбияләре нинди идекене, вә бу тәрбияләрнең ни дәрәҗәдә зарарлы идекене укучыларымның күз алларына куймак эстәдем. ...Милләтемездә шул мәсьәләне ислях фикере уянмасмы дип, мин шул эшләремезне булдыра алдыгым кадәр күрсәтмәк эстәдем» [Исхакый, 1998, б. 113]. Ягъни төп максат булган хәлне сөйләп бару гына түгел, билгеле бер хәлләрне **гомумиләштереп, күз алдына кую, күрсәтеп бирү.** Әлеге фикер Ф. Әмирханның «Танымаганлыктан таныштык» дигән хикәясенең «Бер-ике сүз» дип бирелгән керешендә тагын да тәгаенләнә: «Монда очрый торган «мин» кәлимәсен мөхәррирнең үзендән тәгъбир дип уйлау хата булачакдыр. Хикәя язганда бу тәгъбир, гомумтарафыннан кабул ителгән бер тәгъбир булып, мөхәррирнең үз фикерен күбрәк кертер өчен истигъмаль ителәдер» [Әмирхан, 1909]. Шулай итеп, XX гасырның башларында, татар прозасын хикәяләүнең **өченче төренә теоретик нигез салына.** Гамәли яктан исә шул ук Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камалның беренче әсәрләрендә **билгеле бер хәлне сөйләү дәвам ителгәне хәлдә, «мөхәррирнең үз фикерен» күбәйтү ысулы да яшәеш** ала бара. Менә Ш. Камалның «Уяну» хикәясе. «Муса ачуланган иде», – дигән гади генә башламнан, билгеле бер эзлеклелектә, укучы күрә алырдай, аңа көчле эмоциональ тәэсир итә торган тасвир ясала: «...тәне чымырдап китте, чәчләре үрә торды, агач кебек катты....Ишек төбендә ...бер күз! Яшьле күз... туп-туры Мусаның күзенә карый... Гафифәнең күзе...» (Камал, 1909). Бу юлларда автор «юк». Бу – Мусаның уянуы – акылдан шашуы. Сөйләү туктала, сөйләү логикасына туры килә торган җөмлә төзелеше юк. Укучы хәзер тыңлап утыручы гына түгел, персонажның катлаулы рухи хәле аңа да күчә. Сүзләр белән сурәт – образ барлыкка килә. Уяну дигән гадәти бер сүзнең төп мәгънәсе, әлеге әсәр эчтәлеге өчен генә кирәк булган, акылдан шашу дигән өстәмә мәгънә белән катлауландырыла. Ш. Камалның «Буран» хикәясенең исемендә котырган табигать күренеше һәм адәм баласының шундый ук хис-кичерешләре [Камал, 1952]. Г. Исхакыйның «Остазбикә»сендә мулла кызы, мулла хатыны баласыз Сәгыйдә һәм буыннарның дәвам итәргә тиешлеген аңлаучы Ана – Остазбикә. Ф. Әмирханның «Хәят»е – бер кызның исеме, шул кызның мәгънәсез тормышы, Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр»е, «Тирән тамырлар»ы һ.б. әсәрләр шушы юнәлештә иҗат ителә. Өстәмә

мәгънә дигән төшенчәнең төрле авторда төрлечә барлыкка килүе аңлашыла, бу мәсьәләне җентекләп өйрәнәсе барлыгы күренә.

Әмма бу хәлне барлык укучы да бер дәрәҗәдә аңлыймы? Әлеге мәсьәләгә үз вакытында Җ. Вәлиди игътибар итә: «...Гаяз әфәнденең яңа чыккан бер әсәрене укый идек...Авылның куштанларыннан булган фатир хуҗамыз боны тыңлап тора икән, мин аның ишене көненә бишне язарга могу, диде. ...Гаяз әфәнденең әсәре ачык татарча язылган, безнең хуҗага да, хуҗа хатынына да тәмамла аңлашыла, фәкать безгә аңлашылган бик күп мәгънә аларга аңлашылмый иде. Бу көндә инсанның фазыйләте (*өстенлеге, холкы*), аның гәүдәсе, кара көче илә үлчәнмәгән кебек, әдәбиятның да кыйммәте тышкы ягы, ягъни ләфызыга (*сүз, сүзнең яңгырашы белән белдерелә торган мәгънәсенә*) карап билгеләнмидер», – дип аңлата [Вәлиди, б. 13].

Кыскасы, хикәяләүдәге аермалык әсәрнең композицион төзелешенә, сүзләрнең сайланып кулланылуына, җөмлә төзелешенә, сөйләнә торган хәлләргә карата авторның мөнәсәбәте белдерелүенә, гомумән, Гегель сүзләре белән әйткәндә, әсәрдәге эстетик эчтәлекнең сәнгатьле чаралар белән тасвирланып бирелүенә үзенчә тәэсир итә.

Хәзерге татар прозасы бу яктан да каралып тикшереләме икән?!

**Әдәбият**


*Акъегетзадә М.* Хисамеддин менла. Милли роман яки хикәя. Казан: Ун-т табгыханәсе, 1886. 70 б.

*Әмирхан Ф.* Танымаганлыктан таныштык. Милли хикәя. Казан: «Юл» китапханәсе, 1909. 62 б.

*Бәширова И.Б.* Сәнгатьле чәчмә әсәрләр теле. Татар прозасында хикәяләү стильләренең үсеше һәм аның әсәр теленә тәэсире (VIII–X класслар өчен әдәбияттан кулланма). Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 96 б.

*Болгари М.* Нәһҗел-фәрадис. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 358 б.

*Вәлиди Җ.* Татар әдәбиятының барышы. Оренбург: Вакыт, 1912.

*Виноградов В.В.* О теории художественой речи. М., 1971.

*Исхакый Г.* Кәләпүшче кыз. Хикәя. Казан: тип-я Б.Л. Домбровского, 1902. 42 б.

*Исхакый Г.* Бай углы. Роман // Мөхәммәдгаяз әл-Исхакыйның мәҗмугәл асәре. 1 җилд. 4 китап. Казань: Лито-тип-я И.Н. Харитонова, 1910. Б. 161–224.

*Камал Ш.* Уяну // Шура (Оренбург). 1909. № 8, № 12 (июнь). Б. 379.

*Камал Ш.* Сайланма әсәрләр: 4 томда. 1 т. Хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1952. 336 б.

*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: ике томда. 2 т Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. 318 б.

*Насыйри К.* Рәиси әл-хөкмән Әбүгалисина кыйссасы. Казань: Типолитография Императорского университета, 1898. 112 б.

*Нуриева Ф.Ш.* «Нахдж ал-Фарадис» Махмуда ал-Булгари. Казань: Фән, 1999. 208 с.

*Нуруллин И.* Реализм турында. Казан, 1974.

*Фәизхан Г.* Тутыйнамә китабы. Казан: типо-лит-фия наследников М. Чирковой, 1896. 142 б.



***Бәширова Илида Басыйр кызы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми тел белеме бүлеге әйдәп баручы хезмәткәре*

УДК 811.512.145′38

***Б.К. Миңнуллин***

# МАССАКҮЛӘМ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАСЫ БУЛАРАК ГАЗЕТА ТЕЛЕ ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИК СТИЛЬ

В статье рассматривается проблема соотношения языка газеты как средств массовой информации и публицистического стиля литературного языка, а также затрагивается роль татарской газеты начала XX века в формировании и становлении национального языка татарского народа.

**Ключевые слова:** литературный язык, функциональные стили, публицистический стиль, язык средств массовой информации, язык газеты.

Әдәби телнең формалашуы һәм үсеше аеруча катлаулы, озак вакыт аралыгы таләп итә торган процесслардан санала. Беренче чиратта, бу аның киңкырлы иҗтимагый күренеш булуы белән аңлатыла. Әдәби телнең төп үзенчәлекләреннән саналган язма традицияләр һәм нормалар белән бергә, аның төрле иҗтимагый өлкәләрдә кулланылуы нәтиҗәсендә барлыкка килгән функциональ-стилистик төрлелекне – ягъни әдәби телнең функциональ стильләрен аерым атап үтәргә кирәктер. В.Х. Хаков фикеренчә, теге яки бу телдә функциональ стильләрнең булуы – тел үсешенең иң төп шартларыннан берсе булып тора [Хаков, б. 110].

Төрле елларда әдәби тел мәсьәләләрен, шул исәптән функциональ стильләр проблемасын, фәнни яктан өйрәнүгә рус тел белемендә Р.А. Будагов, В.В. Виноградов, Л.В. Щерба, Г.О. Винокур, И.Р. Гальперин, В.Г. Костомаров, Г.Я. Солганик, М.Н. Кожина, А.Н. Васильева, Л.М. Майданова, Д.Н. Шмелев, татар тел белемендә – Х.Р. Курбатов, В.Х. Хаков, Ф.С. Сафиуллина, С.М. Ибраһимов, М.З. Зәкиев, И.М. Низамов, И.Б. Бәширова, Р.С. Абдуллина, В.З. Гарифуллин кебек галимнәр үзләреннән зур өлеш керттеләр.

Бүгенге көндә үсеш алган телләрдә аз дигәндә биш функциональ стиль бар дип исәпләнелә: публицистик, фәнни, рәсми-эш кәгазьләре, матур әдәбият һәм сөйләм-көнкүреш стильләре [Кожина, с. 157]. Шул ук вакытта, татар тел белемендә кайбер галимнәр фикеренчә, өстәмә рәвештә дини-дидактик, эпистоляр һәм хәтта көндәлек-профессиональ стильләр турында сүз алып барырга да урын бар дип санала [Бәширова, с. 20–25].

Мәгълүм булганча, публицистик стиль – күпсанлы массакүләм мәгълүмат чаралары телендә чагылыш таба торган, әдәби телнең аерым бер функциональ стиле. Хәзерге дөньяны газета-журнал, радио, телевидение, интернеттан башка күз алдына китерү дә кыен. Бүгенге көндә алар инде халыкка мәгълүмат җиткерү чарасы гына түгел, ә бәлки дәүләт һәм дөнья күләмендә пропаганда коралы

да булып тора. Әдәби телнең публицистик стиле телче галимнәр өчен тел белеменең аеруча мөһим һәм үзенчәлекле аланы булып тора. Яңа мәгънәләр, күренешләр, иң беренче чиратта, нәкъ менә массакүләм мәгълүмат чаралары телендә урын ала, биредә аларны аңлату һәм тасвирлау өчен яңа тел чаралары кулланылышка кертелә.

Бүген рус һәм татар тел белемендә публицистик стиль турында сүз йөрткәндә берничә атама кулланыла. Мәсәлән, төрле авторларның хезмәтләрендә үзара синонимик саналган «публицистик стиль» («публицистический стиль»), «газета-публицистика стиле» («газетно-публицистический стиль»), «газета стиле» («газетный стиль»), «газета-журнал стиле» («газетно-журнальный стиль»), «мәгълүмати стиль» («информационный стиль»), хәтта «иҗтимагый-сәяси стиль» («общественно-политический стиль») дигән терминнар очрый. «Рус теле стилистикасы» («Стилистика русского языка», 1982) хезмәтендә исә «публицистик стиль» термины файдаланыла, ә «газета-публицистика» термины публицистик стильнең бер тармагы, ягъни подстиле дип аңлатыла [Бондалетов и др., с. 188]. Узган гасырның 90 нчы еллары уртасына кадәр, элекеге Советлар Союзы территориясендә яшәүче халыкларның тел проблемаларын язма материаллар нигезендә фәнни яктан өйрәнү барышында «публицистик стиль» термины белән параллель рәвештә «газета стиле» яисә «мәгълүмати стиль» вариантлары да кулланылып килде, чөнки укучы яңа мәгълүматны бары тик шул ук газета һәм журнал текстларыннан гына таба ала иде. Ләкин инде дөньякүләм масштабларда интернет челтәре кулланылышка тирәнрәк керә барган саен, бу терминнарның мәгънәләрендә билгеле бер дәрәҗәдә аерымлыклар барлыкка килде. Хәзер инде интернет челтәрендә басылган публицистик мәкаләнең тел үзенчәлекләрен берничек тә «газета стиле» яки «газета-публицистика» стиле дип атап булмый.

Телче галим М.Ю. Казак фикеренчә, әдәби телнең безне кызыксындырган стиленең иң төгәл һәм киң кулланылышта булган атамасы – «газета-публицистика стиле» [Казак, с. 11]. Аның эчтәлеген һәм эчке структурасын нәкъ менә әлеге термин тулысынча ачып бирә дип исәпли ул.

Әдәби телнең иң киң кулланылышлы дип табылган функциональ стилен «газета-публицистика» термины белән атау, аның фактик таралыш һәм кулланылыш кысаларын ясалма рәвештә тарайту булыр иде. Без, һичшиксез, әлеге стиль кысаларына әдәби телнең язма һәм сөйләмә формалары өчен хас башка үзенчәлекләрнең дә керүен таныйбыз, ләкин терминнар чуарлыгы тудырмас өчен, аның күпкырлылыгын күздә тотып, «публицистик стиль» терминын куллануны кулайрак күрәбез. «Публицистик стиль» термины әлеге стильнең үз эчендә ике тармакны (публицистик һәм газета-мәгълүмати) берләштерүен дә кире какмый, чөнки «публицистика» термины үзе үк «газета» төшенчәсен күз алдында тота.

Мәгълүм булганча, газета көндәлек тормышта актив кулланыла торган, иҗтимагый характердагы һәм башка күптөрле проблемаларны яктыртучы, башкалардан элегрәк барлыкка килгән традицион массакүләм мәгълүмат чараларыннан санала. Бу факт исә массакүләм мәгълүмат чаралары теленең, шул исәптән аерым публицистик жанрларның иң элек газета текстларында формалашканын һәм үсеш алганын күрсәтә. Димәк, массакүләм мәгълүмат чаралары кысаларында газета теле беренче пландагы төп рольне үтәүче компонент буларак кабул ителергә тиеш.

Югарыда әйтеп киткәнчә, публицистик стильнең төп функцияләре укучыга мәгълүмат бирүдән һәм аның аңына тәэсир итүдән гыйбарәт. Моннан тыш, бүгенге көндә газета аналитик, этик һәм эстетик функцияләрне дә башкара. Шул сәбәпле, катлаулы һәм күпкырлы алан булып саналган публицистик стиль кысаларында әдәби телнең башка функциональ стильләренә хас үзенчәлекләр дә чагылыш таба. Бу хакта В.В. Одинцов тарафыннан «Текст стилистикасы» («Стилистика текста», 2007) хезмәтендә әйтелгән сүзләр урынлы булып күренә. Аның фикеренчә, телдә традицион функциональ стилистика кысаларына, аның кагыйдәләренә тулысынча сыешып бетми торган өч төп текст төрен аерып чыгарырга мөмкин: фәнни-популяр әдәбият, мәхкәмә риторикасы һәм публицистик стильнең әдәби жанрлары (очерк, эссе, сатира һ.б.) [Одинцов, с. 71]. Нәкъ менә шул сәбәпле, теге яки бу газетада без төрле жанрларга караган текстларга юлыгабыз. Әлеге текстлар исә, үз чиратында, аерылгысыз бербөтен күренеш булып кабул ителә торган газета телен грамматик, лексик һәм стилистик яктан югары дәрәҗәдә баетуга юл ача.

Вакытлы матбугат органнарының телен фәнни өйрәнү кысаларында, аеруча татар филологиясендә, телче галимнәрнең бер өлеше «газета теле», «газета тексты теле», «матбугат теле», яисә «газета дискурсы» турында сүз алып бара. Ләкин бу очракта чираттагы сораулар туа. Газета теле дигәндә теге яки бу газета битләрендә басылган теләсә нинди текст турында сүз барамы, яисә публицистик стильдә башкарылган мәкалә турында гынамы? Ә бәлки рәсми стильдә теге яки бу чара турында язылган текст, я булмаса, ахыр чиктә, матур әдәбият стилендә башкарылган әдәби әсәрдән бер өзек күз алдында тотыладыр? Газета битләрендә басылган рәсми хисапның яисә әдәби әсәрдән китерелгән өзекнең «публицистик стиль» терминына нинди дә булса мөнәсәбәте бармы, яисә төрле стильләрдә иҗат ителгән бу текстларны функциональ-стилистик бүленеш кысаларыннан читкә чыгып, «газета теле» яисә «вакытлы матбугат теле» төшенчәләренә бәйле рәвештә кабул итү дөресрәк булырмы?

Әлбәттә, үзара мәгънәдәш булган «газета теле» һәм «газета тексты теле» турында сүз йөрткәндә, аларны әдәби телнең өстәмә мөстәкыйль функциональ стильләре итеп кабул итү дөрес булмас иде. Шул ук вакытта,

«газета теле» һәм «публицистик стиль» төшенчәләре арасында тәңгәллек билгесен кую яисә газета телен публицистик стильнең бер тармагы, ягъни подстиле буларак кабул итү дә зур хата булыр иде. Ни генә дисәк тә, газета телендә публицистик стильнең характерлы сыйфатларыннан тыш, әдәби телнең башка стильләренә хас булган үзенчәлекләр дә чагылыш таба. Вакытлы матбугатны укучы да, аның телен тикшерүче галим дә, аларны бербөтен күренеш буларак кабул итә. Шул ук вакытта, безнең фикеребезчә, газета телен, үз эченә барлык функциональ стильләрнең үзенчәлекләрен алуына карамастан, әдәби тел белән дә тәңгәлләштерергә ярамый, чөнки газета теле структурасында сөйләм теле күренешләре дә урын ала. Шулай итеп, газета телен, публицистик стиль яки гомумән алганда функциональ стильләргә караганда күпкә киң күренеш буларак кабул итү дөресрәк булыр иде. Газета телен матбугат теленең бер тармагы буларак, әдәби тел кысаларында гына түгел, ә бәлки гомумхалык, яисә милли тел системасында карау дөресрәк булыр.

Әлеге карашны дәлилли торган фикерне, шулай ук, рус телче-галим Ю.Н. Караулов хезмәтләрендә очратырга мөмкин. Автор бу очракта газета теле турында түгел, ә бәлки, гомумән, матбугат теле турында сүз алып бара һәм вакытлы матбугат теле, бүгенге көндә, әдәби телдә булган барлык функциональ стильләрнең байлыгын туплап, алардан югарырак булган баскычка күтәрелеп, милли телнең гомумиләштерелгән бер моделе дәрәҗәсенә иреште дип саный [Караулов, с. 16].

М.Ю. Казак хезмәтендә исә «газета теле» төшенчәсе әдәби телнең публицистик стиле кысаларына гына сыеп бетми торган бер лингвистик күренеш буларак аңлатыла. Автор фикеренчә, газета теле, һичшиксез, сөйләмә телгә каршы куела торган әдәби телгә һәм публицистик стильгә нигезләнә, ләкин «публицистик стиль» төшенчәсенә караганда таррак, әмма шул ук вакытта киңрәк тә форма ала [Казак, с. 7].

Бүгенге көндә әдәби телнең публицистик стиле һәм газета теле, яисә, гомумән алганда, массакүләм мәгълүмат чаралары теле тәңгәллеге турында сүз йөрткәндә, төп өч принципны күз уңында тоталар.

Беренче принципка нигезләнгән очракта, публицистик стиль белән газета теле тулысынча тәңгәл күренешләр дип кабул ителә. Югарыда әйтеп үтелгәнчә, публицистик стиль – ул әдәби телнең иҗтимагый мөнәсәбәтләр аланына хезмәт күрсәтүче бер функциональ стиле. Публицистик стиль, вакытлы матбугат һәм башка иҗтимагый-сәяси әдәбияттә дә чагылыш таба. Иң мөһиме, аның тематик киңлеге чикләнмәгән: сәясәт, идеология, фәлсәфә, икътисад, мәдәният, спорт, көндәлек тормыш, укучы игътибарына теге яки бу сәяси-идеологик күзлектән чыгып тәкъдим ителгән вакыйгаларга бәя бирү һ.б. Рус телче-галимнәр Н.И. Клушина, М.Н. Кожина, И.П. Лысакова һ.б. фикеренчә, публицистик стиль, бертуктау-

сыз үсеш кичергән хәлдә дә, үзенең бөтенлеген саклый. Шул ук вакытта, бу галимнәр публицистик стильнең телдә ике калыпта, ягъни язма (газета, журнал, ә бүгенге көндә – шулай ук интернетта) һәм сөйләмә (радио, телевидение, кино) формаларда чагылыш табуын кабул итә. Димәк, публицистик стиль һәм массакүләм мәгълүмат чаралары, шул исәптән, газета теле тәңгәллеге турында сүз алып барганда, беренче принцип нигезендә, югарыда күрсәтелгәнчә, кулланылыш аланнарының күпсанлы булуына карамастан, барлык мәгълүмат чаралары телләре бары тик әдәби телнең публицистик стиле кысаларында гына карала.

Икенче принципка килгәндә, публицистик стиль массакүләм мәгълүмат чаралары теленең нигезен тәшкил итә, ләкин аңар тәңгәл булып саналмый. О.Н. Григорьева фикеренчә, массакүләм мәгълүмат чаралары теле бүгенге көндә әдәби телнең яңадан яңа функциональ төрләрен үз эченә алып, куәтле бер системага әйләнеп бара [Григорьева, с. 364]. Шул ук вакытта, кешелек дөньясының бертуктаусыз коммуникатив алгарышын, шул исәптән теге яки бу әдәби телнең үсешен күз уңында тотканда, функциональ стильләрнең бүленеше һәм киңәюе турында да сүз алып барырга урын бар кебек. Мәсәлән, М.Ю. Казак, публицистик стильне (газета) язма телгә, электрон матбугат чаралары (телевидение, радио, документаль кино) телен исә, әдәби телнең сөйләмә формасына бәйләп, массакүләм матбугат чаралары стильләре системасын төзергә мөмкинлек булуын ассызыклый [Казак, с. 18].

1971 елда В.Г. Костомаров тарафыннан «Газета полосасында рус теле» («Русский язык на газетной полосе») монографиясендә, телдә яңа бер функциональ-стилистик бердәмлек формалашуы турында әйтелә. Әлеге яңа төшенчә массакүләм мәгълүмат чаралары телен өйрәнүче фәнни хезмәтләрдә бары тик узган гасырның 90нчы елларында күренә башлады. Шулай итеп, матбугат теле мөстәкыйль стиль буларак аерылып чыга. Бу – әдәби телнең публицистик стиле һәм массакүләм мәгълүмат чаралары теле тәңгәллеге проблемасын хәл итүнең өченче принцибы булып тора. Аның нигезендә массакүләм мәгълүмат чаралары теленә, шул исәптән газета теленә дә, тематик һәм стилистик күптөрлелек белән беррәттән, әдәби һәм сөйләмә тел үзенчәлекләре хас, дигән фикер ята.

Публицистик стиль һәм матбугат теле тәңгәллеге проблемасы белән бәйле югарыда китерелгән өч принциптан тыш, тагын бер яңарак фәнни карашның булуы да билгеле. Аның асылы газета телен матбугат теле кысаларында, ләкин әдәби тел системасында гына түгел, ә бәлки гомумхалык яки милли тел кысаларыннан чыгып өйрәнүдән гыйбарәт. Безнең фикеребезчә, югарыда күрсәтелгән барлык карашлардан үзенең яңалыгы, төгәллеге белән, нәкъ менә соңгысы аеруча игътибарга лаек. Бу хакта «Матбугат теле һәм сәясәт» («Язык СМИ и политика», 2012) исемле коллектив монографиядә

Г.Я. Солганикның сүзләрен үрнәк итеп китерергә мөмкин. Автор фикеренчә, матбугат теле, әдәби телнең функциональ-стилистик бүленешен инкарь итмичә, аның функциональ стильләре белән параллель рәвештә янәшә яши. Массакүләм мәгълүмат чаралары бүген функциональ стильләргә карата калыплашкан мөнәсәбәтне үзгәртүгә ирешә. Хәзер алар тел чараларының ябык бер системасы буларак түгел, ә мөстәкыйль тел – массакүләм мәгълүмат чаралары телен формалаштыру өчен нигез булып торган бер башлангыч буларак кабул ителә. Әлеге мөстәкыйль тел, яңа нигез буларак, әдәби тел стильләре һәм сөйләмә тел формаларыннан торган катлаулы күренешне барлыкка китерә [Язык СМИ…, с. 12].

Бүгенге көндә, газета теле әдәби тел стильләре системасы кысаларына гына сыешмыйча, рәсми телгә, сөйләмә телгә, шулай ук реклама һәм риторика жанрларына да мөрәҗәгать итә. Шундый ук вәзгыять XX гасыр башы татар газеты текстларына да хас. Бу, беренче чиратта, узган гасыр башында татар газетасы теленең һәм татар милли теленең бер үк вакытта параллель рәвештә формалашуы һәм үсеше белән бәйле. Төгәлрәк әйткәндә, милли телгә хас беренче сыйфатлар нәкъ менә газет битләрендә чагылыш таба.

Безнең фикеребезчә, массакүләм мәгълүмат чаралары теле, шул исәптән газета теле дә, әдәби телгә генә тәңгәл була алмый. Дөрес, вакытлы матбугат телендә әдәби телнең функциональ-стилистик төрлелеге чагылыш таба әлбәттә. Әдәби телгә хас барлык функциональ стильләр белән тыгыз мөнәсәбәттә булып, әлеге стильләргә хас булган үзенчәлекләрдән файдаланып, массакүләм мәгълүмат чаралары яңа чынбарлык тудырырга тырышалар. Матбугат телен милли һәм әдәби тел арасында бәйләнеш тудыра торган бер күпер буларак кабул итәргә мөмкин. XIX һәм өлешчә XX гасырларда әдәби тел үзенең бертуктаусыз барган үсешен тәэмин итү өчен диалектларга һәм сөйләмә телгә мөрәҗәгать итә. Әлеге процесста татар газетасы аеруча мөһим роль уйнаган. Күп кенә яңа күренешләр һәм аларны белдерә торган тел чаралары иң беренче чиратта нәкъ менә аның телендә пәйда булып, соңыннан гомумкулланылышка кереп киткән, язма норма дәрәҗәсенә күтәрелгән.

Биредә Г.Я. Солганикның сүзләрен китерү кызыклы булыр иде. Аның фикеренчә, массакүләм мәгълүмат чаралары теле – ул милләтнең уртачалаштырылган теле, ягъни милли телнең әдәби нормаларын формалаштыручы, сәясәтне, идеологияне, сәнгатьне, әдәбиятны кабул итүгә ярдәм итә торган бер моделе [Язык СМИ…, с. 859].

Мәгълүм булганча, татар халкы милләт буларак XIX гасыр урталарында формалаша башлый. XX гасыр башындагы 1905–1907 еллардагы буржуаз революция Россия мөселманнары арасында милли үзаңның үсүенә сәбәпче була. Нәкъ менә 1905 елда татар газетасы дигән күренеш барлыкка килә. Россиядәге беренче татар газеты дип «Нур» (1905–1914)

саналса, Казанда чыга башлаган беренче татар газетасы – «Казан мөхбире» (1905–1911) була. Шул ук вакытта, XX гасыр башларында татар милләте һәм милли тел формалашуның беренче баскычларын инде үткән була, әдәби тел белән сөйләмә телнең якынаюы күзәтелә башлый. Һәм татар халкының «уртачалаштырылган теле», безнең фикеребезчә, иң элек нәкъ менә татар газетасы телендә чагылыш таба да инде.

Әлбәттә, XX гасыр башы татар газетасы теле һәм татар әдәби теленең функциональ стильләре тәңгәллеге татар тел белеменең актуаль мәсьәләләре рәтенә кертеп каралырга лаеклы. Шул уңайдан, XX гасыр башы татар матбугаты теле һәм, аерым алганда, шул вакыттагы татар газеты теленең функциональ стильләр системасында тоткан урынын, яисә матбугат телен газета теле, радио теле, телевидение теле һ.б. кебек тармакларга бүленми торган аерылгысыз күренеш буларак өйрәнү кебек әлегә ахырга кадәр тикшерелмәгән фәнни мәсьәләләрне дә игътибарсыз калдыру дөрес булмас иде. Безнең фикеребезчә, югарыда әйтелеп киткәнчә, газета телен массакүләм мәгълүмат чаралары теле кысаларында радио теле, телевидение теле, интернет теле, һ.б. белән параллель рәвештә, ләкин әдәби телнең публицистик стиленең бер тармагы буларак түгел, ә бәлки гомумхалык яки милли тел кысаларында өйрәнү сорала.

**Әдәбият**

*Бәширова И.Б.* Татар стилистикасының теоретик нигезләре. Казан, 2005. 30 б.

*Бондалетов В.Д., Вартапетова С.С., Кушлина Э.Н., Леонова Н.А.* Стилистика русского языка. Л.: Просвещение, 1982. 286 с.

*Григорьева О.Н.* Публицистический стиль в системе функциональных разновидностей языка // Язык средств массовой информации: учеб. пособие. М., 2008. С. 355–366.

*Казак М.Ю.* Язык газеты. Белгород: ИД «Белгород», 2012. 118 с.

*Караулов Ю.Н.* Язык СМИ как модель общенационального языка // Язык средств массовой информации как объект междисциплинарного исследования: Тезисы докладов международной конференции. М., 2001. С. 15–18.

*Кожина М.Н.* Стилистика русского языка. М.: Просвещение, 1977. 223с.

*Одинцов В.В.* Стилистика текста. М., 2007. 264 с.

*Хаков В.Х.* Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. Казан: КДУ нәшр., 1972. 224 б.

Язык СМИ и политика / под ред. Г.Я. Солганика. М.: Изд-во Московск. ун-та; факультет журналистики МГУ имени М.В. Ломоносова, 2012. 952 с.

***Миңнуллин Бәхтияр Ким улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге мөдире*

УДК 811.512.145′367

*Г.Ә. Нәбиуллина*

# ТАТАР ТЕЛ ГЫЙЛЕМЕНДӘ ЭКСПРЕССИВ СИНТАКСИК ТӨЗЕЛМӘЛӘРНЕ ӨЙРӘНҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

В статье рассматриваются проблемы изучения эспрессивно-синтаксических конструкций в татарском языкознании; выделяются основные синтаксические конструкции, как повторы, номинативные предложения, присоединительные конструкции, инверсия, однородные члены предложения, в которых проявляется экспрессивность татарского языка.

**Ключевые слова:** синтаксис, татарский язык, экспрессия, синтаксические средства.

Хәзерге заман тел гыйлеме, белем алуның төрле юнәлешләрен исәпкә алып, аның когнитив һәм функциональ-коммуникатив якларына игътибар итә. Когнитив (ягъни кеше акылы, психологиясе үзенчәлекләренең тел белән бәйләнеше), икенче яктан, сөйләмнең акыл-зиһен процесслары белән бәйлеге ягыннан карап өйрәнелүе алгы планга чыгып, сөйләмнең белем алу, фикер йөртү, хәтердә калдыру процесслары белән бәйлелеге ассызыкланса, функциональ-коммуникатив аспект, тел берәмлекләренең төрле стильләрдә һәм өлкәләрдә кулланылышын, аралашу процессын оештырудагы үзенчәлекләрен өйрәнә. Бу җәһәттән, сөйләмне экспрессив яктан өйрәнү мәсьәләсе алгы планга чыга. Татар телендә эмоциональ-экспрессивлык төсмерен белдерүче синтаксик конструкцияләр әлегә кадәр җентекләп өйрәнелмәгән мәсьәләләрнең берсе булып тора.

Экспрессив (лат. exspressio) – тәэсирле, сәнгатьле дигәнне аңлата. Ул бердәнбер, реаль итеп субъектив дөньяны, андагы вакыйгаларны, кичерешләрне тасвирлап бирү алымы. Ул уй-фикерләрне, хис-кичерешләрне бик тә тәэсирле һәм калку итеп төрле сәнгатьле чаралар ярдәмендә гәүдәләндерә. Экспрессивлык әдәбиятның барлык чор, юнәлеш, метод һәм жанрлары өчен хас. Иҗтимагый-әдәби хәрәкәтнең аерым чорларында заман рухын оста, үткен, искиткеч сәнгатьле һәм тәэсирле итеп сурәтләгән экспрессив чараларга ихтыяҗ арта.

Тел белемендә экспрессивлык проблемасы үзәк мәсьәләләрнең берсе булып кала. Экспрессивлык проблемасы белән кызыксыну XIX йөз ахырларында башланып, хәзер дә дәвам итә. Бу юнәлештә эшләүче байтак галимнәрнең бихисап хезмәтләре дөнья күрде.

Телдә экспрессивлык чынбарлыкны субъектив аспектта кабул итү белән бәйле. Экспрессивлык ул сөйләүче тарафыннан фикерне аерып күрсәтү, эмоция һәм хис-тойгы белдерү, әйтелгән сөйләмне эмоциональ тулыландыру, нинди дә булса бәя бирү,

образлылыкка ирешү, эстетик тәэсир итү аша бирелә.

Татар тел белемендә эмотив чараларны тикшерүгә багышланган беренче мәгълүматларны Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы»нда очратырга мөмкин. Автор әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре арасында аерым аһәң һәм тавыш белән әйтелә торган өндәү һәм үкенеч җөмләләренә игътибар итә. Мәсәлән, «*Ах, бу матур, айлы кичләр!*» Үкенеч җөмләләре исә сузып-сузып, кайгы тавышы белән әйтеләләр: «*Ах, нигә генә килдем икән монда!*» [Алпаров, б. 287].

В. Хангилдин «Татар теле грамматикасы»нда исә телдә эчке кичерешләр, тойгы белдерүнең ике чарасын аерып күрсәтә – интонация һәм махсус сүзләр. Интонация өндәү җөмләдә көчле тойгылар, кичерешләр белдерү чарасы буларак карала. Махсус сүзләр дигәндә, ымлыклар һәм «шулар функциясен үти ала торган сүзләр» күз алдында тотыла. *«Әй, аңламыйсың син, дустым, диңгезченең йөрәген!»* (Г. Әпсәләмов) *«Әһә, син шундый кешемени әле?!»* (К. Нәҗми) [Хангилдин, б. 644].

Экспрессия белдерүнең синтаксик юллары М. Зәкиевның «Синтаксический строй татарского языка» дигән монографик хезмәтендә дә аерым игътибар бирелә. Эмоциональлек төшенчәсе сөйләмгә хас үзенчәлек буларак модальлек эчендә карала. Автор экспрессия белдерү чараларын әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләренә (тойгылы җөмләләргә) һәм җөмләнең модаль кисәкләренә (эндәш һәм кереш сүзләргә) бәйле рәвештә бирә [Зәкиев, б. 464].

70 нче елларда татар тел белемендә экспрессив төзелмәләр стилистик чара буларак өйрәнелә башлыйлар. Х. Курбатов «Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы» дигән хезмәтендә, сөйләм стильләренә бәйле рәвештә, беренчеләрдән булып «экспрессив сөйләм» дигән термин куллана. Автор, экспрессия белдерү чаралары буларак, эллипс *(«Китәм. Мәскәүгә. Госпланга чакырдылар. Доклад белән.»* (И. Абдуллин), әйтеп бетермәү *(«Әллә инде... Әллә инде ул хатларның хуҗасы Мөнир микән?»* (Р. Төхфәтуллин) һәм инверсия (*«Көлдер үзләрен бер, рәхәтләндер!»* (И. Гази) күренешләренә туктала [Курбатов, б. 192].

Татар тел белемендә экспрессив төзелмәләрне синтаксик планда беренчеләрдән булып җентекләбрәк Ф.С. Сафиуллина тикшерә башлый. «Татар телендә сүз тәртибе» хезмәтендә галимә болай дип яза: «Өстәлмә конструкцияләр сөйләмнең экспрессивлыгын арттыра, мәгънәне калкуландыра. Текстның шундый төзелмәләргә байлыгы үзенчәлекле (“рубленый”) синтаксис тудыра» [Сафиуллина, б. 154]. Автор сүз тәртибен эмоция белдерүнең иң әһәмиятле чараларыннан берсе дип билгели, экспрессия белдерү өчен хезмәт итә торган сүз тәртибенә нигезләнгән стилистик чараларны аерып күрсәтә: хиазма, боҗралы кабатлаулар. Мәсәлән, *«Караңгы тын урамнардан тып-тын гына* ***тамчылар тама.*** *Күңелемә нидер*

***әйтмәкче**, нәрсәнедер **искә төшермәкче була бу тамчылар»*** (Ә. Еники), «***Искерер** җирдәге күп нәрсәләр, Хаттагы сүзләр дә **искерер»*** (С. Хәким). Ф.С. Сафиуллина фикеренчә, күзаллауны белдерүче баш килеш шулай ук сөйләмнең тәэсирлелеген, эмоциональлеген, экспрессивлыгын арттыра. Мәсәлән, ***«Рәшидә... Рәшидә!** Күпме мөлаемлык, җылылык, нәфислек, хәйләкәрлек, иркәлек бөркелеп тора **ацардан**.»* (Ә. Еники); ***«Әдәбиятның үткәне...** Тәнкыйть ярдәмендә мин **аның** зурлыгын тоярга телим»* (С. Хәким)

Ф.С. Сафиуллинаның «Синтаксис татарской разговорной речи» хезмәтендә хис-тойгы белдерүнең түбәндәге синтаксик чаралары тикшерелә: кабатлау алымы, эллиптик конструкцияләр, раслау һәм инкарь җөмләләрнең аерым төрләре, өстәлмә конструкцияләр (парцелляция). Мисаллар: *Венера... Венера дип кенә дәшәргә сөйләшкән идек бит инде. Ходайбирдин. Венерасын Венера, иптәш Котбетдинова, ләкин мин бүген сезнең белән чынлабрак сөйләшергә телим* (М. Әмир) [Сафиуллина, б. 254].

Өстәлмә конструкцияләр – тел белемендә шактый бәхәсләр уяткан, күпьяклы күренеш. Кайбер телче галимнәр аларны *синтаксик берәмлек* (К. Сабиров, М.З. Зәкиев), әдәби әсәр телен өйрәнүчеләр аларны поэтик синтаксис кысаларында *стилистик алым* (В.В. Виноградов, Г.С. Шалимова), экспрессив синтаксис исә өстәлмә конструкцияләрне хис-тойгы белдерү *чара*сы буларак өйрәнә.

Әдәби текстның тәэсирлелеген көчәйтү өчен, телнең синтаксик берәмлеген, сүзтезмәләрен һәм җөмләләрнең төрле структур, мәгънә һәм интонация үзенчәлекләре кулланыла. Шулай ук текстның композицион төзелеше, аларның абзацларга бүленеше һәм пунктуацион ясалышы да зур роль уйный.

Экспрессив синтаксисның төп чаралары булып түбәндәгеләр санала:

1) җөмләнең синтаксик структурасы һәм тыныш билгеләре;

2) махсус синтаксик тәэсирлелек чаралары (атау җөмләләр, өстәлмәләр);

3) текстның композиционсөйләм ясалышы ягыннан үзенчәлекле ысуллары (эчтәлекнең сорау-җавап формасы, кыек, туры сөйләм, цитаталау һ.б. ысуллар).

Лексикадан аермалы буларак, матур әдәбият текстында эмоциональ-экспрессив чаралар барлыкка китерүче булып поэтик синтаксис та зур роль уйный. Шуңа күрә дә синтаксик берәмлекләрнең матур әдәби образлар тудырудагы роле аерым игътибарга лаек. Проза әсәрләрендә синтаксик конструкцияләрнең төрле типлары катлаулы фикер сөрешен, кичерешләрне, аларның чагылышын, нюансларны күрсәтергә сәләтле, шулай ук ул үзенчәлекле итеп автор интонациясенең кызыклы якларын да ачып бирергә ярдәм итә. Алай гына да түгел, текстта сурәтләнгән мәгънәне автор әйтергә теләгән фикер белән кушып күрсәтергә дә сәләтле.

Телдә экспрессивлык чынбарлыкны субъектив аспектта ка-

бул итү белән бәйле. Аның нигезендә өстәмә мәгънә төсмерләре ята. Экспрессивлык төрле алым һәм чаралар белән белдерелә. Алар телнең төрле яссылыкларында – фонетикада, лексикологиядә, грамматикада табыла. Синтаксик чаралардан эндәш, кереш сүзләр һәм конструкцияләр, тиңдәш кисәкләр, кабатлаулар, бер составлы җөмләләр, җыйнак җөмләләр, инверсия һ.б. эспрессивлыкны чагылдыруда катнашалар.

Матур әдәбият әсәрләре телендә бигрәк тә атау җөмләләргә зур сурәтләү мөмкинлекләре салынган. Матур әдәбият телендә кыска, җыйнак җөмләләрнең кулланылышы да аклана. Берсе артыннан берсе тезелеп килеп, алар сурәтләнгән күренешләргә җанлылык, динамизм өстиләр һәм шул рәвешле текстның экспрессивлыгын арттыралар.

Кабатлаулар шулай ук тәэсирлелекне арттыруда катнашалар. Тәэсирлелек экспрессивлыкның мөһим элементы санала. Кабатлаулар үзенчәлекле яңгыраш, эмоциональ бизәк, мәгънәви басым ясауда ярдәм итәләр. Кабатлаулар контекстка ниндидер моң, шигърилек өсти кебек.

Тиңдәш кисәкләр дә сәнгатьлелекне көчәйтүче чаралардан саналалар. Алар ниндидер күренешне төгәлрәк, конкретрак, калкурак итеп күрсәтүдә алыштыргысыз роль уйныйлар.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, экспрессивлык, барыннан да элек семантик категория. Чөнки сүздә экспрессивлыкның барлыкка килүе һәрвакыт мәгънә күләменең киңәюенә һәм катлаулануына китерә, өстәмә, икенчел дәрәҗәдәге мәгънә төсмерләрен тудыра. Эмоциональлек исә экспрессивлыкның иң мөһим элементы санала. Аларның берсен икенчесеннән аерып та булмый.

Сөйләмне тәэсирле, тирән мәгънәле итүче, фикерне калкурак күрсәтүче чаралар, хискә һәм тойгыга бай сүзләр эмоциональ-экспрессив лексиканы тәшкил итәләр. Эмоциональ-экспрессив чаралар өстәмә мәгънәләре һәм хис-тойгыга бай булулары белән аерылалар, фикерне ачык, төгәл итеп җиткерүгә хезмәт итәләр.

**Әдәбият**

*Алпаров Г.* Шәкли нигездә татар грамматикасы. Казан: Мәгариф, 2008. 287 б.

*Закиев М.З.* Синтаксический строй татарского языка. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1963. 464 с.

*Курбатов Х.Р.* Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. 192 б.

*Сафиуллина Ф.С.* Синтаксис татарской разговорной речи. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. 254 с.

*Сафонова С.С.* Язык современной прессы: экспрессивные синтаксические конструкции. Казань: Магариф, 2006.

*Хангилдин В.* Татар грамматикасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 644 б.

***Нәбиуллина Гүзәл Әмир кызы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университеты доценты*

УДК 811.512.145′373

*Д.Б. Рамазанова*

# ТАТАР-МОНГОЛ УРТАК ЛЕКСИКАСЫ ТУРЫНДА

В современном татарском языкознании исследование татаро-монгольских параллелей в области лексики является одним из актуальных направлений. Ряд ученых считают татарский и монгольский языки родственными. Другие же придерживаются мнения о том, что татаро-монгольские параллели являются результатом многовековых контактов двух народов и взаимовлияний их языков. В статье рассматриваются различные аспекты и подходы в исследовании данного вопроса.

**Ключевые слова:** лексика татарского языка, татаро-монгольские параллели, монгольские языки, общеалтайское единство, историко-генетический анализ.

Татар теле лексикасының формалашуы һәм үсеше турында тикшеренүләр алып барганда, татар-монгол янәшәлекләре (параллельләре) мәсьәләсенә дә кагылмыйча булмый. Татар һәм монгол телләрен дә бертөркем галимнәр тугандаш дип саныйлар (мәсәлән, Г.И. Рамстедт, Н.Н. Поппе һ.б.), икенче бер төркем галимнәр бу фикергә каршы төшәләр, татар һәм монгол янәшәлекләренә әлеге ике халыкның кайчандыр озак еллар буена сузылган контактта булу, үзара тәэсир итешү нәтиҗәсе дигән фикердә торалар. Соңгы елларда археологик материалларны гомумиләштерүгә багышланган хезмәтләрдә дә шундыйрак фикер уздырыла. Мәсәлән, күренекле тарихчы И.Л. Кызласов «...археологический материал в целом отрицает изначальное единство тюркских народов с монгольскими и тунгусо-маньчжурскими. Археология встает на сторону тех лингвистов, которые видят в близости алтайских языков результат контактов, не связанных с изначальной общностью происхождения», – дип яза [Кызласов, 2008].

Татар-монгол янәшәлекләренә кагылышлы кайбер мәсьәләләр фәндә кузгатылган. Мәсәлән, шундыйлардан Б.А. Серебренников һәм С.С. Харькtotаларның мәкаләсе зур игътибарга лаек.

Төрки телләрнең сүзлек составы үсә-үзгәрә баруын өйрәнгәндә төрки-монгол контактлары тарихын өйрәнү бик кирәк. Кызганычка каршы, бу мәсьәлә күп кенә галимнәр тарафыннан күтәрелеп чыккан булса да, әлегә аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе булып кала килә [Дыбо, 1996].

Монда берничә үзәк аспект калкып чыга: гомумалтай берлеге нинди характерда булган: генетик характердамы, әллә алтай төркеменә керә торган телләр билгеле бер чорда озакка сузылган үзара бәйләнеш-тәэсир итешүләр рәвешендәме. Билгеле, биредә бу мәсьәләләрне хәл итүгә һич тә алынмыйбыз, әмма аларга караган кайбер тирән тикшеренүләрне бераз күздән

кичерү һәм шуларда чагылыш тапкан төрки (татар)-монгол янәшәлекләрен билгеләү татар теленең сүзлек составы формалашу тарихы мәсьәләләренә кайбер штрихлар сызарга мөмкинлек бирер кебек.

Югарыда, гомумалтай чоры лексикасына кагылышлы хезмәтләргә берникадәр күзәтү ясаганда, әлеге мәсьәләләр белән шөгыльләнгән галимнәргә бераз тукталган идек. Биредә татар теленең монгол телләре белән уртак лексикасын өйрәнүдә безнең тема өчен аеруча әһәмиятле булган моментларны билгеләп үтәргә кирәк. Конкрет шушы мәсьәлә белән кызыксынып тикшеренүләр уздырган берничә галимнең хезмәтләрен хронологик планда карап үтик.

Тел белемендә лаеклы эз калдырган алтаист Ж.Г. Киекбаев (1968) башкорт теленең лексикасын һәм аның чыганакларын өйрәнүне гомумалтай берлеге чорыннан башлый. Билгеле булганча, башкорт теле татар теленә иң якын торган тугандаш төрки тел, башкорт телендәге тунгус-маньчжур һәм монгол телләре белән уртак сүзләр, нигездә, татар теле лексикасына да карый (дөрес, аларның фонетик яңгырашларында һәм мәгънә төсмерләрендә берникадәр үзенчәлеклелек тә чагылыш таба). Тунгус-маньчжур һәм монгол телләре белән тарихи яктан уртак булган сүзләр татар лексикасының да төп сүзлек фондына карыйлар.

Ж.Г. Киекбаев үзенең хезмәтендә тунгус теле белән уртак 23, монгол һәм бүрәт телләре белән уртак 21, монгол теле белән уртак 46 башкорт сүзен эченә алган таблицалар [Киекбаев, б. 94, 95, 95–96] китерә, аларның борынгы (V–VIII гасыр), төрки язма истәлекләрнең теле өчен дә характерлы булуына басым ясый. Шулай да борынгы төрки лексиканың хәзерге бөтен җанлы төрки телләрдә тигез таралмаган икәнен искәртә, төрле (казакъ, чуаш, татар) төрки телләр белән чагыштырулар уздыра.

Шулай итеп, Ж.Г. Киекбаев монгол телләре белән уртак сүзләрне гомумалтай берлеге чорыннан килә торган төп башкорт сүзләрен тәшкил итәләр дип билгели [Киекбаев, б. 96–104].

А.Х. Нуриева (1975) татар телендәге монгол теле белән уртак сүзләрне, югарыда күрсәтеп үткәнчә, монгол алынмалары дип атый, татар теленең лексикасын чыганаклар буенча төркемләгәндә, монголизмнар дигән төркемне дә рус, гарәп-фарсы һ.б. алынмалар рәтендә аерып атый [Нуриева, б. 9, 10]. Әмма автор теге яки бу телнең «үзәген яки төп фондны» аерып чыгара, һәм аны хаклы рәвештә гомуми сүзлек составына каршы куя.

Автор гомумалтай катламны тикшергәндә, әлеге катламның аерылгысыз өлеше итеп монгол теле белән уртак лексиканы да тикшерә. Ул, лексика гына түгел, уртак фонетик, грамматик күренешләрнең дә өйрәнелүе алтай телләренең генетик кардәшлеген тануга китерә дигән караштa тора, әмма алтай телләренең тарихи фонетикаларының да, тарихи грамматикаларының да нигез тел дәрәҗәсендә эшләнмәгән булуын ассызыклап үтә.

А.Х. Нуриева татар-монгол параллельләрен төрле башка төрки телләр белән дә чагыштырып анализлый. Ул татар-монгол янәшәлекләрен чагылдырган таблица төзи, анда төрле тематик төркемгә караган 15 сүз кителгән [Нуриева, б. 19]. Шунда ук монгол-казакъ-татар лексик янәшәлекләреннән 12 сүзне чагылдырган таблица да бирелгән [Нуриева, б. 19], 6 сүзне эченә алган таблица монгол-якут-чуваш-татар лексик янәшәлекләреннән тора.

А.Х. Нуриева тагын татар һәм монгол телләрендәге бер үк тамырдан ясалган сүз ояларын да анализлый. Мәсәлән, ике телдә дә *каты, кисәк, чак* (*чакма, чагылу* һ.б.) тамырларыннан барлыкка килгән шактый бай төркемнәр формалашкан. Кайбер тамырлардан я монгол, я татар телләрендә бай оялар ясалган. Мәсәлән, монгол телендәге *ца-* (ак) тамырыннан ясалган сүз оясы, татар телендәге шул ук тамырдан ясалган сүзләр (*сыкы, чал, чык, чаган*) оясы белән чагыштырганда, күпкә баерак.

Шулай итеп, А.Х. Нуриева татар һәм монгол телләре өчен уртак лексиканы төрле яклап тикшергән һәм кызыклы күзәтүләр язып калдырган. Ул монгол-татар лексик параллельләрнең саны меңнән артып китә [Нуриева, б. 20] дип яза.

А.Х. Нуриева татар телендә монгол алынмалары мәсьәләләрен дә тикшерә. Ул аларны татар-монгол лексик уртаклыкларының икенче төркеме дип аерып карый, хаклы рәвештә монгол яулап алулары, аларның Идел буйларында шактый озак идарә итүләре белән бәйләп карый. Бу төркем, нигездә, хәрби, хокук, титулатура, канцелярия һ.б. шундый өлкәләр белән бәйле атамаларны тәшкил итәләр һәм дәверләр үтү белән алар тарихи сүзләр рәтенә күчкәннәр, яки архаиклашканнар. Мәсәлән, *даруга* – башлык, командир, *нүкәр/нөкөр* – тат. диал. *кийәнүгәр* – кияү егете, *улус* – улыс, район, *сойурган* – бүләк, *каравыл*, *туткаул, букаул, сүткүл* – болар төрле титуллар һ.б.

Монгол теле белән уртак сүзләрне төрле тарихи чорлар белән бәйләп карарга кирәклеген Р.Г. Әхмәтьянов [Әхмәтьянов, 2003, б. 43–50, 144], Туймебаев (2008) кебек галимнәр дә фәнни нигезлиләр.

Башкорт теле лексикасының тарихи үсешенә багышланган хезмәтендә Э.Ф. Ишбердин (1986) башкорт һәм монгол телләре арасындагы лексик бәйләнешләргә махсус тикшерү уздыра. Төрки һәм монгол телләренең тугандашлыгы мәсьәләсе бәхәсле булганга күрә, автор башкорт һәм монгол телләрендәге соңгырак чорда кергән алынмаларны аерып чыгару зарури дип ассызыклый. Автор фикеренчә, моның өчен теге яки бу төрки телләрдәге монгол сүзләренең таралыш киңлеге чикләнгән булса, башка төрки телләрдә булмаса һәм борынгы төрки язма истәлекләрдә чагылмаса, алар соңгы чордагы (мәсәлән, монгол яуларыннан соң) кергән монгол алынмалары булып торалар. Мәсәлән, татар теленең Урал төбәге сөйләшләрендәге *конаҗың* – өченче

яшенә чыккан сыер, *дебә* (кабыргасы) – ялган кабырга, *нөгәр/нәгәр* – кияү егете, *әҗегәй* – корт, *самай* – үсеп җиткән, балигъ булган; чигә һ.б.

Төрки телләрдәге, шул исәптән татар телендә дә, яңа монгол алынмаларын аваз тәңгәллекләре нигезендә дә чамалап була. Мәсәлән, **х ~ к:** монг. *хэсэг* – өлеш, тат. *кисәк*; *тах – дага*, тат. дага; *хялгана* – кылган, тат. *кылган*; *хир* – пычрак, тат. *кер*; **з ~ р:** монг. *үхер* – мөгезле эре терлек, тат. *үгез*; *берүү* – бер яшьлек үгез, тат. *бозау*; **ш ~ л:** монг. *танил* – таныш, дус, тат. *таныш*, *холи* – кушу, болгату, тат. *кушу, залуу* – яшь, егет, тат. *яшь* һ.б. **у, ү ~ о, ө:** монг. *шог* – шаярту, шаянлык, тат. *шук* – шаян һ.б.; *төс(он)* – тузан, тузан бөртеге, тат. *тузан, зурх(эн)* – йөрәк, тат. *йөрәк*, *тором* – торма, тат. *торма* һ.б.

Монгол алынмалары структур яктан, грамматик күрсәткечләр белән дә аерылырга мөмкин. Мәсәлән, *-тай/-тәй* кушымчалы сүзләр: *түбәтәй, иркәтәй* – иркә, узынган, *сакалтай* – тат. сакаллы, *корылтай* һ.б.

Татар теленә, гомумән төрки телләргә хас *-чы/-че, -ык/-ек, -ак/-әк/-к* кушымчалары монгол телендә берникадәр үзгәрешләр кичерәләр: монг. *төмөрч(ин)* – тат. *тимерче, авчин – аучы, хайч(ин)* – кайчы һ.б.

Татар һәм монгол телләре өчен уртак булган сүзләр семантик яктан да төрлелек күрсәтә. Аларның бер төркеме мәгънәләре белән тәңгәл булырга мөмкин: *җәй~зун, хар~кара, бул~боло, чәчәк~цэцэг, кабырга~хавигра, күк~хөх (төс)* һ.б. Мәгънәләре һәм закончалыклы аваз күчешләренә туры килгән, фонетик яклары да тәңгәл килгән, татар һәм монгол телләре өчен уртак чыгышлы сүзләр әлеге телләрнең генетик тугандашлыгын раслау өчен әһәмиятле материал булып торалар.

Шул ук вакытта, бер төркем уртак сүзләрнең татар һәм монгол телләрендә мәгънәләре өлешчә генә тәңгәл килергә мөмкин. Мәсәлән, монг. *талх(ан)* – икмәк, тат. *талкан*, *тухал* – бозау, тат. диал. *тукал* – мөкләк, *салхи(н)* – җил, тат. *салкын*, *зус* – бит төсе, тат. *йөз* – бит, чырай, *арвай* – арпа, тат. *арпа* – 1) арпа (ашлык), 2) арпа (күзгә чыккан шеш), *мал* – терлек, тат. *мал* – терлек, мөлкәт, байлык һ.б.

Б.А. Серебренников һәм С.С. Харьковалар шушы мәсьәләләргә багышлаган мәкаләләрендә (Советская тюркология. 1983. № 5) татар-монгол телләре өчен уртак булган лексиканы аерым төркемнәргә бүлеп карыйлар.

Алар бер төркем сүзләр монгол теленә төрки телләрдән чагыштырмача күптән түгел генә (ике мең елдан артык түгел) үтеп кергәннәр, дип билгелиләр: *авыл, алтын, балта, бака, беләү, бук, болак, ел, җимеш, макта-, урын, сакла-, сул, сукыр, таяк, тимер, диңгез, тәкә, сал, дала, ту* (әләм), *мал, бал, тара(л)-, күк* (зәңгәр), *дага, тукта-, сирәк, капк(ан), карчыга, таны-, ала, кабырга, кайчы, кара* (черный), *кара-, кычкыр-* һ.б. Авторлар әлеге сүзләрнең монгол эквивалентларының архетип вариантларын торгызуда роль уйный алмауларына да игътибар итәләр һәм әлеге факт китерелгән сүзләрнең

монгол телендәге төрки алынмалары икәнлегенә бер дәлил булып тора, дип күрсәтәләр.

Авторлар төрки-монгол янәшәлекләрендәге кушымчаларның («суффикслар» – Б. Серебренников һәм С.С. Харькова) монгол телләренә хас суффикслар системасын чагылдырмауларына басым ясыйлар һәм әлеге күренеш шулай ук төрки-монгол янәшәлекләренең монгол телендә төрки алынмалар икәнен раслый, дип күрсәтәләр. Мәсәлән, калмык телендәге *зармм* ‘ярма’ сүзе составындагы *-м* элементы төрки *-ма* кушымчасына кайтып кала. Бу кушымча монгол телләренә хас түгел, ә төрки телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, киң таралган. Төрки-монгол параллельләренең бер төркемендә *-ык/-ек, -ч, -кы, -ки, -әк* һ.б. шундый элементлар чагылыш тапкан: *бүлэг* – тат. ‘бүлек’, *кесг* ‘өлеш’ һ.б. сүзләрдә төрки телләрдә бик актив булган сыйфат һәм корал исемнәрен белдерә торган, ләкин монгол телләренә хас булмаган *-ык/-ек, -кы, -ки, -әк, -к* кушымчалары сакланган һ.б.

Монгол телендәге төрки-монгол параллельләре арасында семантик яктан үсеш-үзгәреш кичермәгән, тар мәгънәдә кулланыла торган, ягъни алынма икәнлекләре бәхәс тудырмый торган лексемалар бар. Мәсәлән, монг. *ширэ-*, төрк. *сыр-* ‘сыру’, монг. *эрт*, төрк. *иртә* һ.б. сүзләр шундыйлардан.

Авторлар А.Б. Серебренников һәм С.С. Харькова монгол телләрендә ротацизм һәм ламбдаизм күренешләре булмаган, алар бары төрки-монгол параллельләрендә генә күзәтелә, дип язалар. Конкрет материаллар өстендә анализ ясаганнан соң, авторлар ротацизм һәм ламбдаизм билгеләре булган сүзләр монгол телләренә чуваш тибындагы төрки телдән кергәннәр дигән фикергә киләләр [Серебренников, Харькова, б. 55].

Сүз уңаенда күрсәтеп үтик, Ж.К. Туймебаев та монгол телендәге ротацизм һәм ламбдаизм күренешләрен монгол теленә чувашоид характердагы төрки телнең тәэсир итү нәтиҗәсе дип саный [Туймебаев, 2008]. Автор төрки телләрдәге монголизмнарны һәм, киресенчә, монгол телләрендәге төрки алынмаларны ачыклау өчен фонетик критерийлар кирәк дип яза. Мәсәлән, аныңча, монгол телендәге төрки алынмаларга ротацизм һәм ламбдаизм күренешләре булган сүзләр керә: *culun, üxer* сүзләре, *tas, ükïs* дип әйтелә икән, димәк алар стандарт типтагы төрки телләрдән кергән сүзләр булып торалар.

Б.А. Серебренников һәм С.С. Харькова мәкаләсендә чыгышлары белән бабатөрки телгә барып тоташа торган төрки-монгол параллельләре дә бүлеп чыгарылган: *тиң, яр-, ярык, асрай, көч, аяк* (нога), *кук* (зәңгәр), *ала, җилен, тукта-, сукыр, макта, ел, көрәк* һ.б. [Серебренников, Харькова, б. 55].

Мәкаләдә төрки-монгол параллельләренең төп сүзлек фондына керә торганнары да аерып күрсәтелә; билгеле булганча, алар бик борынгы чордан ук килергә мөмкин. Алар төрки һәм монгол телләренең генетик тугандашлыгы мәсьәләсендә ыша-

нычлы дәлил була алалар. Мәсәлән: *ала, яка, сакал, кем, бака, кара* (черный), *кабырга, кычкыр-, дала, тукта-, күк* (синий), *сирәк, сукыр, таяк, бусага, көч, ару* (чиста), *алыс, түлә-, түгәрәк, маңгай, кара-, болак, бөклән-* һ.б.

Төрки-монгол параллельләре мәсьәләсен өйрәнү дәвам итә.

Шундыйлардан Ж.К. Туймебаевның төрки-монгол лексик параллельләрне тарихи-генетик чикләүнең теоретик принциплары һәм критерийлары турындагы тикшеренүләре зур кызыксыну уята. Автор казах телендәге һәм шулай ук күпчелек башка төрки телләрдәге монгол теле белән уртак сүзләрнең зур өлеше монголларның төркиләр тарафыннан ассимиляцияләнүе нәтиҗәсендә барлыкка килгәннәр дигән нәтиҗәгә килә. Ул монгол телендәге терлекчелек, җир эшкәртү тармакларына караган сүзләр төрки чыгышлылар дип күрсәтә [Туймебаев, с. 17].

Э.Ф. Ишбердин да үзенең башкорт-монгол лексик янәшәлекләрен җентекле анализлауга багышланган хезмәтендә монгол теленә төрки телләр йогынтысы мәсьәләсенә дә тукталып үтә. Шундыйлардан мисал итеп *хуймаг* – тат. коймак, *оточ* (врач) – тат. утчы (ут – үлән, *утчы* – дәвалаучы, имче), *хавхан* – тат. капкан, *отор* – терлекне еракта урнашкан көтүлекләрдә көтү – тат. утлавык (утар, утлык һ.б.), *зэрлэглэ* – тат. җирләү сүзләрен күрсәтә, ә монгол телләрендә әлеге сүзләрнең тамыр формалары сакланмаган, димәк аларның төрки телдән кергән икәнлекләре турында фикер йөртергә мөмкин [Ишбердин, б. 39]. Э.Ф. Ишбердин, башкорт-монгол янәшәлекләрен анализлагач, алар я уртак генетик чыгышлы, яисә бик борынгы чордагы (контактлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән булырга мөмкин, дип фараз итә [Ишбердин, б. 40].

Р.Г. Әхмәтьянов татар терминологиясенең тарихи чыганакларына багышланган хезмәтендә дә татар һәм монгол телләренең үзара мөнәсәбәте, бигрәк тә аларның лексик составлары мәсьәләләрен дә кузгата. Аның күзәтүләренчә, «Алтын Урданы нигезләүчеләр монголлар булсалар да, шул чорлардан калган культура һәм дәүләтчелек терминнарында монгол сүзләре артык сизелми» [Әхмәтьянов, 2003, б. 144]. Ул түбәндәге сүзләрне китерә: *каравыл, ясавыл, алпавыт* (монг. кушымч. *-уыт, -агут*), *арчи, әртил* (артыл, артавыл), *бирән* (мишәрләрдә «якын кардәш» мәгънәсендә), *байтал*, *конан*, *дүнән, субагай, җирән, чаптар* (ат билгеләмәләре), *маңгай, кабырга, себә* (тән әгъзалары), *канҗырга* (ияр киндерәсе), *бөлдерә, бөлдеркә* (чыбыркы элгече), *катау* (түгәрәк ныгытма), *калкан*, *кавырсын*; *бөркет*, *кияү*, *кода*, *кодагый*, *койты* (монголча *куйту* – түбәнлекле, *куйи* – түбән, *-ту* – монгол кушымчасы), *мендәр* (*-дәр,* монголча *мендәр, менгедәр* – артка менү өчен мендәр), *мөлҗәл* (мочал), *буат* (60 еллык цикл), *нарат* (монголча «кызыл агач, кояшлы агач»), *нөгәр* (тат. диал. нәгәр), *каудан, каудар* – былтыргы үлән калдыгы, *сөлтәр* – скелет, талда (юаныч мәгънәсендә, монголча *дал* – арка, тыл, далда – арка таянычы), тутай (монголча

*тоотай* – аристократ, сайланмыш); *үгәй* (чагыштыр.: үксез), *комагай* (чагышт.: комсыз), *җилбәгәй* (чаг: җилсез) – бу сүзләрдә -*сыз*/-*сез* мәгънәсендәге монгол кушымчасы *-гуй, -гәй* сакланган; *чаган* (монголча *цагаан үлтэнэг* – ак юкәле агач), *чандыр* (монголча *чандагар* – сөякләч), *чибәр* (монголча *чэгэбэр, цэгэбэр* – ап-ак, чиста, матур), *чолан* (монголча: җыелу урыны), *әгерҗе* (әче камыр, монголча – ачы, әче тамырыннан). *Калау* – костер, учак, *чүгәтә* – борынлы савыт, *кобага* һ.б. кайбер сүзләрне дә автор монгол сүзләре рәтенә кертә [Әхмәтьянов, 2003, б. 145]. Мисаллардан күренгәнчә, китерелгән сүзләр төрле өлкәләргә карыйлар, автор аларны очраклы характерда төрле шартларда үтеп кергән дип тә атый, алар арасында иҗтимагый характерда булганнары, мәдәнияткә караганнарының чагыштырмача аз булуларын да билгели. Р.Г. Әхмәтьяновның мондый фактлардан татар халкының этногенезына монгол токымының катнашы бик аз булуы аңлашылса кирәк, дигән фикере безнеңчә дә дөреслеккә туры килә. Югарыда китерелгән сүзләр арасындагы *кияү*, *кода*, *кодагый* лексемалары ностратик *koda* сүзенә кайтып калалар, ләкин аларның функцияләре әле тунгус-маньчжур телләрендә дә (ягъни, бабаалтай чорында да) конкретлашып бетмәгән булган. *Қодагай* сүзе исә монгол җирлегендә (-*гай* кушымчасы белән) ясалган һәм чагыштырмача яңарак сүз булса кирәк.

Күрше төрки телләрдә (башкортларда, чувашларда) монгол сүзләре күбрәк күзәтелә дип санайлар. Чыннан да, татар һәм монгол телләре өчен уртак сүзләр арасында Р.Г. Әхмәтьянов күрсәткән *конан, дүнән, субагай, себә, мөлҗәл* һ.б. сүзләр татар теленең башкорт ареалында формалашкан сөйләшләрендә генә күзәтеләләр (ТТЗДС), аларны татар теле өчен хас дип әйтеп булмый.

Р.Г. Әхмәтьянов та, венгр галимнәренең карашын җөпләп, төрки телләрдәге монгол сүзләренең күпчелеге Чыңгыз яуларына кадәр үк алынганнар» дигән фикердә тора [Әхмәтьянов, 2003, б. 145].

Төрле этимологик һәм башка сүзлекләрендә Р.Г. Әхмәтьянов түбәндәге лексемаларны монгол сүзләре дип күрсәтеп үтә (2001, 2005 һ.б.).

Туганлык атамалары: *кинҗә, кода, кодагый, тэнэкә* (принцесса), *тутай, туташ.*

Кешенең тән төзелеше*: корчаңгы, сару кайнау, сипкел, субагай, чуан, яурын.*

Кешенең эшчәнлеге: *киги, корыч, кишәрлек, көлтә, көрәк, кура, сыр, талкы, тап(чык), тәләкә, тәңкә, точ (бронза), тугым, тулка, түмәр, түтәл, чапчак, чолан, чүкеч, көрчек, төркем, чи.*

Кешене бәяләү: *таркау, койты, комагай, комсыз, наян, табалау, телмәр, тискәре, чандыр, чибәр, чуар, шәмәй, шелтә, ябагай, ялагай.*

Рухи мәдәният: *нәгәр, шобага*. Бабаалтай телендәге аллалар понтеонында төрки материалның аз чагылуына игътибар ителде (тиешле бүлекне кара).

Йорт кирәк-яраклары: *чөмәк*/*че(ө)мәк, тарак,ч үгәтә.*

Кием-салым: *тасма, томар, турка, түбәтәй, чәмчә, яка.*

Аш-су: *көртә, көлчә, тукмач.*

Хайваннар: *керәшә, кисәрткә, күлем (көл – җиргү), өер, суер, таракан, ташбака, ту I, үрчү, чаптар, чөелдерек.*

Үсемлекләр: *нарат, серкә II, суган, чаган, чәкән I.*

Табигать: *көрт* (шуннан: көртлек – кош исеме), *чүл, күкрәү, чуак.*

Без дә биредә бер никадәр өстәмә материаллар тәкъдим итәбез.

Бер төркем сүзләр монгол һәм төрки, шул исәптән татар телләрендә билгеле:

| татар | монгол | тәрҗемә |
|---|---|---|
| тансык | тансаг | тәмле |
| комсыз | хомхой | саран |
| караңгы | харанхуй | караңгы |
| коры | хурай | коры |
| кирәк | хэрэгтэй | кирәк |
| йылдам | жалдам/жилдәм | оста чаңгычы |
| масай – борын күтәрү | маасай | шатлан, елмай |
| бас | босо | бас, тор, күтәрел |
| буйа | буда | буя |
| бәйлә | багла | бәйлә |
| чүке | цохи | сук, бәр, төй |
| сук | сукы | чукы (клевать) |
| сыр | ширэ | сыру, тегү |
| эче (әд. ачу, әчи башлау) | эсэ | шулай ук |
| дага | тах | дага |
| угыз (сөт) | ууураг | угыз |
| борчак | буурцаг | борчак, бобы – бакча борчагы |
| кайын | хус(ан) | каен |
| дүләнә | долоогоно | дүләнә |
| чийә | чий | дала чиясе |
| артыш | арц | артыш |
| балтырган | балдаргана балчиргана | балтырган |
| дилбегә | дэлбэг | дилбегә |
| быгау – тимер богау | богоч | богау |
| тышау | тушаа | тышау |

Татар-монгол параллельләре диалекталь лексемаларны да эченә ала.

| татар | тәрҗемә | монгол | тәрҗемә |
|---|---|---|---|
| тирес | кире, сул як | тэрэ | дошман (як), каршы |
| хөрти | начар, ярлы | херт/хөртөй | зарарлы, агулы, явыз |
| алыс | ерак | алс | ерак |
| корт | махсус әзерләнгән сөт ашамлыгы | хурууд | киптергән эремчек |
| торон | корымбаш | туруу(н) | башак |

Еллар үткән саен, аеруча соңгы елларда лексикология өлкәсендә тикшеренү-эзләнүләр аеруча активлашты, фәнгә яңа материаллар, яңа нәтиҗәләр керә тора. Мәсәлән, шундыйлардан тунгус-маньчжур телләренең чагыштырма сүзлеген (1975) күрсәтергә мөмкин.

Соңгы елларда монгол теле белән бабаалтай теле арасындагы мөнәсәбәтләр (алар тугандашмы яисә аларның уртаклыклары типологик характерда гынамы) мәсьәләсен өйрәнү тагын да тирәнрәк дәрәҗәдә алып барыла. Шундыйлардан А.В. Дыбо һәм аның фикердәшләренең (С.А. Старостин, Е.А. Хелимский һ.б.) хезмәтләре бик әһәмиятле.

А.В. Дыбо бабаалтай телен реконструкцияләү өчен, лексика гына түгел, телләрнең башка яруслары буенча да тирән тикшеренүләр кирәк дигән фикердән чыгып, алтай телләрендәге аваз тәңгәллекләрен, протетик авазлар һәм, гомумән, авазлар системасының үсеш-үзгәреше юнәлешләрен, семасиологик характердагы үзгәрешләрнең закончалыкларын билгели торган критерийларны ачыклый. Шушы мәсьәләләр буенча ышанычлы өйрәтмәләр булдырылгач кына бабаалтай теленә хас күренешләр системасын дөрес итеп реконструкцияләп булачак, дип күрсәтә.

А.В. Дыбо лексик составны реконструкцияләү өчен лексик-тематик төркемнәрне аерып чыгарырга, аларның үзләренә генә хас формалашу үзенчәлекләрен билгеләргә кирәк һәм шуннан соң гына теге яки бу тематик төркемнәрнең үсеш-үзгәреш закончалыкларын ачыклап була, дип саный. Мәсәлән, кеше әгъзалары атамаларын А.В. Дыбо хайван әгъзаларының бабаалтай чорына хас атамаларыннан килеп чыкканнар дигән фикердә [Дыбо, 2006, с. 658] тора һәм соматизмнарны шушы критерийга нигезләнеп реконструкцияли [Дыбо, 1996, с. 305–333].

Монгол сүзләренең башка телләргә алынуы, төрки сүзләрнең монгол теленә үтеп керүе, кыскасы төрки-монгол лексик бәйләнешләре мәсьәләсе дә А.В. Дыбо өчен үзәк мәсьәләләрнең берсе булып тора. Автор фикеренчә, алтай телләренең үз эчендә сүзләрнең кабат-кабат алынуы да булган һәм менә шушы факт монголизмнар һәм монгол телендәге төрки алынмалар мәсьәләсен чишүне бик нык кыенлаштыра, кыенлыклар тагын шунда, монгол лексикасы җитәрлек өйрәнелмәгән.

А.В. Дыбо кеше гәүдәсенең *кул-җилкә-арка* өлешләренә караган соматизмнарны өйрәнә һәм китап чыгара (1996). Үзе эшләгән критерийлар нигезендә тирән тикшеренүләр ясый һәм түбәндәге соматизмнарны бабаалтай системасына карый дигән нәтиҗәгә килә [Дыбо, 1996, с. 305–333]: *арка, сырт, сауры, яка* (*пікэп* – шейные позвонки: бу мәгънәсе инде онытылган, әгъза атамасы → кием атамасы закончалыгы нигезендә барлыкка килгән яка сүзе яшәп килә. – *Д.Р.*), *бия, иңсә, ял* (ат ялы), *кевzе* – лопатка (гәүдә? – *Д.Р.*), *күкрәк*, *иң* (< ию фигыленнән), *ирен, түш, буын, баканак* (шайтан сөяге: чагыштыр: *бәкәл*, диал. *бәкәй*,

*баканак. – Д.Р.*), *беләк*, *терсәк*, *тырна-, канат, җилек, сөяк, кимек, кимер-, кул, эл* (-әд. кул), *култык, куен, алакан* – уч төбе (чагыштыр: тат. диал. алакан – шулай ук), *йодрык, уч, бармак, чымчалак* (диал.), *чәнчә бармак, тырнак* һ.б. (сүзләр хәзерге татарча әдәби язылышта бирелде).

А.В. Дыбо, җентекле тикшеренүләрдән соң, алтай (тунгус-маньчжур, монгол, төрки) телләренең уртаклыгы генетик характерда дигән нәтиҗәгә килә [Дыбо, 1996, с. 4, 333].

Анализ барышында автор кайбер алынмаларны да билгеләп бара. Мәсәлән, ул монгол *salaγa* (тырпаеп торган чәч; ял) сүзенең борынгы чордагы алынмасы, яисә алар икесе дә гомумалтай теленә хас борынгы формага (**salïga* – кошларда: бүрек) кайтып калалар [Дыбо, 1996, с. 125], дип күрсәтә.

*Кары* (үлчәү берәмлеге), сүзен А.В. Дыбо фарсыдан төрек телләренә, аннан монгол теленә үтеп кергән [Дыбо, 1996, с. 164], умрау – монгол алынмасы [шунда ук, б. 220], дигән фикердә тора.

Кайбер әгъза атамалар, кулланыштан төшеп калсалар да, кием-салым атамасы буларак сакланып калганнар: мәсәлән, **dire* (калак сөяге) сүзе ульч һәм нанай телләрендә «киемдәге кокетка» мәгънәсендә кулланыла; тунгус-маньчжур телләрендәге nikən (муен сөякләре) сүзе хәзерге төрки телләрдә яка мәгънәсендә кулланыла; *терсәк* сүзенең чуваш телендә кием җиңе дигән метонимик мәгънәсе билгеле [Дыбо, 1996, с. 167] һ.б.

Шулай итеп, татар-монгол янәшәлекләрен тикшерү буенча әһәмиятле күзәтүләр, тирән эзләнү нәтиҗәләре ясалган. Татар телендәге монгол теле белән уртак лексика, нигездә, бабаалтай чорына кайтып кала. Без, әлеге юнәлештә эзләнүләр алып барганда, кешелек башлангычының берлеге теориясенә таяну ягында торабыз (бу караш ЮНЕСКО тарафыннан 1997 елда игълан ителгән: Зәкиев, 2008: 2 нче форзац). Ностратик телләр берлеге дә шушы карашны раслый, һәрхәлдә кешелек турындагы фәннең бүгенге торышы әлеге фаразларга туры килә кебек. Мәсьәләгә логик якын килү бабаалтай составыннан аерылып чыккан тунгус-маньчжур, монгол, төрки телләре гомумуртак нигезгә тоташалар дип әйтергә мөмкинлек бирә.

**Әдәбият**

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең кыскача тарихи этимологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 272 б.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. Казан, 2003. 174 б.

*Әхмәтьянов Р.Г.* Татар теленең этимологик сүзлеге. Дүрт томда. I т. Бирск, 2005. 232 б.

*Дыбо А.В.* Семантическая реконструкция в алтайской этимологии: Соматические термины (плечевой пояс). М.: Школа: «Языки русской культуры», 1996. 389 с.

*Дыбо А.В.* Антропоморфная и зооморфная метафора в тюркских языках // Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. М.: Наука, 2006. С. 648–659.

*Зәкиев М.З.* Татар халкы тарихы: (этник тамырлары һәм киләчәге). Казан, 2008. 544 б.

*Ишбердин Э.Ф.* Историческое развитие лексики башкирского языка. М.: Наука, 1986. 152 с.

*Киекбаев Ж.Г.* Хәзерге башкорт теленең лексикасы һәм фразеологиясы. Өфө: Башкортостан китап нәшрияте, 1966. 275 б.

*Кызласов И.Л.* Археологический взгляд на проблему первоначального единства алтайских народов // Еуразияшылық идеясы контекстсндегі Қазақстан түркітануы: Мәселелері мен болашағы (халықаралық ғылыми теориялык конференциясының ғылыми теориялық мақалалар жинағы). Астана: «Ус-Сервис» – ЖИС, 2009. С. 36–49.

*Нуриева А.Х.* Татар теле тарихыннан материаллар. Лексикология. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1975. 97 с.

*Серебренников Б.А., Харькова С.С.* О некоторых эффективных методах исследования проблемы родства тюркских и монгольских языков // Советская тюркология. 1983. № 5. С. 46–56.

Сравнительный словарь тунгусо-маньчжурских языков: материалы к этимологическому словарю. Т. I: А–Ң. Л.: Наука, Ленингр. отд-е, 1975. Т. I. 672 с.; Т. II. 992 с.

ТТЗДС: Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казань: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

*Туймебаев Ж.К.* Теоретические принципы и критерии историко-генетического разграничения тюркско-монгольских параллелей: Автореф. дис... д-ра филол.наук. Астана, 2008. 56 с.

**_Рамазанова Дөрия Бәйрәм кызы,_**
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 811.512.145′373

***Г.Р. Гайнетдинова***

# ТӨРКИ-ТАТАР ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕ ЛЕКСИКАСЫН ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫННАН

В статье проведен обзор некоторых монографий и научных статей, посвященных изучению лексики древнетюркских и старотюркских письменных памятников, опубликованных в XX веке.

**Ключевые слова:** лексика, старотюркские письменные памятники, исследование, лексико-семантический аспект, тематика.

Төрки телләрнең үсешен, төрки халыкларның әдәби тел нормаларының формалашуын күзаллау өчен төрле характердагы тикшеренү эшләре алып барылырга тиеш. Бу юнәлештә борынгы төрки һәм иске татар язма истәлекләрнең телен өйрәнү аеруча әһәмиятле. Аларга хас үзенчәлекләрнең күбесе хәзерге телләрнең структурасында да чагылыш таба. Шуңа да аларны системалы рәвештә өйрәнү телнең башлангыч чор һәм хәзерге торышы арасындагы мөнәсәбәт-бәйләнешләрне ачыкларга ярдәм итә.

Әйтергә кирәк, бүгенге көндә борынгы һәм иске төрки-татар язма истәлекләренең телен өйрәнү эше фонетик һәм грамматик яссылыкта югары дәрәҗәдә башкарылган. Шул ук вакытта язма истәлекләрнең лексикасына караган мәсьәләләр төрки һәм татар тел белеменең аз өйрәнелгән өлкәләреннән санала. Мәсәлән, үзенең 1984 елда чыккан «Лексикология тюркских языков» монографиясендә К.М. Мусаев болай дип яза: «…остается еще много неисследованных тематических и лексико-семантических групп, терминов, относящихся к различным сторонам жизни тюркских народов в прошлом и настоящем; мало трудов, посвященных исследованию общих вопросов тюркской лексикологии. Современная лексикология, как и тюркологическая наука в целом, больше развивается вширь, но ей в значительной мере недостает глубины исследования [Мусаев, 1984, б. 4].

Хәзерге төрки тел белемендә борынгы һәм иске төрки-татар язма истәлекләренең лексикасына кагылышлы шактый материал тупланды. Әлеге материал бүгенге этапта гомумиләштерүче характердагы тикшеренүләр үткәргәндә нигез булып тора.

Мәгълүм булганча, төрки телләрнең лексикасы эчке ресурслар һәм төрле телләрдән кергән алынмалар хисабына тулыландырыла. Борынгы һәм иске төрки-татар язма истәлекләрендә чагылыш тапкан лексиканы өйрәнгән вакытта аны системалы тикшерү мәсьәләсе алгы планга чыга.

Күп кенә хезмәтләрдә лексикологиядә семантик принцип кулланыла. Теләсә кайсы телдә сүзне семантик нигездә тикшерергә мөмкин. Бүгенге көндә

төрки телләрдәге сүзләрнең лексик-семантик классификациясе мәсьәләсе гомумтөрки планда, шул исәптән конкрет төрки тел материалында, җентекле тикшеренүләр таләп итә. Конкрет телләрдәге сүзләрне тикшерү, тематик, лексик-семантик төркемнәрне классификацияләү алга таба үткәреләчәк типологик, чагыштырма-тарихи тикшеренүләр өчен нигез булып тора. Бу нисбәттән К.М. Мусаев үзенең «Лексикология тюркских языков» монографиясендә болай дип яза: «Необходимо развивать синхронно-сопоставительное направление исследований семантики тюркского слова. В отличие от сравнительно-исторических и этимологических исследований здесь вопросы реконструкции и этимологии слов и их значения не рассматриваются, основная задача – выявление общего и особенного в развитии семантики слов в современных языках» [Мусаев, 1984, б. 6].

Төрле елларда төрки телләрнең лексикасын өйрәнүгә К.М. Мусаев, Н.З. Гаджиева, А.А. Юлдашев, Ә. Нәҗип, Д.М. Насилов, Г.Ф. Благова, А.К. Боровков һ.б. галимнәр үзләреннән зур өлеш керттеләр. Мәкаләдә аларның хезмәтләрендә төрки-татар язма истәлекләренең тел үзенчәлекләре, аерым алганда лексикасы, ни рәвешле һәм ни дәрәҗәдә өйрәнелгәнлегенә кыскача күзәтү ясау максат итеп куелды.

1951 елда чыккан «Памятники древнетюркской письменности» хезмәтендә С.Е. Малов V–XV гасыр язма истәлекләренең тел үзенчәлекләрен тикшерә. М. Кашгарыйның «Диване лөгат әт-төрк», Рабгузиның «Кыйссасел әнбия» һәм башка әсәрләрдән текстларга, аларга тәрҗемәләр китерә. Шулай ук тикшерелгән язма истәлекләрнең тел үзенчәлекләренә бәйле искәрмәләрен дә бирә.

Үзенең «Лексика среднеазиатского тефсира XII–XIII вв.» исемле монографиясендә (1963) А.К. Боровков тел үзенчәлекләрен өйрәнү белән беррәттән тәфсирнең лексик материалын аерып чыгара һәм аны глоссарий рәвешендә бирә. Шуның белән бергә автор синонимнарны тикшерә, сүзләрнең килеп чыгышында уртаклык һәм аерымлыкларны билгеле.

1969 елда чыккан «Введение в изучение тюркских языков» монографиясендә Н.А. Баскаков төрки телләрнең лексикасын да тикшерә. Аерым алганда, алардагы борынгы лексик катламны, аның эчке үсеш закончалыкларын ачыклый. Автор төрки телләрдә тарихи эзлелектә тотрыклы оешкан лексик структураларга игътибар итә, аларның үзенчәлекләрен ачыклый.

Үзенең «Исследование по лексике старокыпчакского письменного памятника XIII века «Тюрко-арабского словаря» хезмәтен (1970) А.К. Курышжанов сүзлектә чагылыш тапкан лексиканы өйрәнүгә багышлый, аерым алганда сүзләрнең лексик-семантик үзенчәлекләрен һәм алынмаларны билгеле.

1977 елда Алма-Атада яклаган «Сравнительный анализ лексики тюркоязычных памятников XIV века» исемле диссертациясендә Берикбай Сагындыков

Хәрәзминең «Мәхәббәт-намә»-сендә, Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ендә, С. Сараиның «Гөлстаны»нда чагылыш тапкан лексик материалның уртак һәм аерым якларын билгели, архаик элементларны ачыклый, гарәп һәм фарсы алынмаларын тикшерә.

Я.С. Ахметгалеева 1979 елда чыккан «Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы» хезмәтендә «Кисекбаш китабы»ының жанр һәм тел үзенчәлекләрен анализлый: әсәрнең фонетик, грамматик үзенчәлекләрен һәм лексик составын өйрәнә.

1983 елда Тбилисида чыккан «Лексика произведений Юнуса Эмре» дигән монографиясендә Ш.В. Габескирия Юныс Әмрә әсәрләрендә чагылыш тапкан төрки лексиканы тикшерә, аңа генетик анализ ясый, архаиклашкан лексик берәмлекләрне өйрәнә. Өйрәнелгән материалны автор искәрмәләр белән сүзлек рәвешендә бирә.

1983 елда чыккан «Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников» дип исемләнгән мәкаләләр җыентыгында Э.Р. Тенишев «Новый список Рабгузи» мәкаләсендә кыскартылган вариантта «Кыйсасел әнбия» текстын китерә һәм аның Н.И. Ильминскийның текстыннан күпкә тулырак булуын да искәртә. Шуның белән бергә галим текстның гадиләштерелгән транскрипциясен һәм тәрҗемәсен бирә, искергән сүзләрне ачыклап китә.

Үзенең «Исследования по истории тюркских языков (XI–XIV вв.)» монографиясендә (1989) Ә. Нәҗип Й. Баласагуниның «Котадгу билиг», М. Кашгарыйның «Диван-е лөгат аттөрк», Ә. Йүгнәкинең «Атебат ал-хакаик», Ә. Ясәвинең «Диван-е хикмәт», Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», С. Сараиның «Гөлстан бит-төрки», Хәрәзминең «Мәхәббәт-намә», Котбның «Хөсрәү вә Ширин», М. Болгариның «Нәһҗел-фәрадис», Ә. Хафизның «Сираҗел-колүб» (XVI гас.), Кади Борһанетдин Сиваслының «Диван» (XIV гас.) исемле язма истәлекләренә лингвистик анализ ясый. Аерым алганда, галим «Кыйссаи Йосыф» әсәре телендә угыз элементларының зур урын алып торганлыгын күрсәтә, С. Сараиның «Гөлстан бит-төрки» әсәрен гомумтөрки катламы һәм алынмалар ягыннан тикшерә, гарәп һәм фарсы элементларын билгели, Хәрәзминең «Мәхәббәт-намә»сендә моңарчы теркәлмәгән архаик элементларны ачыклый, синонимнар һәм парлы сүзләрне тикшерә, XVI гасыр урталарында иҗат ителгән «Сираҗ әл-колүб» төрки язма истәлегенең глоссарием китерә һ.б.

Төрки-татар язма истәлекләренең телен өйрәнүгә багышланган хезмәтләр моның белән генә чикләнми әлбәттә, алар шактый күп. Мәкаләдә без аларның кайберләренә генә тукталдык һәм әлеге юнәлештә эш алга таба да дәвам ителәчәк.

**Әдәбият**

*Ахметгалеева Я.С.* Исследование тюркоязычного памятника «Кисекбаш китабы». М., 1979. 191 с.

*Баскаков Н.А.* Введение в изучение тюркских языков. М., 1969. 332 с.

*Баскаков Н.А.* Тюркская лексика в «Слове о полку Игореве». М., 1985. 231 с.

*Боровков А.К.* Лексика среднеазиатского тефсира XII–XIIIвв. М., 1963. 367 с.

*Габескирия Ш.В.* Лексика произведений Юнуса Эмре. Тбилиси, 1983. 214 с.

*Кузьмина Х.Х.* Лексика поэмы «Кысса-и Йусуф» Кул Гали. Казань, 2001. 98 с.

*Курышжанов А.К.* Исследование по лексике «Тюрко-арабского словаря». Алма-Ата, 1970. 234 с.

*Малов С.Е.* Памятники древнетюркской письменности. М., 1951. 452 с.

*Мусаев К.М.* Лексика тюркских языков в сравнительном освещении (западнокыпчакская группа). М., 1975. 359 с.

*Мусаев К.М.* Лексикология тюркских языков. М., 1984. 226 с.

*Наджип Э.Н.* Исследования по истории тюркских языков XI–XIV вв. М., 1989. 284 с.

*Сагындыков Б.* Сравнительный анализ лексики тюркоязычных памятников XIV в.: автореф. дис. ... канд. филол. н. Алма-Ата, 1977.

*Тенишев Э.Р.* Новый список Рабгузи // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. Казань, 1983. С. 25–31.

***Гайнетдинова Гөлнара Рашат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145:821.512.122

*Х.Й. Миңнегулов*

# АБАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

В статье творчество Абая (Ибрагима Кунанбаева) рассматривается в контексте взаимосвязей казахской и татарской литератур, приводятся факты и сведения об известности казахского поэта в татарском мире.

**Ключевые слова:** Абай, казахи, татарская литература, взаимосвязи, переводы.

Мең елдан артык тарихы булган төрки сүз сәнгатендә бик күп шагыйрьләр, язучылар иҗат иттеләр. Алар арасында мәшһүр әдибебез Абай [Ибраһим Кунанбаев (10.08.1845–6.07.1904] күренекле урыннарның берсен алып тора. Аның 170 еллыгы зурлап, халыкара масштабта билгеләп үтелде. Бу кешенең киңкырлы поэтик, мәгърифәтчелек, иҗтимагый эшчәнлеге үзен тудырган халыкның тормышы белән шулкадәр тирән һәм табигый рәвештә үрелеп барган ки, хәтта соңгы 100 елда Абайдан башка казакълар һәм Казакъстанның тарихын, тормыш-көнкүрешен күз алдына китерүе дә кыен. Татар поэзиясенең классигы Сибгат Хәким (1911–1986) сүзләре белән әйтсәң, «Абайның күңеле очсыз-кырыйсыз казакъ далаларына таралган халкының моң-зарын үзенә сеңдергән», «үзенә бөек казакъ рухын формалаштыру миссиясен алган» [Хәким, б. 5].

Минем Абай әсәрләрен оригиналда да, тәрҗемәдә дә укыганым бар. Янә бер тапкыр аның иҗатына мөрәҗәгать иттем һәм гаҗәпкә калдым: алар мине беренче тапкыр очрашкандагы кебек шулкадәр үзләренә җәлеп иттеләр ки, авторның тирән фикерләре, эчкерсез тойгылары, дәртлелеге таң калдырды. Мин шагыйрьне укымыйм, ә тыңлыйм, ул аудитория алдында тере килеш чыгыш ясый, минем алдымда думбрада уйный, җырлый кебек үземне хис иттем; аның үтемле сүзләре, күңелгә ятышлы музыкасы бүген дә безне – XXI гасыр кешеләрен – дулкынландыра.

Абай турында күп язылган. Үзенең танылган якташы Мохтар Ауэзевның (1897–1961) роман-эпопеясы – «Казакъ халкының әдәби энциклопедиясе» ярдәмендә ул бөтен дөньяга таралды. Бөек шагыйрь турындагы бу әсәр автор әле үзе исән вакытта ук Сәрвәр Әдһәмова (1901–1978) тәрҗемәсендә ике тапкыр (1957, 1960 елларда) татар телендә нәшер ителде һәм ул бүгенгәчә татар укучысының яраткан китабы санала.

Абай, аның шигырьләренең идея-сәнгати һәм поэтик үзенчәлекләре, шагыйрьнең традицияләре һәм башлангыч чоры, казакъ шагыйренең иҗаты һәм татар әдәбияты арасындагы охшаш һәм типологик параллельләргә тукталып үтәсем килә.

Минем фикеремчә, «Абай һәм татар әдәбияты» мәсьәләсен казакъ-татар бәйләнешләре контекстында карау максатка ярашлы булыр иде. Бу проблема Чокан Вәлиханов (1835–1865), Сабит Муканов (1900–1973), Сәйфи Кудаш (1894–1993), Темиргали Нуртазин (1907–1977), Резеда Ганиева (1932 елда туган), Лирон Хәмидуллин (1932 елда туган), Хатыйп Миңнегулов, Күлбәк Ергобәк (1952 елда туган) һ.б. язучылар, галимнәр тарафыннан билгеле бер дәрәҗәдә яктыртылган. Казакъ-татар әдәби бәйләнешләре, шулай ук Б. Исхаковның Абай хакындагы монографиясендә [Ыскаков, б. 175] кызыклы фактлар һәм мәгълүматлар бар.

Мәгълүм булганча, казакъ һәм татар – килеп чыгышлары, телләре буенча тугандаш халыклар. Аларны күпгасырлык икътисади, мәдәни, дини мөнәсәбәтләр, бер үк дәүләтләрдә яшәп алулар, катнаш никахлар, мөселман дөньясына йөз тоту берләштерә. Татарларның билгеле бер өлеше инде бик күптәннән Казахстан җирендә көн итә. Алар аеруча Петропавл (Кызылъяр), Семипалатинск, Уральскида яшәделәр һәм шунда мәктәпләр ачып, татар телендә нәшер ителгән китаплар, Казаннан килгән газета-журналларны таратып көн иттеләр. Мәсәлән, «1863 елда Семипалатинскида якынча 500 укучыга исәпләнгән 9 шәхси татар мәктәбе эшләде» [Татары в Казахстане, с. 9]. Аларда татарлар белән бергә казакъ һәм төрки халыкларның балалары да укыды. Казакъның күп кенә әдәбият һәм мәдәният эшлеклеләре Казандагы («Мөхәммәдия»), Уфадагы («Галия»), Ырынбурдагы («Хөсәения») һ.б. татар уку йортларында белем алалар. Казакъларның тормышы һәм образлары татар язучыларының күп кенә әсәрләрендә чагылдырыла (Г. Ибраһимов, А. Таһиров, Ш. Усманов, И. Сәлахов...).

Хәзерге көнчыгыш Казакъстан өлкәсендә туган Абай, кечкенәдән татарлар белән аралашып, аларның тормышын күреп, менталитетын белеп үсә. Үзенең «Кара сөздер» («Слова назидания») әсәрендә ул татар-ногайлар турында болай дип яза: «...алар һәм солдатлыкны да үткәреп җибәрә алалар, һәм ачлыкка да түзә, һәм кайгыга да сабыр итә, һәм динне дә тота. Җан тирләре чыкканчы эшли һәм ничек итеп байлык тупларга, муллыкта яшәргә кирәклеген белә» [Кунанбаев, 2014, с. 12]. Абай башта авыл мулласында – татар Габитханда укый, аннан – Семипалатинскидагы татар мәдрәсәсендә, Әхмәт Ризада белем ала. Уку елларында ул көнчыгыш классик язучыларының, урыс язучыларының, шулай ук Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889), Каюм Насыйри (1825–1902), Хөсәен Фәйзханов (1826–1866) һәм башка татар мәгърифәтчеләренең әсәрләре белән таныша.

Абай әсәрләре казакъларның тормышын, табигатен, менталитетын, образлы фикерләү сәләтен төрле картиналар, детальләр, образлар аша гәүдәләндерә. Шул ук вакытта аның әсәрләрендә, татар әдәбиятындагы кебек, типологик охшашлыклар, генетик яктан якын күренешләр, образлар еш

очрый. Татарның күп кенә авторлары кебек, Абай да ислам динен, мөселманлыктагы рухи кыйммәтләрне хөрмәт итә, традицион сюжет һәм образларны куллана, мәгърифәтле булырга, әхлаклылыкка чакыра, антитеза юлы белән кешеләрдәге тискәре сыйфатларны һәм гамәлләрне кискен тәнкыйть итә. Аның шигърияте Акмулла (1831–1895), Кандалый (1797–1860), Гомәр Мөхәммәт улыныкы (XIX гасырның беренче яртысы) кебек үк тормышка якын. Ләкин Абайның теле киң җәмәгатьчелеккә дә аңлаешлы, анда гарәп-фарсы сүзләре чагыштырмача аз. Шагыйрьнең стилендә импровизаторлык, ораторлык башлангычы өстенлек ала.

Абайның шигырь һәм җырлары татарларга, бигрәк тә, Казакъстандагыларга, билгеле бер дәрәҗәдә күптәннән таныш иде. Аларның күбесе (бигрәк тә катнаш никахта яшәүчеләр) казакъ телен белделәр һәм хәзер дә beləләр. Мәсәлән, рәссам Бакый Урманче (1897–1990), композитор Латыйф Хәмиди (1906–1993), язучылар Кави Нәҗми (1901–1957) һәм Сәрвәр Әдһәмова, шагыйрь Мәхмүт Хөсәен (1923–1993) һәм татарның башка әдәбият-сәнгать эшлеклеләре казакъ теле, аның бай мәдәнияте белән яхшы таныш иделәр. Минем хатынымның үги этисе Тәүфикъ Хәсәнҗанов (1909–1973) Семипалатинскида туган һәм үскән, үзешчән татар театрында уйнаган, Абай шигырьләрен яттан белгән, аның җырларын җырлаган. Берничә тапкыр М. Ауэзов белән дә очрашкан. Ул аңа култамгасы белән үзенең китабын да бүләк иткән. Кайнатамның кәгазьләре арасында мин аның дүртьюллык җыр сүзләрен дә табып алдым:

Ямьле Иртеш буйларында
Матур Семәй каласы.
Казаннарын сагнып яши
Биредә нугай (татар. – *Х.М.*) баласы.

Күрәсең, ул үзенең тарихи ватаны – Казанны сагынып яшәгән.

Абай әсәрләре һәм алар турындагы мәгълүматлар татар басма матбугатында XIX гасыр азагы XX гасыр башларында күренә башлый. Мисал өчен, 1908 елда «Вакыт» газетасында (№ 333) (Ырынбур) Абай турында мәкалә, аның берничә шигыре бар. Кырым татар нашире Ильяс Бораганский 1909 елда Петербургтта Абайның шигъри җыентыгын бастыра («Казакъ акыны Ибраһим Кунанбай улының өлеңдери»). Шагыйрьнең 1916 елда Ырынбурда нәшер ителгән китабы да бар («Абай термесi»). Шагыйрь әсәрләренең шактый тулы басмасы 1922 елда Казанда нәшер ителә («Абай Конанбай өлеңнери») [Культура Казахстана, с. 7]. Абай шигырьләре шулай ук башка җыентыкларда һәм басма матбугат битләрендә дөнья күргән.

Мәгълүм булганча, Г. Тукай 10 елдан артык (1895–1907) Уральскида яши: шунда укый, эшли һәм шагыйрь буларак формалаша. Ул казакълар белән аралашкан, аларның фольклоры белән танышкан. Тукай Абайның исемен атамаса да, ул аның шигырьләрен яхшы белгән. «Шигырьләребез» (1907) исемле мәкаләсендә Тукай татар

шагыйрьләрен тәнкыйтьли, шул исәптән Акмулланы да һәм казакъ шагыйренең «Карагыз, айналаем, сез кызгалдак» сүзләре белән башланган лирик шигырен үрнәк итеп китерә. Анда лирик герой үзенең сөйгәнен бик матур буяулар белән сурәтли («Авызың бал, телең секер, куйның оҗмах...»), мәхәббәт хисен идеаллаштыра [Тукай, б. 223–225]. Бу шигырьнең авторы күрсәтелмәгән. Абайның нәшер ителгән әсәрләре арасында бу юллар очрамаса да, алар аның иҗатына бик якын.

Абай урыс шигъриятенең үрнәкләрен – Пушкин, Лермонтов, Крылов, Бунин әсәрләрен казакъ теленә беренчеләрдән булып тәрҗемә итә башлый. Бу традицияне Тукай да дәвам иткән.

Татар-башкорт шагыйре Шәехзада Бабич (1895–1919) «фәсахәт вә ләззәт табып» Абай шигырьләрен укуы, аны татарларның Тукае, гарәпләрнең Имрелькайсы (VI гасырның беренче яртысы, Мәҗнүннең прототибы. – *Х.М.*) белән чагыштырган. Ш. Бабич үзенең кайбер шигырьләрен Абай йогынтысында язган [Ыскаков, б. 75].

Татар шагыйре Дәрдемәнд (1859–1921), башлыча Ырынбур губернасында яшәгәнлектән, казакъларның сөйләм сәнгате белән бик тирән кызыксынган. Үзенең иҗатында ул кайчакта Абай кебек «алтыаяк» һәм «сигезаяк» шигъри формаларын да куллана.

Татар әдәбиятының классигы, җәмәгать эшлеклесе, галим, «Казакъ кызы» романының авторы Галимҗан Ибраһимов (1887–1938) казакъ халкының, аның мәдәниятенең үзенчәлегенә еш игътибар иткән, Абайны югары бәяләгән, шагыйрьнең мәшһүрлеге турында сөйләгән [Ибраһимов, б. 230, 431...]. Бөек казакъ шагыйре, халыкларның рухи тормышында тоткан урыны һәм роле турында башка татар авторларының язмаларында да күп әйтелә.

XX гасыр башларында мөселман төрки халыкларының интеллигенция вәкилләре бер-берләренең әдәбиятын, башлыча, оригиналда укый алган. Ләкин, гомуми уртак гарәп графикасын гамәлдән чыгарганнан соң, язма тел белән сөйләм тел берләшкәч, төрки телләрне аңлау авырлашты, тәрҗемәгә күчелде. Шушы дулкында Абай шигырьләренең татар теленә тәрҗемәсе нәшер ителә башлый. Абайның тууына 100 ел тулу уңае белән шагыйрьнең шигырьләр җыентыгы дөнья күрә [Абай, 1947]. Анда авторның 40 шигыре һәм 2 поэмасы урын алган. Җыентык татар шагыйре Мәхмүт Максуд (1900–1962) тарафыннан әзерләнгән. Китапның кереш сүзендә ул Абайны, «казакъ халкының бөек улы», «ялкынлы мәгърифәтче», ирек, бәхет өчен көрәшүче дип атый.

1981 елда Абайның татар телендә шактый тулы җыентыгы дөнья күрде [Абай, 1981]. Анда 134 шигырь, 2 поэма һәм «Хикмәтле сүз»е кергән. Китапның проза өлешен җыентыкны төзүче Л. Хәмидуллин үзе тәрҗемә иткән. Шигырьләренә тәрҗемәне Н. Арсланов (69), Ә. Исхак (15), М. Шабаев (15), М. Хөсәен (5) һ.б. әдипләр эшлә-

гән. Ике поэма һәм 16 шигырь М. Максуд тарафыннан 40 нчы елларда нәшер ителгән җыентыктан алынган. Барлык тәрҗемәчеләр дә талантлы, тәҗрибәле шагыйрьләр. Текстларны тәрҗемә итү өчен алар фәкать оригинал белән генә эш иткәннәр.

Нури Арслан (1912–1991), Мәхмүт Хөсәен (1923–1993) – икесе дә Кызылъярдан (Петропавл), шунда белем алганнар, казакъ телен, әдәбиятын, мәдәниятен яхшы белгәннәр. Татар җыентыгына кергән әсәрләрне мин төп нөсхәсендәге текст белән чагыштырып укып карадым. Тәрҗемәләр шигырьнең мәгънәсен һәм эчтәлеген генә түгел, казакъ текстының поэтик яктан байлыгын да күрсәтергә тырышканнар. Абайның татар телендәге шигырьләре тәрҗемә буларак түгел, ә бәлки тулы канлы поэтик әсәр буларак яңгырый.

Иллюстрация өчен фәкать бер шигырьне генә китерәм.

[«Кактаган ак күмістей кең маңдайлы...» – [Абай Кунанбаев,1968, 1 т., б. 22] Н. Арслан тәрҗемәсендә:

Ак көмештәй коеп куйган киң маңгае,
Кара күзләрнең йолдыздай,
нурланганы,
Кара кашлар кыйгач кына сызып
куйган,
Хәтерләтә яңа туып килгән айны.
Маңгаеннан туры төшкән нәфис
борын,
Аксыл чырай, ал-кызыл битләр алмалы.
Иренен ачса – тезеп куйган ак тешләре,
Күрү белән җанда дәртнең кайнаулары!
Сөйләр сүзе әдәпле дә, мәгънәле дә,
Көлүендә – сандугачның сайраулары.
Түп-түгәрәк ак ефәктәй ап-ак муен,
Йомшак ияк асты – ала күз яуларын.
Калак сөякләре – канат, иңнәре төз,
Күкрәгендә пар алманың уйнаулары.
Буе-сыны озын түгел, кыска түгел,
Нечкә биле талчыбыктай сыгылмалы.
Беләкләре яшь баланың тәнедәй саф,
Бармаклары нәзек, төрле эшкә җайлы.
Таралып, дулкынланып иңгә төшкән
Кара чәче хәтерләтә ефәк талны
[Абай, 1981, б. 19].

Җыентыкның кереш сүз авторы, татар шигъриятенең классигы Сибгат Хәким тәрҗемәләрнең камиллеге турында болай дигән: «Күп кенә тәрҗемәләрдә Абай рухы, аның поэтик фикерләве сакланган [Абай, 1981, б. 6]. Кереш сүз авторы Абайның масштаблылыгын ассызыклый, аның традицияләренең казакъ әдәбиятында уңышлы төстә дәвам ителүенә шатлануын белдерә.

Газета-журналларда, һәртөрле җыентыкларда Абайның тәрҗемәләре күп бирелде һәм бирелә. Казан федераль университетының фәнни китапханәсендә аның урыс, татар, казакъ телләрендә бик күп җыентыклары бар.

Һәртөрле тормыш зилзиләләре, борчулары булуга карамастан, Абай Кунанбаев шагыйрь һәм кеше буларак бик бәхетле. Ул үзенең бөтен көчен һәм иҗади җегәрен халкына багышлады. Абайның поэтик эстафетасын аның бертуган кардәшенең улы – талантлы шагыйрь, философ, музыкант Шәкәрим Кудайбердиев (1858–1931), традицияләрен Сабит Муканов, Мөхтәр Ауэзов, Сәкен Сәйфуллин һ.б.лар дәвам итә. Кайчандыр хокуксыз, бәйле булган казакъ халкы хәзер үз җиренең, үз язмышының хуҗасы. Казакъстан Республикасы хәзер

Евразия дәүләтләре арасында иң алга киткән илләрнең берсе.

Абай тормышны, кешеләрне, матурлыкны яратты һәм шуңа күрә аның үзен дә, аның тәэсирле шигъриятен дә, аннан соң килгән буыннар, күп миллионлаган укучылар да ярата.

**Әдәбият**


*Абай Кунанбаев.* Слова назидания / пер. Сатимжана Санбаева. Алматы: Библиотека Олжаса, 2014. 156 с.

*Абай Кунанбаев.* Стихотворения. Поэмы. Проза: перевод с казахского. М.: ГИХЛ, 1954. 415 с.

*Абай Кунанбаев.* Шыгармалар: Екi томдык. Алматы: Жазучы, 1968. I т. 319 б.; II т. 251 б.

*Абай Кунанбай улы.* Кара сөз. Алматы: Олжас китапханасы, 2014. 171 б.

*Абай.* Шигырьләр һәм поэмалар / Мәхмүд Максуд тәрҗ. Казан: Татгосиздат, 1947. 75 б.

*Абай.* Шигырьләр һәм поэмалар. Хикмәтле сүз / төз. Л. Хәмидуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 256 б.

*Бабич Шәйхзадә.* Зәңгәр җырлар: Шигырьләр, поэмалар, мәкаләләр, хатлар / төз. Г. Гыйльманов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 544 б.

*Ибраһимов Г.* Әсәрләр: сигез томда. 5 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. 625 б.

Культура Казахстана: Энциклопедический справочник: Алматы: Аруна, 2010. 656 с.

*Миннегулов Х.* Великий сын казахского народа (к 70-летию со дня рождения Нурсултана Назарбаева) // Записи разных лет (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи). Казань: Идел-Пресс, 2010. С. 206–211.

*Миннегулов Х.* Мы – крона одного дерева // Записи разных лет (Татарская литература: история, поэтика и взаимосвязи). Казань: Идел-Пресс, 2010. С. 212–218

*Миннегулов Х.* О казахско-татарских литературных взаимосвязях и о Рымгали Нургали // Әдебиеттанудың теориялык мәселелерi және Р. Нургали зертеулерi. Халыкаралык гылыми-теориялык конференция материаллары (Л.Н. Гумилев атындагы Еуразия ұлттык университеты, 1 маусым 2015 жыл). Астана, 2015. Б. 7–12.

*Миннегулов Х.* Мохтар Ауэзов һәм татар әдәбияты // «Дөньяда сүземез бар...». Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Б. 281–295.

Татары в Казахстане: Энциклопедический словарь / под ред. Г.Т. Хайруллина. Алматы: Мир, 2011. 220 с.

*Тукай Г.* Әсәрләр: дүрт томда. 3 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 447 б.

*Хәким Сибгат.* Могҗизалар тудыра торган җир // Предисловие к книге «Абай..». Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. Б. 5–10.

*Ыскаков Б.* Казак-татар әдеби байланысы. Алматы: Гылым, 1976. 175 б.



***Миңнегулов Хатыйп Йосыф улы,***
*филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университеты профессоры*

УДК 821.512.145-97

***А.А. Хасавнех***

# ТАТАР ШӘЕХЕ МӨХӘММӘД ЗАКИР ӘЛ-ЧИСТАВИ ТУРЫНДА ЯҢА МӘГЪЛҮМАТЛАР

В статье приводятся краткие биографические сведения о татарском шейхе Накшбандийского тариката Мухаммад-Закире аль-Чистави. Подробные сведения о жизнедеятельности М.-З. Камалова имеются в сочинении его соотечественника – Мухаммада Мурада Рамзи «Нафаис ас-салихат фи тазйил ал-бакийат ас-салихат», написанного в агиографическом жанре (табакат). Интересным является то, что в нем приводится цепь преемственности (силсила) предшественников М.-З.Камалова из Халидийской ветви Накшбандийского тариката. В статье указывается на тесные многовековые историко-культурные, религиозные связи Волго-Уральского региона с Северным Кавказом. В этой связи приводятся воспоминания муридов Мухаммад-Закира ишана – выходцев из из северокавказского региона Габдулхака ал-Бакри и Сайфуллы ан-Ницубикри.

**Ключевые слова:** Мухаммад-Закир ал-Чистави, Мухаммад Мурад Рамзи, агиография, суфизм, Накшбандийский тарикат, силсила, письма-наставления (мактубат).

Күп гасырлар буена татар әдәбияты бердәм гомуммөселман мәдәнияте кысаларында үскән һәм ныгыган. Ул гарәп, фарсы һәм төрки мәдәниятләр белән тыгыз бәйләнештә булган.

Идел буе һәм Урал мөселманнары Якын Көнчыгыш илләре мөселманнары тормышы орбитасында ныклап катнашканнар, ә бу исә, гарәп-мөселман әдәби традицияләренең иң яхшы сыйфатларын туплаган татар мөселман әдәбиятының жанрлар составында да чагылыш тапкан. Шунысын да әйтеп китү зарур, татар мөселман әдәбияты регионның үз эчендә генә аерым үсмәгән, ә Россиянең башка мөселман өлкәләре, мәсәлән, Төньяк Кавказ белән тыгыз контактта булган. Урал һәм Идел буе мөселманнарын Төньяк Кавказ мөселманнары белән күпгасырлык тарихи-мәдәни һәм дини элемтәләр берләштергән. Төньяк Кавказ белән аеруча тыгыз бәйләнешләр XIX–XX гасырлар аралыгындагы чорда булган. Ул вакытта, кайбер дагыстанлылар, билгеле бер тарихи шартлар аркасында, үз белемнәрен татар мәдрәсәләрендә камилләштерергә мәҗбүр булганнар. Идел-Урал регионы һәм Төньяк Кавказ мөселманнары бәйләнешләренең ачык мисалы булып, Дагыстан суфый шәехе Сәйфулла казый Башларовның эшчәнлеген күрсәтергә була. Ул эзлекле рәвештә мөршидлеккә (рухи остаз булырга) өч татар шәехеннән: Чистайдагы Мөхәммәд Закир шәехтән, Троицкидагы Зәйнулла Рәсүлев шәехтән, Әҗем авылыннан булган Мөхәммәд Салих шәехтән *иҗазат* (мөршид булырга рөхсәт) алган [Шихалиев, с. 72–73]. Шунысы кызыклы, югарыда телгә алынган татар шәехләренең

биографияләре турындагы мәгълүматлар гарәп телендә язылган Дагыстан кулъязмаларына да кертелгәннәр.

С. Башларовның беренче шәехе Мөхәммәд Закир әл-Чиставиның (Габделваһаб Камалов улы Мөхәммәд Закир, 1804–1893) биографиясе тикшерүчеләрдә аеруча зур кызыксыну уята. Аның тормышына караган кайбер мөһим мәгълүматлар күренекле дин эшлеклеләре һәм мәгърифәтчеләр Ш. Мәрҗани (1818–1889) һәм Ризаэддин Фәхретдинов (1859–1936) хезмәтләрендә бар. Мөхәммәдзакир ишанның тормышын җентекле рәвештә өйрәнүгә шактый өлеш керткән галим – ул Р.Г. Әмирханов (1946–2006).

Мөхәммәд Закир әл-Чиставиның ярты гасырга якын Казан губернасының Чистай шәһәрендә имам-хатыйп булып торуы, ул вакытлар өчен шактый зур булган «Камалия» мәдрәсәсен тотуы билгеле. Р. Фәхреддин, Ф. Кәрами, Г. Гафуров-Чыгътай, Г. Исхакый кебек татар халкының мәшһүр вәкилләре бу мәдрәсәдә белем алып чыкканнар. М.З. Камалов Россиянең үзәк өлешендә Нәкышбәндийә мәзһәбенең лидеры булган. Бу шәехнең җентеклерәк биографиясе гарәп телендәге кайбер Дагыстан язмаларында бәян ителгән. Мөхәммәд-Закир әл-Чиставиның тәрҗемәи хәле китерелгән шундый хезмәтләрнең берсе – татар галиме һәм шәехе Морадулла (Мөхәммәд Морад) бине Баһадирша Габдулла бине Гаделша әр-Рәмзи әл-Мәнзәләви әл-Казаниның (1855–1934) хезмәте. Аның аз билгеле «Нәфәис әс-сәлихат фи тазйил әл-бакийат әс-сәлихат» («Башка изге гамәлләргә өстәмә итеп изге гамәлләрнең зиннәтләре») дигән хезмәте турында сүз бара. Галимнең бу хезмәте Дагыстан суфый шәехе Шөһаеб бине Идрис әл-Багининең (1853–1912) күптән түгел генә фәнни әйләнешкә кертелгән «Табакат әл-Хваҗаган ән-нәкшбәндийә» («Нәкышбәндийә мөршидләре тормышы»)[1] гомуми хезмәте составына кертелгән һәм кулъязмада нәшер ителгән [Мусаев, Шихалиев, с. 37–43]. Китапның кереш сүзендә язылганча, аны редакциягә Дагыстан мөфтие урынбасары аша Дагыстан шазилий шәехе, Дагыстан галимнәре шурасы рәисе Арслан Гали әфәнде[2] тапшыра. Шунысын күрсәтеп китәргә кирәк, Мөхәммәд Морад әр-Рәмзинең бу хезмәте бүгенге вакытта бары тик шул алда әйтелгән Шөһаеб әл-Багини хезмәтендә генә барлыгы билгеле. Бу хезмәт берничә бүлектән тора. Авторның үз язмаларына караганда, аның бу хезмәте нигезенә ике китап алынган, беренчесе: Али бине әл-Хөсәен әл-Кәшифи каләме астынннан чыккан «әл-Бакыйат әс-сәлихат фи такриб әр-рәшахат» («Тамчыларга якынлашканда башка игелекле эшләр»). Монда Әбу Бәкер әс-Сиддыйктан башлап, Гобайдуллаһ Әхрарга кадәрле Нәкышбәндийә тарикате шәехләренең биографияләре искә алына. Икенче бүлек «Нәфәис әс-сәлихат фи тазйил әл-бакийат әс-сәлихат» («Башка изге гамәлләргә өстәмә итеп изге гамәлләрнең зиннәтләре») дип атала, аның авторы: татар гали-

ме – Мөхәммәд Морад әр-Рәмзи әл-Мәнзәләви әл-Казани. Бу икенче бүлектә Мөхәммәд Заһир әс-Самаркандидан (1529 елда вафат) башлап, Хәлил әл-Багдадига (1779–1826) кадәрле нәкышбәндийә шәехләренең биографияләре карала. Өченче бүлектә калган нәкышбәндийә шәехләренең биографияләре китерелгән. Бусы – хезмәтнең оригиналь өлеше, аны Шөһаеб әл-Багини үзе язган. Йомгаклау өлешендә нәкышбәндийә тәрикатенең кагыйдәләре, үзенчәлекләре һәм этикасы буенча кайбер аңлатмалар бирелгән [Шөһаеб бине Идрис әл-Багини, б. 19–20].

Мөхәммәд Закир әл-Чистави турында кыска белешмәләр Мөхәммәд Морад әр-Рәмзи язган: «Мәүләнә шәех Мөхәммәд Закир әфәнде әл-Казани әл Чистави, Аллаһы аңа озын гомер бирсен, аны һәм безне Үзенең рәхмәтеннән ташламасын. Ул (*хәлифәнең*) халидий тармагының (нәкышбәндийә тәрикатенең) безнең җирләрдәге данлы дәвамчысы, барысына да үрнәк булып хезмәт итә. Казанда, бу шәһәрнең галимнәре һәм башка затлы вәкилләре аның артыннан бармаган бер генә почмак та калмады инде. Ул, шул ук вакытта, бар фәннәр, бар рационалистик һәм традицион фәннәр өлкәсендә дә зур галим булды. Ул фикһ гыйлемен бу өлкәдә бердәнбер булган зур галим, мәрхүм Габдуллаһ әл-Мучаскаравидән өйрәнде, Аллаһы аны рәхмәтеннән ташламасын. Аннан соң Мөхәммәд Закир әфәнде, фәннәрдән үз иленә күп еллар буена файда алып, ул белемнәрен замандашлары мәнфәгатендә файдаланып, мөгаллимлек эше белән шөгыльләнде. Аннан соң ул халидийа (Нәкышбәндийә мәзһәбе) тәрикате юлына басып, шәех Мәхмүд-әфәнде әд-Дагыстани әл-Алмалидан, җаны изге булсын аның, зикер әйтергә өйрәнде. (Мәхмүд әл-Алмали бу зикергә) Юныс әл-Халиди шәехтән, ә анысы (үз чиратында) – Габдуллаһ Әрзанҗани шәехтән өйрәнде. Алда әйтеп кителгәннәрне (бу зикер турында) мин, (Мөхәммәд) Закир әфәнде шәехнең үз куллары белән язган үз хатыннан күчереп алдым. Ләкин без Хәлил Баш шәехтән, Юныс әфәнде тәрикатькә Яхъя бәк (җитәкчелегендә) кергән, ул Габдуллаһ әл-Мәкки белән очрашмаган дип ишеткән идек. Аллаһы Тәгалә бу турыда күбрәк мәгълүматлырак инде. «...барсы да аларга каян эчәргә тиешлеген белде» [Коръән: 2; 60].

Мәхмүд әфәнде (әд-Дагыстани) тәрикатькә Хәшим-әфәнде әл-Ямшани шәех (җитәкчелегендә), ә ул – Зыяддин Зөбәйһуллаһ эш-Ширвани шәех (җитәкчелегендә) кергән. Соңгысы Мәүләна Халид, Аллаһы аның күңелендәге югары серләрен изге кылсын (дәвамчысы булган). Бу юллар авторы күп тапкырлар аның белән танышу мәртәбәсенә ия булды.

Мин Аллаһыны аңлауга ирешкән (гариф), Аллаһының бавына ныклап тотынган галим Мөхәммәд Морад бине Габдуллаһ әл-Казани шәех (хезмәтләренә) тап булдым, (аларны) кыскарттым, эшләп бетердем ...» [Шөһаеб бине Идрис әл-Багини, б. 346–347].

Шөһаеб әл-Багининың шул ук җыентыгында Мөхәммәд Закир әл-Чиставиның гарәп телендәге үзе язган «Табсират әл-мөршидин» («Мөршидләрнең үгет-нәсыйхәтләре») дип аталган хезмәте дә бар. Бу хезмәттә нәшер итүченең кереш сүзе һәм Мөхәммәд Закир турында кыскача биографик белешмәдән тыш, нәкышбәндийәдәге ритуаль практика мәсьәләләренә, кайбер суфыйчылык терминнарына җентекле аңлатма бирелә.

Габделхәлил әл-Гата әл-Бәкриның хатирәләрендә, Мөхәммәд Закир әл-Чиставиның Мәхмүд әфәндене (әд-Дагыстани) үзенең мөршиде итеп сайлап алуының сәбәпләре турында менә нәрсәләр язылган: «Миңа безнең галим туганыбыз Хәбибулла әл-Каһи шулай дип әйткән иде: «Табсират әл-мөршидин» авторы, Мөхәммәд Закир шәех, укымышлы, мөлкәткә ия, таза кеше булган; ул Мәхмүд әфәнде шәехне шәех итеп танымаган булган. Бервакыт төнлә, ул йоклаган вакытта, аңа Мәхмүд әфәнде килеп, таягы белән суккан. Ул йокысыннан уянган, аннан тагын йоклап киткән. Шуннан соң шәех тагын аның янына килеп, тагын бер тапкыр таягы белән суккан. Шуннан бу тагын уянган... Җиде тапкыр шулай кабатланган. Шуннан соң инде шәех бер сүз дә әйтми аның янына килеп баскан. Мәхмүд әфәнде аңа бу төнне төш булып кергән әлеге вакыйгаларны аңлаткан. Шуннан соң ул аның тәрикатен кабул итеп алган һәм камил шәех булып киткән».

Аның турында шулай ук безнең тәкъва туганыбыз Сәйфулла ән-Ницубкри: «Мин Мәхмүд-әфәнде шәехнең үз куллары белән Мөхәммәд Закир шәехка язган хатларын күрдем. Анда аңа багышлап язылган шундый юллар бар иде: “Син дәрәҗәләр буенча *(дәрәҗәт)* безне узып киттең. Хат бетте”. Аллаһ, аларның икесеннән, бездән һәм бар мөселманнардан да разый булсын».

Шулай итеп, рухи генеологик тармак *(шәҗәрә),* шул ук вакытта мөселман элитасының мәшһүр вәкилләренең биографияләрен (*табакат*) үз эченә алган агиография жанры гарәп телле татар әдәбиятында билгеле бер урын алган. Гарәп телле һәм гарәп графикалы татар әдәбияты турында аерым сүз алып барган вакытта, татар мөселман рухи элитасы вәкилләренең Россиянең төрле регионнарында таралыш алган күп хезмәтләре, кызганычка каршы, азагына кадәр өйрәнелмәгәннәр. Эзләнү эшләре татар дин галимнәренең яңадан-яңа хезмәтләрен ачыклый тора. Алар арасында гарәп әдәбияты традицияләрен кабатлаучылары да, һәм Идел-Урал регионы мөселманнарының дини мәдәнияте үзенчәлекләрен искә алып язылганнары да бар. Бүген, безнең илдә игътибарга лаек әйберләрдән, безнең ата-бабаларыбыз мирасыннан, безнең бөек шәехләребез, имамнарыбыз мирасыннан да зуррак игътибарга лаек булган башка берни дә юктыр, мөгаен. Аларның хезмәтләрен, тормыш юлларын өйрәнеп, без үзебезнең рухи тамырларыбыз белән бәйлелегебезне ныгытабыз.

## Әдәбият

*Амирханов Р.У.* Закир ишан Камалов и татарское просвещение // Гасырлар авазы = Эхо веков. 2001. № 1/2. С. 69–78.

*Амирханов Р.У.* Путь шейха Мухаммад Закира Чистави [Электронный ресурс] // URL: http://www.sufizm.ru/lib/douknow/chistavi/

*Амирханов Р.У.* Знаменитость всероссийского масштаба (Закир ишан Камалов) [Электронный ресурс] // URL: http://www.tataroved.ru/institut/novhist/publ/3/.

Коръән: 2; 60.

*Мәрҗәни Ш.* Мостафад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казань: Типолитография Имп. ун-та, 1900. Т. 2. Б. 207.

*Мусаев М.А., Шихалиев Ш.Ш.* Чудотворства святых в дагестанском арабоязычном суфийском биографическом сочинении «Табакат ал-Хваджакан ан-накшбандиййа вас адат ал-машаих ал-Халидийа ал-Махмудийа» // Исламоведение. 2011. № 4. С. 37–43.

*Фәхреддин Р.* Асар. Т. 3, 4 / фәнни мөхәррир Миркасыйм Госманов. Казан: Рухият, 2010. 648 б.

*Хәсән бине Мөхәммәд Һилми әл-Каһи.* Сираҗ әл-сәгадәт фи сийар әс-садат (гарәп телендә). Махачкала, 2011.

*Шихалиев Ш.Ш.* Сайпулла-кади // Ислам на территории бывшей Российской империи: Энциклопедический словарь / под ред. С.М. Прозорова. М. 2003. Т. 4.

*Шөһаеб бине Идрис әл-Багини.* Табакат әл-хваҗаган әл-Нәкышбәндийә вә садат машаих әл-халидиййә (гарәп телендә). Дамаск, 1999.

## Искәрмәләр

[1] هدايات الزمان في طبقات الخواجكان النقشبندية و سادات المشايخ الخالدية المحمودية. دمشق: دار. النعمان للعلوم،٢٠٠٢. – ص. ١ – ٨٧

[2] Арслангали Гамзатов (1954 елда туган), шазилий тәрикате шәехе, Дагыстанның галимнәр Шурасы рәисе, Буйнакскидагы С.-К. Башларов исем. Дагыстан ислам университеты ректоры.

***Хасавнех Алсу Әхмәдулла кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

***И. Нигъмәти***

# ЧОРЛАР ЧАТЫНДАГЫ ҮЗГӘРЕШЛӘРГӘ КАБАТ ТУКТАЛЫП...

*(Г. Гыйльманов һәм Ф. Бәйрәмова әсәрләренә күзәтү)*

Интерес к вопросам фольклора и мифологии занимал значительное место в научных исканиях ученых XIX века. Например, исследования К. Насыйри «Поверья и обряды казанских татар», «Образцы народной литературы казанских татар» стали отправной точкой в процессе изучения фольклора. Религиозные и мифические темы в современной литературе в теоретическом и историко-литературном аспектах остаются актуальными и в сегодняшние дни. В данной статье даётся анализ произведений современных татарских писателей Ф. Байрамовой «В стране великанов» и Г. Гильманова «Лесные духи» сквозь призму мифологических и религиозных представлений.

**Ключевые слова:** Г. Гильманов, Ф. Байрамова, мифология, ислам, сюжет, мифологический персонаж.

Татар әдәбиятының мең елдан артык тарихы булуы белән хаклы рәвештә горурланабыз. Әйтик, «Кыйссаи Йосыф» поэмасын (XIII йөз башы) төрки-татар язма әдәбиятының беренче классик әсәре дип саныйбыз. Шул чорлардан алып бүгенге көннәргә кадәр әдәбият белеме фәнендә, әдәби әсәрләрдә мифологик һәм дини темаларның хакыйкатьне аңларга һәм аңлатырга тырышу өчен игелекле бер гамәл икәнлегенә төшенә барабыз. Татар халкының мифларын өйрәнүнең шактый бай һәм үзенчәлекле тарихы бар. Татар мифларына багышланган беренче фәнни хезмәт XIX гасырның соңгы чирегендә дөнья күрә. Сүз күренекле мәгърифәтче-галим Каюм Насыйриның «Казан татарлары тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр» дигән бай эчтәлекле мифологик хезмәте турында бара. Анда Убыр, Албасты, Бичура, Шүрәле кебек «түбән мифология» затлары турында бәян ителә. Совет чорында татар галимнәре милли мифологияне өйрәнү эшеннән читләштерелә. Бары тик галим Нәкый Исәнбәт кенә татар мифларыннан гаять зур һәм бай хәзинә туплый. XX гасырның 70 нче елларыннан татар мифларына игътибар нык арта. «Татар халык иҗаты» сериясенең риваятьләр белән легендаларга багышланган томында мифологик хикәятләр махсус бүлек итеп бирелә. Ниһаять, 1996–2004 елларда милли мифларга багышланган махсус өчтомлык басыла.

Татар мифологиясен өйрәнгәндә, башлыча, яһүд, христиан, ислам диннәре, аларның Изге китаплары һәм аерым пәйгамбәрләрен һ.б. күз алдында тотабыз.

Әлеге диннәр бер-берсе белән дә тыгыз бәйләнештә барлыкка киләләр. Ислам аңа кадәр булган диннәрне, Изге китапларны һәм пәйгамбәрләрне инкарь итми. Киресенчә, алар ихтирам белән телгә алына. Изге китаптагы изге затлар – пәйгамбәрләр бер-берсенә шактый ук якын. Байтак мифологик сюжетлар һәм мотивлар: яһүд һәм христиан диннәренең аллалары һәм Коръәндә гәүдәләнгән Аллаһы Тәгалә тарафыннан Җиһан-Дөнья-Галәмне, Җирне, Күкне, Ай-Кояш-йолдызларны, Адәм галәйһиссәламне, Хаува ананы, аларның аерым атрибутларын һәм язмышларын барлыкка китерү; Адәм пәйгамбәр белән Хаува ананы җәннәттән читләштереп, җиргә төшерү; туфан суы һәм аннан котылу юллары; Җиһанның һәм Адәм галәйһиссәлам балаларының киләчәк язмышы – барысы да охшаш.

Милли мифологияне өйрәнүдә мифларга, төрле диннәрнең Изге китапларына гына түгел, ә бәлки саф әдәби китапларга да мөрәҗәгать итәбез. Кол Галинең Коръәндәге «Йосыф» сүрәсенә нигезләп язылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасында да ислам тәгълиматы белән бәйле Аллаһы Тәгалә еш кына борынгы төрки халыклар диненнән килгән Тәңре исеме белән атала:

«...Бар кылучы бер Тәңредер,
Җирдә, күктә юлларына ризык бирер,
Тәңремә, ризыкларга лаек торыр,
Сезнең безне бар итүче тик ул инде»

[Кол Гали, б. 13].

Поэманың сюжеты гына түгел, төп идеяләре дә төркиләрнең борынгы мифлары һәм ислам сюжетлары нигезендә оештырылган. Язма әдәбият әсәрләре милли һәм дини мифологияне өйрәнү өчен мөһим чыганак була ала икән, димәк, безнең көннәрдә миф һәм әдәбият мәсьәләләрендә дә бөтенләй яңача якын килергә мөмкин. Коръән кебек Изге китаптагы һәм борынгы мифлардагы билгеле сюжетларның, мотивларның күпчелеге хәзерге әдәбиятта чагылыш таба, соңгы елларда әдәби әсәрләрдә мифологик, дини темаларның һәм мотивларның чагылышына игътибар артты. Ни өчен артты? Дин тоту ирегә кайтты. Язучыларыбыз үз максатларына тизрәк ирешү – имгәнгән калебләребезне савыктыру өчен – әсәрләрендә борынгы мифологик һәм дини сюжетларны һаман да ешрак кулланa башладылар.

Ошбу өлкәгә иң элек мөрәҗәгать иткән шундый язучыларыбыздан Фәүзия Бәйрәмованың «Алыплар илендә» исемле повесте һәм Галимҗан Гыйльмановның дүрт бүлектән торган «Албастылар» исемле хыялый кыйссасындагы дини-мифологик мотивларга басым ясалды. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, әлеге әсәрләр галимнәр күзеннән читтә калмады, алар хакында Ф. Урманчеев, Д. Заһидуллина һ.б.ның әтрафлы мәкалә-хезмәтләре бар.

Танылган язучы Фәүзия Бәйрәмова моңарчы кешелекнең вак һәм пычрак тормышка кереп батканлыгын билгеләгән әсәрләрендә бүгенгене кире

кагу ноктасында төгәлли иде. Ә инде шушы хәлдән чыгуның бер юлы, бер мөмкинлеге Ф. Бәйрәмованың 2002 елда дөнья күргән «Алыплар илендә» повестенда ачылды. Әсәрдә кеше тормышындагы «кара таплар» берничә вариантта сурәтләнә: эчкечелек (авыл халкы, Җиһангир, Сәлим мисалында), наркомания (шәһәргә киткән авыл кешеләренең балалары-оныклары язмышы), байлык артыннан куу (Сәлим), битарафлык (авыл халкы). Шушы каралык кешеләрнең рухи дөньясын томалый. Төп сюжет сызыгында, әсәрнең буеннан-буена рухи фаҗига – кеше күңелләренең «сөрелеп-яраланып» беткән булуы һәм экологик фаҗига – болын, табигатьнең юкка чыгарылуы янәшә сурәтләнә. Автор әлеге ике фаҗигагә китергән сәбәпләрне дә бик төгәл билгели һәм бергә үрә. Табигатьне байлыкка табыну юк итсә, кешеләрнең рухи байлыгын – тарихны оныту, дөрес кануннар белән яшәмәү бетерә, ди сыман.

Әсәрнең исеме үк «Алыплар илендә» дип аталуы аңа мифологик сер яшеренгән булуы хакында төрле уйлар тудыра. Безнең борынгы бабаларыбыз кемнәр булган? Каһарман Алыплар кемнәр ул? Татар халык әкиятләре, дастаннарында да Алып батыр образлары еш очрый. Әсәрдәге Алыпларның кайчандыр зур канатлы еланнар – аждаһалар белән көрәшә-көрәшә яшәүләре әлеге мифик образларның Идел буе халыкларында ислам диненә кадәрге чорда туган риваятьләр булуын ачыклый. Аждаһа да бит төрки халыклар мифологиясендә кешеләргә каршы куелган иң төп мифик затларның берсе. Әмма әсәрдәге төп герой Камилнең әтисе Җиһангир әлеге мифны гел чынбарлыкка бәйләп сөйләшә. «Биредә шушы төбәкнең иң борынгы кешесе Тимершәех яшәгән. Аның буе 9 катлы йорт биеклегендә, ул дөньядагы беренче кеше – Адәмнең улымы, оныгымы булган, диләр. Астагы болында алар намаз укыганнар, җыелышып киңәш иткәннәр. Җиһангирнең фикерен Камилнең әбисе дә көчәйтә: «Пәйгамбәребезнең хәдисләрендә беренче кеше Адәм галәйһиссәламнең буе 60 терсәк, иңе 7 терсәк, ягъни буйга 30 метр, иңгә 3 метр тирәсе булган. Икенче бер хәдистә җәннәткә керүче мөселманнар да атабыз Адәм кыяфәтендә – 60 терсәк озынлыкта булырлар, диелгән. Беренче кешеләрнең гаять көчле булулары турында Коръән сүрәләрендә дә еш бәян ителә», – ди. Сәлимханның кызы Камилә дә компьютердан Алыплар турында галимнәр фикерен җиткерә: «Пасха утравындагы гаҗәеп зур таш сыннарны кемнәр ясаган? Гади кеше көче җитмәслек Мисыр пирамидаларын кемнәр төзегән? Сардиния утравындагы биек башня-манараларны кемнәр салган? Эш кораллы таш һәм балта гына булган заманда дөньяның төрле почмакларында – Мексикадан алып Мисыргача – кем, нинди максат белән шундый зур биналар төзи алган? Бу эшне гигант кешеләр, ягъни Алыплар башкарган дигән фикер дә яши. Туфан суыннан исән калган Нух пәйгамбәр нәселе дә шундый ги-

гант кешеләр булган. Атлантида да Туфан суыннан соң юкка чыккан». Нух галәйһиссәлам турында Коръән Кәримнең 43 жирендә искә алына.

«Алыплар илендә» әсәренең төп сюжет сызыгы – Камилнең дингә килү тарихы – бер канунны югары күтәрә: бары тик дин генә җәмгыятьне һәм кешене рухи юкка чыгудан коткару, камилләштерү көченә ия. Идеяне автор Алып баласы исеменнән әйттерә: «Сез Аллаһ кушканча яшәмисез, бөтен бәхетсезлегегез шунда», «Аллаһ кушканча яши башларга... Хәрәмнән аерылырга... Барыгызга да намазга басарга... Ярдәмне бары тик Аллаһтан гына сорарга, Аннан гына өмет итәргә...». Төп сюжет сызыгындагы чишелеш – авылны яшен сугу – гөнаһлары өчен кешеләргә Аллаһының җәзасы булуы аңлашыла. Сәлим бай һәм аның хатыны, Җиһангир, яшь наркоманнар язмышлары да шушы идеяне көчәйтеп килә. Әсәрләрдәге мифологик катлам, Алыплар турындагы риваять хыял, саташу, төш кебек бирелә. Ул гайре табигый хәлнең Аллаһка килү юлын тизләтүен канун итеп раслый. Ләкин әсәр бер ноктада гына тукталып калмый: кешелек тарихына караган, җирдә тормыш – тереклек барлыкка килүгә кагылышлы материал милли төсмер белән дә сугарылган. («Алыплар – татарларның беренче бабалары»). Язучы татарлар тарихын югары күтәрә, аларның үз үткәнен белмәвен әһәмиятле мәсьәлә итеп аерып чыгара. Тарихны белмәү һәм белергә теләмәү рухи бушлыкның, кешелек үсешендә ялгыш юлга кереп китүнең бер сәбәбе төсле билгеләнә. Әсәрне язганда авторны, татар әдәбиятының алтын чоры – XX йөз башы әдипләрендәге кебек үк милләт язмышы, аның киләчәге борчыганы сизелеп тора. Әсәрнең үзәк герое – малай кеше, саф күңелле, изге теләкле авыл малае. Автор аны аллегорик образ, милләтнең киләчәге итеп күзаллаган. Анда көрәшче сыйфатлары да бар: «Ул бүген бу чоңгылны җиңәргә тиеш иде! Бәлки аны алда әле моннан да куркынычрак чоңгыллар көтеп торадыр...». Әсәрнең үзәгендә Камилнең борынгы бабалар, Алыплар дәвамчысы икәнлеге, аның ислам динен тотучы булуы ассызыклана. Язучы өчен намазга басу иманлы булуга тиң. Повестьтагы мифологик катлам татар мифларындагы мәгълүматны кабатлый: бик олы гәүдәле кешеләр яшәве, аларның таулардан тауларга атлап йөрүе, Алып баласының кулына гадәти кешене тотып алуы, киләчәк кешеләрнең шундый буласын хәбәр итү һ.б. Автор мифологик катлам тәшкил иткән мондый материалны җентекләп һәм җылы төсләр, мөнәсәбәт белән тасвирлый. Ислам динен кеше һәм яшәеш проблемаларын хәл итү юлы, дип күтәрә. Ф. Бәйрәмова иҗаты төрлелеге, милли әдәбиятта яңа эзләр салып, үзенчәлекле һәм татар укучысы яраткан әсәрләр тудыруы белән сокландыра.

Инде язучы Галимҗан Гыйльмановның «Албастылар» романында дини һәм мифологик мотивлар бәйләнешен күздән кичерик.

XX–XXI гасырлар чигендә татар прозасы мәгънә һәм форма ягыннан бик көчле үзгәрешләр кичерә. Әсәр чынбарлыгы үзмаксат булудан туктый. Авторның яшәешкә карашын ачыклауда аерым герой мисалында тормыш, яшәеш, кеше хакындагы уйланулары үзәк мәсьәләгә әйләнеп кала. Моңа кадәр милли әдәбиятта күзәтелмәгән үзенчәлекле эчтәлекне укучыга җиткерү өчен бер әсәр чикләрендә төрле темалар, әдәби алымнар, стильләр, төрле әдәби-тарихи традицияләрнең очрашуы кирәк булып чыга. «Албастылар»да шушы синтез, кушылма уйланмада күзәтелә башлый. Авторның ни өчен албастыларга мөрәҗәгать итүен ачыклаганчы, әүвәл татар мифологиясендәге Албасты образына күз салып үтик.

Татар мифологиясендә Албасты – түбән рухларның берсе. Кеше яшәми торган йортларда, ташландык җирләрдә, кырларда, чокыр буйларында яшәүче кара көчләргә, явыз рухларга Албасты дип исем биргәннәр. Бу атаманың килеп чыгышы төрлечә аңлатыла: «“кул” сүзенең борынгы “әл” вариантын кушып ясалган әлбасты (кул белән басты), ал-басты (алга чыгып өстеңә басты). Ал төстәге хәшәрәт басты, дип тә аңларга мөмкин. Гомумән, ал төс – явыз рухлар төсе. Албасты, Убыр, Өрәк (үзе ут), Бичура, Шүрәле кебек рухларның ал-кызыл төстә бирелүе гадәти хәл. Каюм Насыйри албастының кеше кыяфәтендә йөрүен язган. Албастының гәүдәсе зур авырлыкта, кешеләрне буып та газаплый. Имеш, ерак чакрымнар буе бер агач, таш, авыл булмаган ялан кырда күкрәк читлеге ватылган кеше гәүдәсе табып алсалар, моны һичшиксез, Албасты эше дигәннәр» [Татар мифлары, II т., б. 20–21].

Әсәрдә беренче төп сюжет Хәлим исемле авыл егетенең тормышы хакында сөйли: аның әнисе, авылдашлары белән мөнәсәбәтләрен күрсәтә, өй салуын, өйләнүен, хатынын югалтуын бәян итә һәм нәни кызын ияртеп, туган төбәгеннән чыгып китүе белән тәгалләнә. Хәлим белән танышкач, аның безнең замандашыбыз кебек гап-гади, көчле, яхшы күңелле егет булуын беләбез. Авылы да күңелгә якын, таныш. Әнисе Сания дә, безнең әниләр кебек, кадерле җан. Яшәвенең бөтен мәгънәсе бердәнбер улында.

Әсәрдә, беренче сюжет яссылыгыннан караганда, икенче бер үзенчәлекле юнәлеш Хәлимнең саташуы, уйлану-хыяллануы кебек тоела. Бу очракта ул – мифологиядән килгән албастылар хакындагы мотив. Язучы әлеге хыялны яңа чынбарлыкка әйләндергән: Хәлим буыннар кылган хатаның, явызлыкның җәзасын күреп, албастылар яши торган утарга эләгә, хәтерен югалта, күп еллар элек гаип булган әтисен, мәхәббәтен очрата, хатынын һәм кызын алып, бу тозактан котыла – җиңеп чыга, ләкин албасты сихере Хәлимгә генә түгел, аның нәсел дәвамына да кагыла – кызы әнисез кала. Икенче мифологик сызык беренчесенең азагына килеп ялгана: сихерчеләрне җиңгән Хәлим авылдашларының битарафлыгын һәм усаллыгын күтәрә

алмый, кызын бу тирәлектә калдырмаска теләп, урман юлы белән китеп бара.

Әсәрнең беренче томында укучы үзен исламга кадәрге чорга килеп кергән кебек тоя. Ислам динен тотучы әнисеннән, Ак бабаеннан, күршеләреннән аерылып, җеннәр, албастылар мыжлап торган мәҗүси урманга килеп эләгә һәм «бисмиллаһ» догасын да юньләп белмәгән егет урмандагы кара көчләр арасында ялгызы, яклаучысыз кала.

Албастылар ни өчен әсәрнең төп герое Хәлимнән үч алырга уйлаган соң? Имеш, хәзерге Кампәрле авылы урынында, тайга үзәнендә сихерче карчыклар гаиләсе яшәгән. Бу урынны аучылар әйләнеп узганнар, ә сихерчеләр үзләре кешеләргә зыян салмаган. Әмма начарлык кылырга тырышкан бәндәләргә мәрхәмәтсез булганнар, аларны аңсыз, хәтерсез калдырганнар. Бу тирәдә яшәгән сихерчеләрнең тынычлыгын берничә татар гаиләсе боза. Татарлар башта шулар янына берничә йорт салып керәләр. Бөтен зәхмәтне сихерчеләрдән күрә башлыйлар. Ниһаять, сихерчеләрне куып җибәрәләр, ә башлыкларын агачка бәйләп ут төртәләр. Татарның ыру башлыгы Хәлимнең борынгы бабасы булган. Соңыннан Кампәрле авылын да сихерчеләр авылы дип йөртә башлыйлар.

Икенче томда исә без инде бөтенләй башка Хәлимне күрәбез. Ул инде динебез исламның изге догалары белән коралланган, кесәсендә хәтта догалык бөтие дә бар, күңеле дә ислам дине белән нурланган. Моңа ирешүдә аңа авылдагы Ак бабае нык ярдәм итә. Хәтта кабаттан урманга барганда аңа атына утырган Хозыр пәйгамбәр дә очрый. Ул Хәлимгә киләчәгеп сөйләп бирә, яшәү мәгънәсе турында сокландыргыч әңгәмә кора. Саубуллашканда артыш куагы кәүсәсеннән юнып ясалган таяк бүләк итә. Нәтиҗәдә, бу сәфәрендә Хәлим урман аланындагы явыз көчләрне җиңә. Икенче бүлек үзе дә буеннан-буена Коръән сүрәләрендәге аятьләр белән үрелеп бара. Алдагы ике бүлектә исә, кешедән өстен көчне – албастылар сихерен җиңеп, аклык-матурлык, тынычлык оясына – авылына кайткач, яраткан хатынын да, ышанычын да югалтып, тагын чыгып китәргә мәҗбүр була – авыл халкы үзе дә албастыга әверелә башлаган икән.

Әсәрнең төп идеясе бүлек саен сурәтләнеп, искә төшерелеп килгән олы юлга яшеренгән. Юл – кеше гомере. Анда очраган явызлык һәм изгелек – тормышны хәрәкәткә китерүче көчләр булып күзаллана. Кеше әнә шул юлдан изгелек ярдәмендә явызлык белән көрәшеп яши, хакыйкый урталыкны эзли. Ялгыш юлга кереп киткән авыл, җәмгыять өчен дөрес кануннар нинди булырга тиеш соң? Бу сорауга Ак бабай болай дип җавап бирә: «Кешеләр бер-берсенә шәфкатьле булсалар, изгелек кылсалар, бер-берсен кичерсәләр – иман шул инде». Җәмгыятьтә исә яхшылык түгел, явызлык алдан йөри. Авыл һәм урман өчен уртак булган табигать һәм кеше дөньясында кисешүче тагын бер дөнья – ышанулар дөньясы бар. Аллаһы Тәгаләгә

ышану исә әлеге явызлыкка каршы торырлык рухи көч бирә, өмет уята. Табигать кануннарын саклап яшәргә чакырса да, язучы ислам динен мәҗүси ышанулардан өстен куя. Хәлимгә ак-кара көрәшендә ярдәм иткән догалар, Хозыр кебек карт һәм артыш таягы – ислам дине атрибутлары. Дингә мөрәҗәгать итү – бүгенге татар әдәбияты өчен яңа күренеш. Яңадан мәҗүси урманга албастылар утарына әйләнеп кайткан Хәлимнең «Әлхәм» сүрәсен укуы, әнисе өйрәткән догаларны исенә төшерүе әсәр тукымасына яңа сулыш бирә. Язучы төп сорауга да җавап бирергә онытмый: бу хакыйкатьне без Хозыр галәйһиссәлам, дип кабул иткән ак сакаллы бабайдан әйттерә: «Җир йөзендә һәр адәм баласы – Алланың бер колы, димәк, изге зат. Ә һәр изге затта пәйгамбәрлек бар. Җир пычрагына буялган саен, кеше пәйгамбәрлектән ерагая, еш кына Аллаһы Тәгалә биргән сыйфат-хасиятләрен бөтенләй югалта». Әсәрдә ислам дине кануннары белән яшәгәндә генә изгелеккә, арулыкка, бәхеткә, максатка ирешә алачакбыз, дигән фикер үткәрелә. Коръән дә – адәм балаларын тугры юлга өндәргә дип, соңыннан үкенмәсеннәр өчен алдан ук кисәтеп кую максаты белән Аллаһ тарафыннан Пәйгамбәргә иңдерелгән изге Китап. Коръән – могҗизалы, гыйбрәтле хикәятләр китабы. Коръән ул – гадел яшәү ысулы. Коръән – гүзәл әхлакка, пакьлеккә, сафлыкка өндәүче маяк.

Узган гасырның Октябрь түнтәрелешеннән соң килгән буыннар, әнә шул гүзәл әхлактан әкренләп ераклаша барды. Мәчетләр җимерелеп, алардан склад, клуб, сельсовет ясап, халык Коръәнсез калды. Әмма иманлы кешеләрнең йортында, күңелендә Коръән саклана килде. Татар әдәбияты нинди генә гүзәл әсәрләр иҗат итмәсен, Коръәнсез ятим иде. Әмма узган гасырның 90 нчы елларында башланган үзгәрешләр татар язучыларының иҗатына да уңай йогынты ясады. Максатларына ирешүдә ислам динен байрак итеп алган бер төркем язучылар үсеп чыкты. Без шушы хезмәтебездә анализларга алган «Алыплар илендә» һәм «Албастылар» әсәрләренең авторлары Фәүзия Бәйрәмова белән Галимҗан Гыйльманов әдәбият тарихында, мөгаен, әлеге игелекле юнәлешнең чишмә башында торучылар булып калырлар. «Алыплар илендә» төп сюжет сызыгы – Камилнең дингә килү тарихы – бер канунны югары күтәрә: җәмгыятьне һәм кешелекне рухи юкка чыгудан коткару, камилләштерү көченә бары тик дин генә кодрәтле. «Албастылар» романында исә төп идея әсәрнең эченә яшеренгән олы юлга бәйләнгән. Юл – кеше гомере. Кеше әнә шул юлдагы изгелек ярдәмендә явызлык белән көрәшеп яши. Татар әдәбиятында дингә мөрәҗәгать итү матур, табигый күренеш булып, алда да мәгънәле әсәрләр туар дип ышанабыз.

**Чыганаклар һәм әдәбият**

Әхмәд ибн Фадлан китабы. Казан, 2003.

*Бәйрәмова Ф.* Алыплар илендә. Казан, 2002.

*Гыйльманов Г.* Албастылар. Казан, 2003.

*Давлетшина Л.* Мифологизм в татарской прозе конца XX – начала XXI века. Казань, 2005.

*Заһидуллина Д.* «Албастылар» яки татар прозасында яңа сыйфатлар… // Казан утлары. 2001. № 11.

*Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф. Казан, 1983, 13 б.

Коръән. Казан, 2001.

*Насыйри К.* Сайланма әсәрләр: 2 томда: Т. 2. Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр. Казан, 1975.

Пәйгамбәрләр тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 144б.

Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / төз. С. Гыйләҗетдинов. Казан, 1987.

Татар мифлары. 3 томда. 1 том. Казан, 1996.

Татар мифлары. 3 томда. 2 том. Казан, 1999.

*Урманчеев Ф.* Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек. Казан, 2008.

*Хисамов Н.* Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә». Казан, 2006.

***Ирек Нигъмәти,***

*Татарстан Фәннәр Академиясенең Татар энциклопедиясе*
*һәм төбәкне өйрәнү институты фәнни хезмәткәре*

УДК 930.271

***М.И. Әхмәтҗанов***

# С.-ПЕТЕРБУРГНЫҢ ТАТАР ЗИРАТЫНДАГЫ ТАШБИЛГЕ ТЕКСТЛАРЫ (1843–1986)

В статье излагается краткая история мусульманского участка Ново-Волковского кладбища, дается описание надписей на сохранившихся надмогильных памятниках татар.

**Ключевые слова**: С.-Петербург, эпиграфические памятники, история, наследие.

Санкт-Петербург шәһәренә нигез салыну тарихы татар халкы язмышы белән тыгыз бәйләнгән.

1703 елда Петербург каласы салына башлагач, рус хөкүмәте боерыгы белән, татар халкы шәһәр төзелешенә күпләп мәҗбүр ителә. Урман кисү, аны тиешле урынга илтеп җиткерү, гомумән, коточкыч авыр әлеге хезмәттә бик күп кешенең гомере өзелә. Кронштадт каласы диңгез базасы буларак корылгач та, анда, матрослар булып, күп татар егетләре хезмәт итә, бер өлеше шунда яшәп тә кала. Шунлыктан, С.-Петербург һәм Кронштадт калаларында, табигый рәвештә, татар-мөселман зиратлары да барлыкка килгән. Ләкин өч йөз еллык тарихның йөз илле елга якын (1703–1843) чорында бу төбәкләрдәге татар зиратларының кай урыннарда булулары турында төгәл мәгълүматлар юк.

Бүгенге көндә С.-Петербург шәһәрендә 3 мөселман зираты бар (Яңа Волков, Көньяк һәм Ковалеев). Яңа Волков – иң борынгысы.

Волков каберлеге кайчан барлыкка килгән соң? Бу хактагы ышанычлы хәбәр С.-Петербург татарлары арасыннан чыккан, шәһәрнең татар тарихы буенча тирән белемле зыялысы Дауд Габделәхәт улы Әминовның бай эчтәлекле китабында урын ала [Аминов, 1994]. Аның язуына караганда, Патша сарае каршында хезмәттә торучы гвардия корпусы ахуны Җиһангир Кантемиров тырышлыгы белән шәһәр янындагы Волков авылы крестьяннарыннан 1827 елда 2 дисәтинә (2,18 га) җир сатып алырга рөхсәт бирелә. Моннан Волков кырындагы Иске татар зиратының тарихы башлана [Шунда ук, б. 19]. Истәлекләрдән күренгәнчә, бу урынга Әби патша (Екатерина II) заманында әсирлектә үлгән төрек хәрбиләрен күмә торган булганнар [Аминов, с. 19; Андреев, Кобак, с. 467].

Соңыннан бу зират янында рус зираты барлыкка килеп, анда 1941–1944 елларда, Ленинград камалышы вакытында ачлыктан үлгән йөзләрчә мең кешенең мәетләре күмелгән.

Волков зиратында тарихи шәхесләрдән Гомәр Бакиров (1780–1828) һәм Исмәгыйль Ак-

чурин (1860–1900), Советлар Союзы Герое Акбулатов, профессор Габдрахман Таһирҗанов (1907–1983), Петербург университеты укытучысы Ибраһим Мирзаев (1860 елда вафат), сәүдәгәр Гатаулла Бәйрәшев (1846–1908), Россиядәге тәүге татар гәзите «Нур»га нигез салучы һәм аның беренче баш мөхәррире Гатаулла Баязитов (1847–1911) җирләнгән.

Зираттагы кабер ташъязмаларын өйрәнә башлагач, андагы ташларның абсолют күпчелеге XX йөзнең икенче яртысына караганлыгы мәгълүм булды. Борынгы ташлар исә бик сирәк күренә.

Ташъязмаларда теркәлгән текстлардагы исем-фамилияләр, туган-үлгән еллар, кайдан килүләрен теркәгән атамалар – ислам диненә, татар теленә мөнәсәбәтне ачыклау белән беррәттән, Петербург татарларының ни дәрәҗәдә милли тормыш белән яшәүләренең күрсәткече һәм аларның тарихи сәхифәләре дә.

С.-Петербург шәһәренең Волков зиратында 1986 елның 4 июнендә булып, безнең тараф-тан 150 гә якын эпитафик язма күчереп алынды. Мәсәлән, алар арасыннан:

1. Түбән Новгород өлкәсе Ключище авылыннан килгән Зиннур Камалетдин улы Гаязов ташбилгесендә текстлар татар һәм урыс телләрендә язылган. Татар телендәге текст: «Гурки ублысы Ключишча карйәсе гражданы Зиннур Камал углы Гаязов (1929–1970)», рус телендәге текст бик хаталы язылган: «Камальдинов Зинур Гаязов» .

2. «Ошбу кабер иясе Исмәгыйль Габделхәлим углы Кучайыв. Матфий авылы Мардувийә ублысты: 1927–1954».

3. «Тормадың син,

Ташлап киттең Тәңреңә.

Гомерлеккә ядкәр итеп

Таш куябыз кабреңә

Дашкин Алим (1910–1970)» ташбилгесеннән.

4. «Очты дөнья читлегеннән

Тарсынып күңлең кошы

Шат яратса да җиһанга

Ят яраткан Раббысы.

Вельшаков Ренат Хасанович (1925–1980)» ташбилгесеннән.

5. «Тарих вафат ... хаҗи Ак-Мөхәммәд Таҗер... ... шты 12 җөмадил-әүвәл 1259 сәнә» (*июньнең 10 ында, милади 1843 ел. – М.Ә.*).

Кара мәрмәрдән ясалган таш җирдә ауган хәлдә ята иде.

6. «Бу кабергә мәдфүн хафизе кәламулла Әхмәтгәрәй бине Сиддыйк Узбаков Ендовище карйәсе. Аллаһ рәхмәт әйләсүн. 1878–1919».

7. «Бисмиллаһир-Рахманир-Рахим

Майкилдинев Муса Галимхуҗа углы (1894–1963)».

8. «Котойыва Хәлифә Айзатулла кызы

Чүриле авылы (1891–1963)».

9. «Тамбов губернасы Түбән авылының әл-хаҗел-хәрәмәйн, мәрхүм мәгъфүр Таҗетдин хаҗи Хәмзә углы Богданов 1906 сәнәдә үктәбернең дүртенче көнне дарел-фәнадин дарел-бәкайә [рихләт итди]...»

10. «Коръәнхафиз Садретдин бине Сәйфетдин углы. Тугды йегерме өчүнчи мартта 1863 нче йылда. Вафат булды алтынчы үктәбердә 1935 нче йылда».

11. «Көлли нәфсин заикател-мәүт ... Штабс-капитан Нәҗметдин Җабраил углы Сәгыйдов 1915 нче йылның 11 нче август көнендә Брани даласында шәһид булды. Рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтә вә сәгатә».

«Нажмуддин Джабраил оглы Саидов убит в бою под Брест-Литовском 11го августа 1915 г. Прожил 27 лет».

12. «Лә иләһә иллә Аллаһу

София Матвеевна Байрашевская

1839–1909».

13. «Лә иләһә

Казимов Мамед-Али Али-Акперович 1911–1971».

14. «Әгузе билләһи мин әшшәйтан ир-раҗим бисмиллаһир-Рахманир-Рахим. Лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәд рәсүлуллаһ.

Шарифа Александровна Александрович род. в Слоним Гродненской губ., ум. в Петрограде 10 апреля 1919 г. 64 лет».

15. «Көллү нәфсин заикател-мәүт Бәхтийаров Садыйк Фазлулла углы вафат».

16. «Бисмиллаһир-Рахманир-Рахим. Иннә лилләһи вә инна иләйһи раҗигун.

Мерсаитов Сафа, 1907–1945.

Горьковская обл. д. Кочко-Пожарки».

17. «Лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәд рәсүлуллаһ.

Жамлиханов Абдулахат Умарович

1905–1973».

18. «Әл-хөкме Лилләһи

Котлуиддинова Мәрйәм Вәли кызы 1896–1964.

Кутлитдинова Марьям Валеевна (1896–1964).

дер. Ключище».

19. «Кутыев Шакир Сабатович (1890–1965)».

«Әгузе билләһи мин әш-шәйтан ир-раҗим бисмиллаһир-Рахманир-Рахим. Лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәд рәсүлуллаһ».

20. «Әгузе билләһи мин әш-шәйтан ир-раҗим бисмиллаһир-Рахманир-Рахим. Лә иләһә иллә Аллаһу Мөхәммәд рәсүлуллаһ.

Максутова Гаишә Янбулатов Гыйззәтулла кызы.

Максутова Айша Иззатуловна».

21. «Бисмиллаһир-Рахманир-Рахим. Майгильдинов Муса Галимхуҗа углы (1894–1963).

Майгильдинов Муса Алимович (1894–1963)».

22. «Маскаев Хасан Шабанович. 1984.6.VI».

«Бисмиллаһир-Рахманир-Рахим инна иләйһи раҗигун»

23. «Ибрагим Хасанович Мещеров

1912–1983. Деревня Акчеевь».

24. «Бисмиллаһир-Рахманир-Рахим...

Мамин Хесяен Мустафиевич (1909–1971».

25. «Бисмиллаһир-Рахманир-Рахим

Мамин Сулейман Мустафиевич (1911–1947)».

26. «Бисмиллаһир-Рахманир-Рахим...

Майгельдинова Җәмилә Хөснетдин кызы (–1970. үктәбер)

Пенза губер. д. Чудовка (Чудилка иле)».

27. «Бисмиллаһир-Рахманир-Рахим.

Мамлеев Алим Нязмидинович

1880–1969».

28. «Садретдинова Рабига Садретдин кызы (1885–1971). Горьков. обл. дер. Ендовище».

29. «Корънхафиз Садретдин бине Сәйфетдин углы. Тугды йегерме өченче мартда, 1863 елда. Вафат булды алтынчы үктәбердә 1935 нче йылда: 1863–1935.

Көллү нәфсин заикателмәүт...»

30. «Салимова Мабрура (1902–1965), Ленинград. Байда авылында туган, Гурьев өлкәсе Денгиз р-ны».

31. [Гарәпчә догалар]: «Бисмилла...»

Тенишев Феттях Хусяинович 1884.10.XII–1965.10.XII».

32. (Гарәпчә догалар...)

«Тенчурин Хасян Узбекович (1881–1958)».

33. (Гарәпчә догалар...)

«Утемишева Каймя Атауловна 1898–1968.

дер. Танкаевка Пензенской обл.».

34. «Ураев Усман Фахретдинович 1910–1951».

35. [Текст тулаем татар телендә, гарәп графикасында].

«Хәйруллин Мөхәммәтгани 1892 елны рамазанда (*апрель. – М.Ә.*) вафат».

36. «Чинакаева Хафиза Хайрулловна. 1895–1978».

Китерелгән эпитафик текстларның башламы янына мөселманлык билгесе итеп ярымай ясау очраклары да аз түгел.

Яңа Волков зиратындагы татар мазары белән танышкач, шул ачыкланды: зират күптән тулган. Андагы борынгы каберләрнең күпчелеге җимерелеп, алар өстенә яңалары барлыкка килгән. Моңа охшаш эшләр блокада елларында – 1941–1944 елларда ук башланган – ачлыктан, авырулардан, дошман һөҗүменнән һәлак булучыларны җыйнап, гомуми чокырларга күмү очраклары күп булган. Бу – Русиядәге зур шәһәрләрнең халәтенә туры килгән типик күренеш. Мондый хәлләр, ягъни өсте-өстенә күмүне без Казан, Уфа, Чистай, Әлмәт, Касыйм кебек һ.б. шәһәр зиратларында да күрәбез. Әйтергә теләгән төп фикеребез – татар зиратлары өчен яңа мәйданнар бирелмәсә, шәһәр зиратларында тарихыбызның кыйммәтле хәзинәләре юкка чыгарга мөмкиннәр.

Безнең тарафтан 1986 елда язып алынган мәгълүматлар С.-Петербургның сугыштан соң ничек яңаруын күрсәтә баручы чыганаклар булып тора. Әлбәттә, 150ләп ташбилге генә берничә меңләп ташбилгесе булган зиратның тарихи кыйммәтен ачып бетерә алмый. Ләкин әлеге мәгълүматлар татар тарихы белән кызыксынучылар өчен ышынычлы чыганак, әһәмиятле материал булып тора. Шуның белән берраттән, юкка чыкканнарын искә алып, юкка чыгу куркынычы алдында калган истәлекләрнең киләчәк язмышын хәл итү мәсьәләләре дә күтәрелсен иде.

Түбәндә ташбилгеләр хронологик планда, таблицаларда күрсәтелә:

*I таблица*

## С.-Петербург шәһәре Волков зиратындагы ташбилгеләрнең 1843–1986 еллар дәвамында уртача куелышы

| № | Еллар | Ташбилгеләр | № | Еллар | Ташбилгеләр | № | Еллар | Ташбилгеләр |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 1843 | 1 | 21 | 1951 | 2 | 41 | 1973 | 3 |
| 2 | 1892 | 1 | 22 | 1953 | 1 | 42 | 1974 | 2 |
| 3 | 1906 | 1 | 23 | 1954 | 6 | 43 | 1975 | 4 |
| 4 | 1909 | 1 | 24 | 1955 | 1 | 44 | 1976 | 4 |
| 5 | 1913 | 1 | 25 | 1956 | 3 | 45 | 1977 | 5 |
| 6 | 1915 | 1 | 26 | 1958 | 1 | 46 | 1978 | 9 |
| 7 | 1917 | 1 | 27 | 1959 | 4 | 47 | 1979 | 3 |
| 8 | 1919 | 2 | 28 | 1960 | 2 | 48 | 1980 | 6 |
| 9 | 1924 | 1 | 29 | 1961 | 2 | 49 | 1981 | 3 |
| 10 | 1930 | 1 | 30 | 1962 | 2 | 50 | 1982 | 3 |
| 11 | 1932 | 1 | 31 | 1963 | 8 | 51 | 1983 | 5 |
| 12 | 1933 | 1 | 32 | 1964 | 10 | 52 | 1984 | 4 |
| 13 | 1934 | 1 | 33 | 1965 | 5 | 53 | 1985 | 2 |
| 14 | 1935 | 2 | 34 | 1966 | 6 | 54 | 1986 | 1 |
| 15 | 1937 | 1 | 35 | 1967 | 4 | 55 | | |
| 16 | 1938 | 1 | 36 | 1968 | 4 | 56 | | |
| 17 | 1941 | 1 | 37 | 1969 | 2 | 57 | | |
| 18 | 1942 | 5 | 38 | 1970 | 4 | 58 | | |
| 19 | 1945 | 1 | 39 | 1971 | 6 | 59 | | |
| 20 | 1947 | 1 | 40 | 1972 | 3 | 60 | | |

*II таблица*

## Татар ташбилгеләрендә очраган борынгы фамилияләр, шәхеснең вафат булган елы, туган җире

| № | Фамилияләр | Вафат елы | Туган җире |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Абузярова М.Х. | 1978 | x (*билгесезлек билгесе. – М.Ә.*) |
| 2 | Агиев Р.Т. һәм А.К. | 1963<br>1986 | x |
| 3 | Азизбаева А. | 1978 | x |
| 4 | Айгинина | 1954 | x |
| 5 | Акмаев К. | 1964 | x |
| 6 | Аксянов Ж. | 1964 | Горький өлкәсе, Семенеевка авылы |
| 7 | Александрович Ш. | 1919 | Гроднен. губерния, Слоним |
| 8 | Алешев Х.А. | 1980 | x |
| 9 | Алешин ХА. | 1972 | x |
| 10 | Алмакаева Р.А. | 1965 | x |
| 11 | Алмаметов Н. | 1982 | x |
| 12 | Армасов Р.З. | 1967 | x |
| 13 | Бабаев М.Җ. | 1983 | x |
| 14 | Байбеков Х. һәм М. | 1932<br>1942 | x |
| 15 | Байбурова Г.Х. | 1959 | x |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 16 | Байкеев Х. | 1934<br>1956 | x |
| 17 | Байтасов А.С. | 1978 | x |
| 18 | Байрашевская С.М. | 1909 | x |
| 19 | Батыршин Х.В. | 1971 | x |
| 20 | Бахтияров А.С. | 1963 | x |
| 21 | Бекяшова М.К. | 1975 | Морд. АССР, д. Горенко |
| 22 | Биглов И.А. | 1967 | Пензен. обл., д. Никиткино |
| 23 | Бикенеев Л. | 1966 | x |
| 24 | Бикчентаева Б. | 1972 | x |
| 25 | Бильгильдеев Ю.И. | 1956 | x |
| 26 | Бичурин М.З. | 1938 | x |
| 27 | Богданов Т.Х. | 1906 | Тамбов губер., Түбән авыл |
| 28 | Будаев У. | 1942 | x |
| 29 | Будаева Г.Ю. | 1982 | x |
| 30 | Булгаков З.Р. | 1977 | x |
| 31 | Валиев Х.В. | 1935 | Горький өлкәсе, Чембәли авылы |
| 32 | Василова Ф.А. | 1971 | д. Чудовка |
| 33 | Гуляев М.Х. | 1974 | x |
| 34 | Дашкин Ш.Н. | 1951 | д. Дашкино, Морд.АССР |
| 35 | Дашкин А. | 1970 | x |
| 36 | Дашкин З.К. | 1964 | x |
| 37 | Девлет-Кильдеев | 1978<br>1979 | Пенза, д. Мучали |
| 38 | Джангулова Н.Х. | 1967 | x |
| 39 | Деянов М. | 1983 | Горьков. обл. д. Красный Яр |
| 40 | Деянова Д.С. | 1980 | Горьков. обл. д. Кр. Остров |
| 41 | Дианова Г.Д. | 1942 | д. Чембилей |
| 42 | Дивеева Р.Х. | 1977 | x |
| 43 | Дивлетбаев А.Д. | 1981 | Горьков. обл. д. Грибановка |
| 44 | Дулатова Ш. | 1975 | x |
| 45 | Екшикеев Я.Ю. | 1965 | д. Шелдаис |
| 46 | Екшикеев З.Я. | 1985 | д. Шелдаис |
| 47 | Енайдаров Р.А. | 1966 | x |
| 48 | Еникеева З.Ш. | 1959 | x |
| 49 | Еникеева Ф.Ш. | 1960 | x |
| 50 | Жамлиханов А.У. | 1973 | x |
| 51 | Зарипов Ж. | 1966 | Горьков. обл., д. Семенеевка |
| 52 | Измайлова Ф.Х. | 1964 | д. Касымов |
| 53 | Исеева Г.Х. | x | Темниковский р., д. Тювеева |
| 54 | Ишмуратова Ф.Ф. | 1966 | род. в г. Кронштадт |
| 55 | Кадейкин С. | 1964 | x |
| 56 | Казимов М.А. | 1971 | x |
| 57 | Камальдинов З.Г. | 1970 | Горький өлк. Ключищи авылы |
| 58 | Канчурин С.А. | 1979 | x |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 59 | Карамышев И.Х. | 1975 | х |
| 60 | Карамышев И.И. | 1976 | х |
| 61 | Качимасов Ю.Х. | 1975 | Морд. АССР, д. Митрал |
| 62 | Крымский А.Ж. | 1941 | д. Татар. Лаки, Пензенск. обл. |
| 63 | Крымский А.С. | 1967 | х |
| 64 | Кугушев Ш.Ш. | 1973 | х |
| 65 | Кудашева К.Х. | 1978 | х |
| 66 | Куряшев С.Ш. | 1966 | Село Кочетовка |
| 67 | Кутуева Х.А. | 1963 | Чүриле авылы |
| 68 | Кутлутдинова М.В. | 1964 | д. Ключищи, Н.Новгород |
| 69 | Кутыев Ш.С. | 1965 | х |
| 70 | Кучайыф И.Г. | 1954 | Матвей авылы, Мордов. өлк. |
| 71 | Майгилдинов М.А. | 1963 | Пенз. обл., д. Чудовка (Чудилка Иле) |
| 72 | Майгилдинова Җ.Х. | 1970 | Пенз обл., д. Чудовка (Чудилка Иле) |
| 73 | Максутова А.И. | х | х |
| 74 | Мамин А.-З.К. | 1966 | Морд. АССР, с. Кочетовка |
| 75 | Мамин Чингисхан И. | 1954 | х |
| 76 | Мамин Х.М. | 1971 | х |
| 77 | Мамин С.М. | 1947 | х |
| 78 | Мамлеев А.Н. | 1969 | х |
| 79 | Манеев М.Ш. | 1964 | Морд. АССР, д. Черемешева |
| 80 | Маскаев Х.Ш. | 1984 | х |
| 81 | Мерсаитов С. | 1945 | Горьков. обл., д. Кочко Пожарки |
| 82 | Мещерев Х.Х. | 1956 | х |
| 83 | Мещерев И.Х. | 1983 | д. Акчеево |
| 84 | Мещерева Х.К. | 1963 | х |
| 85 | Поляков Канбар С. | 1984 | х |
| 86 | Поляков Нурулла С. | 1959 | х |
| 87 | Поляков С.Х. | 1955 | х |
| 88а | Поляков Хасян М. | 1942 | х |
| 88б | Радаев Ахметҗан | 1960 | х |
| 89 | Садретдинова Р.С. | 1971 | Горьков. обл., д. Ендовище |
| 90 | Сәйфетдинов Садретдин хафиз | 1935 | Горьков. обл., д. Ендовище |
| 91 | Сәгыйдов Н.Җ. | 1915 | х |
| 92 | Сәлимова М. | 1965 | Гурьев өлкәсе, Денгиз р-ны, Байда авылы |
| 93 | Секамов Х. | 1933 | х |
| 94 | Селиванов Юнус Мух. | 1977 | х |
| 95 | Симашова Закия | 1985 | х |
| 96 | Тактаров У.А. | 1982 | х |
| 97 | Телякова Ф.А. | 1964 | д. Горенки |
| 98 | Телякова С.С. | 1977 | х |
| 99 | Теляшев А.И. | 1954 | х |
| 100 | Телешева Х.М. | 1964 | х |
| 101 | Тенишев Ф.Х. | 1965 | х |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 102 | Тенишева Х.А. | 1973 | х |
| 103 | Тенишева Х.К. | 1980 | х |
| 104 | Тенчурин Х.У. | 1958 | х |
| 105 | Тенчурин У.Х. | 1965 | д. Тараканово, Пензенская обл. |
| 106 | Тенчурина Ш.Ф. | 1954 | х |
| 107 | Трегулов Ж.М. | 1961 | х |
| 108 | Трегулова Д.М. | 1980 | х |
| 109 | Тугеев Мирякуб | 1913 | х |
| 110 | Тухтарова З.М. | 1968 | х |
| 111 | Узбаков Ә.С. | 1919 | Ендовище авылы |
| 112 | Ураев У.Ф. | 1951 | х |
| 113 | Уразгильдеев М.Х. | 1975 | х |
| 114 | Уразгильдеева Х.Ә. | х | х |
| 115 | Урдикова Р. | 1930 | х |
| 116 | Урусов Хасян М. | 1969 | х |
| 117 | Урусова Әминә Х. | 1983 | х |
| 118а | Утемишева К.А. | 1968 | д. Танкаевка Пензен.обл. |
| 118б | Хаҗи Ак-Мөхәммәд | 1843 | х |
| 119 | Хәйруллин М. | 1892 | х |
| 120 | Хасанов М. | 1963 | д. Ключище. Н. Новг. |
| 121 | Хасанова Н. | 1972 | д. Ключище. Н. Новг. |
| 122 | Хайров С.А. | 1984 | д. Усть Уза |
| 123 | Чинакаев Ж.С. | 1963 | д. Тат. Лундан |
| 124 | Чинакаева Х.Х. | 1978 | х |
| 125 | Чукашкина С.Х. | 1968 | х |
| 126 | Шакулова С.Х. | 1881 | Касыйм ш. (?) |
| 127 | Шамьянов А.И. | 1978 | х |
| 128 | Шаркузова Ш.Б. | 1974 | х |
| 129 | Шафи-хан, генерал-майор, персидский принц | 1909 | Иран |
| 130 | Юлгушев М.Х. | 1976 | х |
| 131 | Юмаев Рашид | 1917 | х |
| 132 | Юмаев Хамза | 1924 | х |
| 133 | Юняев Мубер Х. | 1981 | х |
| 134 | Юскаев Р.Х. | 1983 | х |
| 135 | Ялымов Хасан А. | 1961 | х |
| 136 | Ялышев З.Ш. | 1937 | х |
| 137 | Ялышева А.Р. | 1971 | х |
| 138 | Ялышева Ф.Х. | 1968 | х |
| 139 | Ямакова Г.Х. | х | Барку Иле, Краснослободск. р-н |
| 140 | Янбиков Э.А. | 1984 | х |
| 141 | Янбулатов Э.И. | 1976 | х |
| 142 | Янбулатов И.И. | 1963 | х |
| 143 | Янбулатов Изатулла | 1942 | х |
| 144 | Янбухтина Н.И. | 1962 | х |

Атап үтелгән 150 ләп ташбилгенең дүрттән береннән генә Санкт-Петербургта яшәгән татарларның Үзәк Русиянең кайсы өлкәләреннән килүчеләр икәнлеген танырга була. Билгеле, зираттагы ташбилгеләрдә асыл ватаннары күрсәтелмәгәннәрнең дә күп булуы бәхәссез.

Волков зиратындагы татар почмагы материаллары татар фамилияләренең тарихи сүзлеген төзү өчен дә кыйммәтле һәм ышанычлы язма чыганаклар булып хезмәт итәләр.

**Әдәбият**

*Аминов Д.А.* Татары в Ст. Петербурге. Исторический очерк. СПб., 1994. 80 с.

*Андреев А.И., Кобак Ф.В.* Исторические кладбища Петербурга: Справочник-путеводитель. СПб., 1993.

*Беккин Р.* Надмогильные памятники польско-литовских татар на Ново-Волковском кладбище в Петербурге // Zycie Tatarskie. 2014. № 39 (116). Р. 18–36.

***Әхмәтҗанов Марсель Ибраһим улы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре*

УДК 398.2

*Л.Х. Мөхәммәтҗанова*

# ТАТАР ТЕЛЛЕ «КАҺАРМАН КАТИЛ» ДАСТАНЫНЫҢ КИЛЕП ЧЫГЫШЫ ҺӘМ ТАРАЛЫШЫНА КАРАТА

В статье автор проводит параллели между историко-культурным процессом и эпическим творчеством татар Поволжья, исследует влияние тюркского эпоса и письменной культуры Древнего Востока на формирование и распространение татарского книжного дастана «Кахарман Катил», выявляет генетические и контактные взаимосвязи.

**Ключевые слова:** дастан, текст, фольклор, литература, источник, сюжет, взаимовлияние, персидский.

Чарланган-камилләшкән вербаль фольклор текстына әверелү өчен әсәр әллә ничә гасырны үтеп формалашырга мөмкин. Тарихлар кичкән мондый әсәр гадәттә үз тукымасына чорга хас үсеш-үзгәрешләрне һәм җирле үзенчәлекләрне дә сеңдерә бара, ягъни үз юлында төрле катламнар тәэсирен кичереп, фольклор әсәре булып оешып җитә. Шуңа күрә, әгәр текстта хронологик фактлар сакланмаган яисә бөтенләй дә юк икән, фольклор әсәренең нәкъ менә кайсы чорда барлыкка килүен тәкъраргарлау – шактый катлаулы һәм бәхәсле мәсьәлә. Бу мәсьәләдә фольклорда күп очракта идеаль төгәллекккә ирешеп булмаска да мөмкин. Ә менә эпик сюжетның кайсы чыганакка барып тоташуын нигездә ачыклап була. Дастанның килеп чыгышын, ягъни тамырларын барлау аша күп кенә принципиаль сорауларга да җавап табарга, хәтта әсәрнең барлыкка килү вакытын чамаларга да мөмкинлек туа.

Бу җәһәттән, ягъни үзенең генезисы белән «Каһарман Катил» дастаны борынгы дәверләрдән мәгълүм фарсы телле чыганак – «Каһарманнамә»гә барып тоташа. Борынгы фарсы истәлеге «Каһарманнамә»нең исә XI–XIII йөзләргә караганлыгы, аның бик борынгы фарсы эпосы йогынтысында барлыкка килгән әсәр булуы мәгълүм [Брагинский, с. 266]. Фарсы әдәбиятындагы мондый әсәрләр язма характерда булып, «төрле җәмәгать урыннарында профессиональ чичәннәр тарафыннан телдән башкарыла» [История всемирной литературы, с. 265] торган булганнар. Иран һәм Урта Азия әдәбиятларына характеристика биргән галимнәр фикеренчә, бу – фарсы телле классик поэзия чорына карый торган, халык традицияләре дә, заманының алдынгы, аристократларча, клерикаль тенденцияләре дә әсәрнең үз эчендә берьюлы үзенчәлекле чагылыш тапкан каршылыклы, катлаулы ядкәр [История всемирной литературы, с. 277]. Аңа халык китабы тибындагы авторсыз әсәр дигән билгеләмә тәңгәл.

Фарсы телле «Каһарманнамә» турында, гомумән, мәгълүматлар бик аз, булганнары аны Иран һәм Урта Азия әдәбиятларына күзәтү ясаганда борынгы Иран эпосы реминисценцияле язма истәлек дип телгә алудан узмый. Төрки-татар «Каһарман Катил»е сюжет-мотивларында, персонаж исемнәрендә һ.б.да фарсы-иран эпик традицияләренең шулай ук бик нык күзгә чалынуына нигезләнеп, бу әсәрнең тамырларын нәкъ менә шушы ядкәрдән эзләргә мәҗбүр булабыз. Фарсы «Каһарманнамә»се – беренчел чыганагының да, үзенең дә авторы гомумән билгесез язма истәлек. Беренчел чыганагына нисбәтән, татар «Каһарман Катил»енең дә авторы мәгълүм түгел.

Төрле чыганаклар тәэсирендә Иран террриториясендә туган әдәби-мифологик сюжет-мотивларның Борынгы чорлардан алып Урта гасырлар буена тирә-юнь халыкларга гаҗәеп зур йогынты ясап килгәнлеге билгеле. Бу йогынты шактый зур ареалны били, үз чорында Иран белән күршеләр мөнәсәбәтендә яшәгән халыклар әдәбиятына һәм фольклорына гомумән карый. Әлбәттә, мондый йогынтының бер генә яклы булмыйча, тарихи үсеш процессында күрше-тирә төрки һәм төрки булмаган кабиләләрнең үзләренең дә Иран әдәбияты-мәдәниятенә үзгәрешләрне шактый керткәнлеге аңлашыла. Шуңа күрә фарсы язма чыганаклары күп очракта үзләре дә чын мәгънәсендә төрле культура ассимиляциясе катламнарыннан гыйбарәт.

«Каһарман Катил»гә мөнәсәбәттә шунысына игътибар итәргә кирәк: татар версиясенең беренчел чыганагы, ягъни фарсы язма истәлеге «Каһарманнамә» дастанының ватаны – Урта Азия, Иран һәм Әзәрбәйҗан регионы ул – соңгырак этапта төрки кабиләләр күпләп үтеп кергән төбәк тә. Бирedә X–XI йөзләрдә иран һәм төрки элементлар катнашкан өр-яңа мәдәният формалашкан, вакыт узу белән соңгыларының роле үсә генә барган [Короглы, 1983]. Әлеге факт иран эпосының да, төрки элементларга нык кына баеп, билгеле бер этапта төрки-иран эпик традицияләре синтезыннан гыйбарәт иҗат булып әверелүе турында сөйли.

Иран язма истәлеге булган «Каһарманнамә»нең барлыкка килүе әлеге синтез инде күптән формалашкан чорга туры килә. Төркиләр күпләп үтеп кергән әлеге төбәктә табылган язма чыганакның бирedә нәкъ менә төркиләр тәэсирендә популярлашкан булу ихтималы да юк түгел. Көнчыгыш фарсы җирләрендә X гасыр башыннан төрки династияләр – Караханилар, Газнәвиләр, Сәлҗүкләр династияләре хакимлек иткән [Восточные персидские земли...]. Әлеге территорияләрдәге алга киткән төрки мәмләкәтләрнең берсе – Караханилар дәүләте (942–1212), мәсәлән, урта гасырларда барлыкка килгән Көнчыгыш Ренессансының мөһим төрки үзәге санала [Ганиева, с. 45–47, 137]. Күчмә һәм утрак уйгыр кабиләләре кушылуыннан барлыкка килгән, зур шәһәрләре белән дан алган бу куәтле дәүләтнең һәм аның әдәбиятының-мәдәниятенең «Каһарман Катил» дастанына

турыдан-туры мөнәсәбәте булырга мөмкин. Караханилар дәүләтендә үз чорында төрки телле мөселман әдәбияты чәчәк аткан. Мәхмүд Кашгари, Йосыф Баласагуни, Фирдәүсиләр калдырган язма мираска игътибар итсәк, идея-рух, сюжет типологиясе җәһәтеннән боларда «Каһарман Катил» белән уртаклыкларны шактый табарга мөмкин. Әсәр кульязмаларының телендә угыз элементларының булуы да әһәмиятле. Барлык төркиләрне генетик бәйләнештә караганда һәм төрле чорда төрле дәүләт берләшмәләренә кергән төркиләрнең төрки телдәге әдәби иҗатын барысын да бер үк өзлексез әдәби процесс итеп күзаллаганда [Стеблева, с. 166], дастанның соңрак кабат төркиләрдә – аларның утрак тормышлы дәвамчыларында, әйтик, үзбәкләрдә, төрекләрдә, казан татарларында таралуы бик тә табигый. Бу яктан фарсы «Каһарманнамә»сен угыз төркиләре иҗаты тәшкил итә дип тә карарга мөмкин. Әмма дастанның казан татарлары китаби версиясендә доминанта ролен төрки эпос традицияләре белән бергә борынгы иран эпосы традицияләре дә үти, моннан чыгып, чыганак әсәр «Каһарманнамә»не синкретик характердагы төрки-иран эпосы дип карау хакыйкатькә якын булыр.

Фарсы телле «Каһарманнамә»нең башка халыклар иҗатына тәэсире әллә ни зур булган һәм масса төсен алган дип әйтеп булмый, алай да ул бөтенләй әһәмиятсез дә калмаган. Бу әсәр башка халыклар эпосына ачыктан-ачык «Каһарман Катил» яисә «Каһарман» исеме белән кереп түгел, ә күбрәк гомуми мотивлары, идея-эчтәлеге, композицион охшашлыклары ягыннан тәэсир иткән булырга тиеш. М. Әхмәтҗанов үзенең фәнни мәкаләсендә [Әхмәтҗанов, б. 198–205] грузиннарның «Карамaниани»ларын (XVIII йөз) һәм үзбәкләрнең 1910 елда басылган, Урта Азиягә хас үзенчәлекләр белән сугарылган «Каһармон» әсәрен [Каһармон, б. 25–33] шушы борынгы язма чыганакка нисбәт итә.

Чыннан да, грузиннарда сюжеты читтән килеп кергән «Бахрам и Гуландам», «Хосров и Ширин», «Сейлан-наме», «Сокровище владык», «Бахтияр-наме», «Книга Синдбада» һ.б. әсәрләр белән бергә «Караманиани» әсәре дә бар һәм бу истәлекләрнең барысын да грузиннарда XVIII йөздә фарсыдан кергән сюжетларга нигезләнгән, үз чорында гаять популярлык казанган ядкәрләр яки тәрҗемә әсәрләре булулары берләштерә. «Караманиани» грузин телендәге, маҗаралы-героик характердагы күләмле текст буларак мәгълүм. Ул – грузиннарның яратып укылган әдәби истәлекләреннән берсе. Катлаулы сюжетка ия булуы һәм зур күләменә нигезләнеп, грузин әдәбияты белгечләре аны еш кына «роман» дип тә атыйлар. Грузин «Караманиани»сы фарсы телле ике әсәрдән оешкан – «Каһарманнамә» һәм «Сәйләннамә»не берләштерә.

Үзбәкләрнең «Каһармон» әсәре – шулай ук катлаулы сюжетлы, мавыктыргыч эчтәлекле, зур күләмле әсәр, «Караманиани» кебек үк, «Каһарман Катил»

сюжеты белән зур уртаклыкка ия. Шушы ук сюжетка язма әсәрнең төрекләрдә булуы турында да мәгълүматлар бар [Әхмәтҗанов, б. 199].

«Каһарман Катил»нең татарларда таралыш алу сәбәпләрен эзләгәндә төп игътибар, әлбәттә, әлеге сюжетка язма истәлекләре булган Көнчыгыш тибындагы культурага ия халыкларга юнәлә. Бу җәһәттән безнең халыктагы «Каһарман Катил» версиясенең иң әүвәл нәкъ менә төрек-татар әдәби-мәдәни бәйләнешләре нәтиҗәсе булуы мөмкин кебек. Чыннан да, төрек язма мәдәниятының татар әдәбиятына тәэсире булган, әлбәттә. Биредә XVIII йөздә фольклор нигезле оригиналь, төрек халык һәм читтән кергән сюжетларга билгеле бер автор хикәяләвендә кулъязма дастаннарның киң таралыш алган булуы мәгълүм. Мондый төр әсәрләрдә борынгы төрек, фарсы, гарәп хикәятләре автор йогынтысында бик нык трансформацияләнеп бирелә торган булган. Моңа мисал рәвешендә Гали Газиз исемле авторның (1798 елда вафат) кысалы кыйссалар рәвешендә төзелгән китабын күрсәтергә мөмкин («Фантазии» дип атала, тулы исеме – «Чудеса божественного откровения») [История всемирной литературы, с. 458]. Ул үз эченә шул чор Стамбул тормышын тасвирлаган һәм «Мең дә бер кичә» циклы мотивлары буенча төзелгән хикәятләрне алган. Төрек әдәбиятындагы бу һәм шундый башка истәлекләр татар китаби дастаны категориясендә карала торган әсәрләргә якын тора. Әмма мондый процесс, ягъни фольклор текстларының автор эшкәртүендә яңа сулыш алуы төрек һәм татар әдәбиятларының һәркайсында үз нечкәлекләре белән параллель рәвештә барган. Татар кулъязма вариантларының төрек телле «Каһарман Катил» тәэсирендә барлыкка килгән булу ихтималын бөтенләй үк инкарь итмәсәк тә, татар версиясенең бер генә чыганагында да төрек «Каһарман Катил»енә нинди дә булса ишарә юк. Моннан тыш төрек-татар әдәби-мәдәни бәйләнешләренең нык активлашкан чоры XIX йөз ахыры – XX йөз башы булуы билгеле, ә «Каһарман Катил» кулъязмалары татарларда XVIII йөзгә, кайбер фикерләр буенча хәтта Алтын Урда чорына ук карый. Шуңа күрә татар «Каһарман Катил» версиясенең турыдан-туры төрек язма әдәбияты аша кергән булу фактын ныклы дәлилләр белән раслап булмый. Татар «Каһарман Катил»енең фарсы «Каһарманнамә»се һәм, гомумән, борынгы фарсы эпосы белән сюжет-мотив уртаклыгы күп очракта сүзне нәкъ менә фарсы-татар бәйләнешләре файдасына алып бару өчен ныклы нигез барлыкка китерә.

Татарларга фарсы тамырлы «Каһарман Катил»нең ни рәвешле һәм ни сәбәпле килеп кергән булуы аерым аңлату таләп итә. М. Әхмәтҗановның хаклы фикеренчә, бу әсәрнең татарлар арасында таралуында төп рольне «Каһарман Катил»нең рухы белән төркиләр томышына һәм төрки героик эпосына якынлыгы уйнаган [Каһарман Катил, б. 3–15]. Дастанда, чыннан да,

борынгы төркиләр җәелеп яшәгән урыннарга мөнәсәбәтле географик атамалар, яшәү рәвешләре, көнкүрешләренә бәйле лексика кулланылган. Борынгы төркиләргә хас булганча, дастан геройларының чатыр корып, күченеп йөрүләрен тасвирлау, төрки эпостагы кебек, сугыш-орыш картинасының ике якның данлыклы батырлары көрәшеннән башлануы, сугыштан тынып торган арада чатыр каравыллаучыларның чатыр янында түгәрәк ясап утырып, думбра чиертүләре, каһарманның атаклы үз сугыш коралы – кылычы булу, агачка атын бәйләп куеп, шул агач төбенә үзе ятып йоклаган батыр янына дошманның килеп чыгуы кебек элементлар дастанны төрки мохиткә якынайта. Әлеге сыйфатлары белән дастан сюжетының төрки-татарларны җәлеп иткән булуы мөмкин, әлбәттә.

Әмма бу сюжет казан татарларыннан тыш төрки халыклардан фәкать төрекләрдә һәм үзбәкләрдә генә чагылыш тапкан. Шуңа күрә «Каһарман Катил»нең төрки рухлы булуы турындагы әлеге фаразны да дастанның таралыш закончалыгы турындагы бердәнбер версия дип раслап булмый. Дастан сюжетындагы күчеп хәрәкәт итүләр, иң беренче чиратта, әллә кайчан утрак тормышны үз иткән казан татарларын түгел, ә күчмә халык булып безнең бабайларга караганда шактый озак гомер кичергән төркиләрне кызыксындырган булырга һәм алар иҗатында чагылыш тапкан булырга тиеш иде кебек. Тагын шунысы да әһәмиятле: үзбәкләр, билгеле булганча, азәрбәйҗаннар, төрекмәннәр, каракалпаклар кебек үк, иранлылар белән этногенетик бәйләнештәге халык. Ә менә казан татарларының этногенезында иран субстратының катнашы юк шикелле. Алай да нәкъ менә татар халык иҗатында фарсы чыгышлы дастанның милли версиясе бар һәм ул үз чорында шактый актив таралган булган.

Моның сәбәпләре тарихи-мәдәни шартлар белән бәйле берничә җитди факторны үз эченә ала.

Әсәрнең татар халкындагы популярлыгының төп хикмәте – төрки-татарлар белән фарсыларның борынгыдан килгән үтә тыгыз әдәби-мәдәни бәйләнешләрендә. Фарсы «Каһарманнамә»се белән татар телле «Каһарман Катил»нең идея-рух якынлыгының үзен дә нәкъ менә шушы факт билгели. Татар халкының, бигрәк тә казан татарларының язма мәдәният белән кызыксынуы үтә зур булып, алар, чыннан да, күп яклап төрки-татар традицияләренә туры килгән мондый мавыктыргыч әсәргә битараф кала алмаганнар. Гарәпләр йогынтысында VII гасырдан ук ислам кабул иткән фарсылар белән Идел буе татарлары язма эпик иҗатын, әлбәттә, дин берлеге дә бик нык якынайткан. «Каһарман Катил»нең мөселман идеологиясе белән сугарылган истәлек булуы аның Идел буе мөселманнары арасында җиңел таралуын тәэмин иткән. Дастанда ислам дине яссылыгында төрки-иран мифологиясе, фольклоры ачык тасвирланган, борынгы тамырлардан килә торган административ-хәрби тәртипләр чагылыш тапкан.

Идел буе татарлары Болгар дәүләтеннән үк, бераз соңрак Алтын Урда составында, аннары Казан ханлыгы чорында, ягъни элек-электән Һиндстан, Урта һәм Кече Азия, Якын Көнчыгыш һәм, әлбәттә, Иран белән сәяси, дипломатик һәм мәдәни бәйләнешләр тотып яшәгәннәр. Иран фольклоры белән төрки-татарлар фольклоры кан-кардәшлек бәйләнешендә тормаса да, борынгы фарсы язма чыганакларының безнең халык иҗатына һәм әдәбиятына тәэсире аеруча зур булганлыгы – исбатланган факт. Әдәбият галимнәре Х. Миңнегуловның [Миннегулов, с. 24–80], Р. Ганиеваның [Ганиева, с. 138] махсус хезмәтләрендә бу мәсьәләләр җентекле яктыртылган. IX гасырдан фарсы теле фарсылар өчен генә түгел, күп кенә башка халыклар өчен дә язма тел, ягъни әдәби тел функциясен үтәп килгән. Иран территориясендә күп кенә халыкларның бер дәүләт кысаларына сәяси, икътисадый, мәдәни берләшү факты фарсы теленең иран халыкларының гына түгел, анда яшәгән төрки халыкларның да әдәби теленә әверелүенә китергән. Бу үзенчәлекнең, кайбер башка төркиләрдәге кебек, Идел буе регионында формалашкан татар мәдәниятенә һәм әдәбиятына да традицион төстә бердәй хас булуын беләбез. Безнең халык фарсы язма истәлекләрен татар теленә күчереп кенә түгел, ә оригинал телдә укыган, чөнки бу чорда фарсы теле татарлар өчен чын мәгънәсендә әдәби-гыйльми аралашу теле булган. Бездә төрле өлкәгә караган фарсы телле язма мирасның күплеге нәкъ менә шуның белән аңлатыла да. Фарсы теленең Идел буе регионында формалашкан татар мәдәниятенә, бигрәк тә әдәбиятына йогынтысы, Идел буе Болгары чорыннан алып, күп гасырлар буена барган. Төбәк Алтын Урда составына кергәч, бу бәйләнешләр шулай ук ныгыган гына, чөнки төрки-татар теле дәүләт теле булып саналган Алтын Урда укымышлылары арасында гарәп һәм фарсы телләрен белү дәрәҗә саналган [Миңнегулов, б. 32]. Рус дәүләтенең XVI йөз урталарыннан алып барылган тышкы сәясәте нәтиҗәсендә XVIII–XIX гасырларга исә татарларның Урта Азия белән бәйләнешләре янә ныгып, татарлар өчен Урта Азия аша Иран әдәбиятына юл яңа этапта ачылган.

Фарсы язма истәлекләре аша үтеп кергән дастани сюжетлар, мотивлар халык иҗатына да күпкырлы тәэсир ясаган. Чыганагы язма булу бу дастаннарның татарларда турыдан-туры язмача эпик иҗат булып таралуын да тәэмин итми калмаган. Мондый сюжетларның күбесенә казан татарлары җирле телдә өр-яңа яңгырашлы үз версияләрен барлыкка китергәннәр. Гаҗәеп мавыктыргыч сюжетлы «Каһарман Катил» дастанының Идел буе татарларында популярлашкан булуы да – нәкъ менә шушы тарихи-мәдәни багланышларның һәм татарларда «Каһарман Катил» тибындагы эпик истәлекләргә үз чорында булган көчле ихтыяҗның логик нәтиҗәсе.

Борынгы фарсы чыганаклы сюжетның Идел буе татарла-

рында шактый актив очравының (бүгенге көндә дастанның төрле вариантын тәшкил итә торган 6 нөсхәсе билгеле [Мухаметзянова, 2013], алар фәнни әйләнешкә кертелгән) сәбәпләренә күзәтү ясау түбәндәге нәтиҗәгә китерә: безнең халыкта язма эпик мирас белән кызыксынуның зурлыгы, мондый төр иҗатның халыкның билгеле бер катламы өчен үз чорында чын мәгънәсендә рухи азык булуы халыкның традицион дини карашларына туры килә торган һәм төрки-татар эпосы белән бик күп типологик охшашлыклардан гыйбарәт «Каһарман Катил»нең Идел буе татарларында китаби дастан булып таралуын тәэмин иткән. Фарсы кулъязма китабы белән татар әдәбияты арасындагы чал гасырлардан ук килә торган бәйләнешнең ныклыгы һәм татарларда дастан вариантларының күплеге бу фикерне шактый ныгыта.

**Әдәбият**

*Әхмәтҗанов М.* Татар кулъязма китабы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 270 б.

*Брагинский И.С.* Литература Ирана и Средней Азии. // История всемирной литературы. В девяти томах. Т. 2. М.: Наука, 1984. 672 с.

Восточные персидские земли и Центральная Азия до прихода турок и сельджуков//URL:http://runivers.ru/doc/isl/index.php?SECTION_ID=278&IBLOCK_ID= 50 (дата обращения – 3.03.2012 г.)

*Ганиева Р.К.* Восточный Ренессанс и поэт Кул Гали. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. 173 с.

История всемирной литературы. В девяти томах. Т. 2. М.: Наука, 1984. 672 с.

Каһарман Катил (дастан). Казан: Татар. китап нәшр., 1998. 221 б.

Каһармон. Зумрад вә Киммәт. Узбек халк ижоди. Күп томлык. Т. 3. Тошкент, 1988. 277 б.

*Короглы Х.Г.* Взаимосвязи эпоса народов Средней Азии, Ирана и Азербайджана. М: Наука, 1983. 336 с.

*Миннегулов Х.Ю.* Татарская литература и восточная классика (Вопросы взаимосвязи и поэтики). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1993. 384 с.

*Миңнегулов Х.Й.* Дөньяда сүземез бар... Казан: Татар. китап. нәшр., 1999. 336 б.

*Мухаметзянова Л.Х.* Некоторые вопросы изучения «Кахарман Катил», эпического достояния казанских татар // Вестник Челябинского государственного университета. 2013. № 4 (295). С. 79–81.

*Стеблева И.В.* Поэтика древнетюркской литературы и ее трансформация в раннеклассический период. М: Наука, 1976. 215 с.

***Мөхәммәтҗанова Лилия Хатип кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*
*e-mail: lilmuhat@mail.ru*

УДК 94(47)

*Р.И. Беккин*

# 1917–1991 ЕЛЛАРДА ПЕТРОГРАД-ЛЕНИНГРАД МӨСЕЛМАН ТАТАРЛАРЫ ТОРМЫШЫ
## (шәхси фотоархивлар турында уйланулар)

В статье рассматривается история татаро-мусульманской общины советского Петрограда-Ленинграда. В качестве отправной точки для анализа послужили материалы частных архивов. Особое внимание автора уделено судьбам ленинградских имамов, ставших жертвами политических репрессий: Я.К. Халикова и Х.В. Махмутова.

**Ключевые слова**: Петроград, Ленинград, *имам-хатиб*, *исем кушу*, *никах*, неофицальные муллы, Татарское кладбище, Г.Н. Исаев, Х.В. Махмутов.

Советлар Союзында ислам темасы соңгы елларда фәнни-тикшеренү эшләрендә шактый киң яктыртыла. Тикшерү объекты булып ислам һәм мөселманнарга карата дәүләт сәясәте генә түгел [Ro'i; Ислам и советское государство, вып. 1–3; Салахбекова һ.б.], ә рәсми һәм рәсми булмаган ислам институтларының илнең төрле төбәкләрендә яшәеш үзенчәлеген күзәтү тора [Сенюткин, Идрисов, Сенюткина и др.; Гусева; Сафаров һ.б.]. СССРда ислам тарихы һәм яшәешен өйрәнү шуның белән дә кызыклы – бу чор әле бездән бик ерак түгел. Бүгенге көндә илебезнең төрле төбәкләрендә дини оешмалар, мәхәлләләр белән җитәкчелек итә торган мөселман дин әһелләре нәкъ менә совет чорында формалашып, белем алган кешеләр. Шулай да вакыт якынлыгы ялган өмет тәбирә, ник дигәндә, чорның төп шаһитлары, Советлар Союзының төрле төбәкләрендә, шул исәптән Ленинград шәһәрендә, 1920–1970 елларда дини тормышта кайнаган шәхесләр инде вафат.

Мөселманнар арасында барлыкка килеп, бүгенге көнгә килеп җиткән һәм Ленинград дини тормышын күзалларга ярдәм иткән чыганаклар алай күп түгел. Иң әүвәл хатларны атап китик. Икенче группа – көндәлекләр. Ленинград мөселманнары арасында көндәлек язу алай киң таралмаган, шуңа да безнең көннәргә килеп җиткәннәрен бармак белән генә санарлык. Зур группаны дини тормышны контрольдә тоткан дәүләт органнары документлары тәшкил итә, бүген бу чыганаклар СССРда ислам тарихын өйрәнә торган галимнәр, шул исәптән чит ил вәкилләре өчен, төп чыганак ролен үти. Алай да искәртеп үтик: бер генә группа чыганаклардан файдалану берьяклы караш булдыра һәм

ялган нәтиҗәләргә дә китерергә мөмкин[1].

Әйтелгәннәрне исәпкә алсак, Советлар Союзында мөселманнарның көндәлек тормышын күрсәткән фотоматериаллар (беренче чиратта, шәхси архивлар күз уңында тотыла) – иң мөһим чыганакларның берсе. Мөһим, ләкин бердәнбер чыганак түгел, чөнки теләсә нинди фотосурәт, белгеч тарафыннан интерпретацияләнмәсә, тарихтан калган бер үле артефакт, «язмыш кисәге» генә. Күпчелек очракта фотографияләрнең хуҗалары – Петроград-Лениград мөселманнарының балалары, оныклары – сурәтләргә аңлатма бирә алмадылар: әллә белмәгәнгә; әллә, белеп тә, ниндидер сәбәпләр аркасында әйтергә теләмәгәнгә. Репрессия корбаннары булган дин әһелләре варислары арасында икенче очрак еш күзәтелә, хәтта безнең кызыксынуыбыз да аларда курку тудырды.

Фотосурәтләрдә сакланып калган кешеләрнең исемнәре дә һәрвакыт билгеле түгел. Шулай да бер нәрсә төгәл ачык – аларның күпчелеге татарлар, Петербург-Петроград-Ленинград шәһәрендә яшәгән төрле татар субэтник төркемнәре вәкилләре. Петербургның мөселман общинасы формалашу тарихына күз салсак, бу факт гаҗәпләнү тудырмый.

Петербург мөселманнарының төп өлешен татарлар тәшкил итә. Петропавловск крепостен төзү эшләрендә үк И.Е. Бахметев җитәкчелегендә эшли торган татар һәм башкортлар була. Тиздән Нева буйларына Россия губерналары, шул исәптән Казан губернасыннан да, крестьяннар китерелә башлый. Петр I указы буенча төзелеш эшләренә крестьяннар гына түгел (4 йорттан 1 кеше хисабыннан), ә йомышлы морзалар да җәлеп ителә. XVIII гасыр уртасына инде Кронштадт һәм Любань авылында (Петербург – Мәскәү трактында) татар-мөселман общиналары оеша.

XVIII гасырда Петербург татарларының күпчелеге хәрби хезмәттә була, сәүдәгәрләр аз санлы гына бер төркем тәшкил итә. Имам функцияләрен ислам йолаларын әйбәт белгән гади кешеләр башкара. XVIII гасыр ахырында галим һәм сәяхәтче И.Г. Георги башкала мөселманнары хакында болай ди: «Магометане, Татары из разных областей чужестранные купцы, поверенные и т.д. не имеют ни мечети, ни какого-либо прихода; но между купцами находятся у них духовные (Муласы), которые в жилищах своих с единоверцами своими по пятницам и по праздникам производят торжественную свою службу на Арабском и Татарском языках» [Георги, с. 282].

1822 елда Петербургта беренче хәрби булмаган мәхәллә оеша, шулай да XIX гасыр ахырына

---

[1] Мисал итеп Яков Роиның югарыда телгә алынган «Ислам в Советском Союзе» (Ro'i Y. Islam in the Soviet Union: From the Second World War to Gorbachev. New York, 2000) китабын күрсәтергә була. Автор СССРда ислам институтларының яшәешен дәүләт органнары документларына гына таянып чагылдыра. Хезмәтнең җитешсезлекләре турында тулырак мәгълүмат: [DeWeese].

кадәр хәрби мөселманнарның саны күбрәк була әле. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Петербург мөселманнарының күпчелеге сәүдәгәр яки хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшли [мәсәлән: Григорьев, с. 251; Ключева, с. 206; Оболенский, с. 13, һ.б.].

1910 елда Петербургта 7,3 мең татар яши (шәһәр халкының 0,4%) [Санкт-Петербург: энцикл. слов.]. Мөселман динендә булган башка милләт вәкилләренең саны берничә дистәдән артмый. Татарлар арасында 3 субэтник группа: касыйм татарлары, казан татарлары һәм мишәрләр – күпчелек була. Аз санлы булса да, Польша-Литва татарлары группасы да бар. Петроград губернасын алсак, биредә башкаладан көньяктарак урнашкан берничә торак пунктта касыйм татарлары күпчелекне алып тора. Мишәрләр Карел бугазын һәм Финляндиянең Выборг губернасы территориясен үз итә.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Петербург мөселманнары арасында татарлардан гыйбарәт (Казан, Түбән Новгород, Касыйм, Польша-Литва, Кырым якларыннан булган) зыялылар төркеме пәйда була. Зыялылар барлыкка килү – 1905–1907 еллардагы беренче рус революциясеннән соң илдә барган либеральләшү нәтиҗәсе. Февраль һәм Октябрь революцияләрен инде Петербург мөселман общинасы тулы көчкә ия булып каршылый, гәрчә 1907–1910 еллардагы реакция вакытында башкаладагы мөселман басмалары һәм бер төркем либераль зыялыларны берләштергән мәхәллә ябылса да. Мөселманнар революцияләрне өмет белән каршы ала, ләкин бу өметләр бик тиз җилгә оча [тулырак мәгълүмат: Исхаков]. Бер фотографиядә (авторы – Яков Штейнберг) Бөтенроссия мөселман советы башкарма комитеты хезмәткәрләре сурәтләнгән[1]. Әйтелгән Совет 1917 елның май аенда Мәскәүдә оеша, ә башкарма комитеты Петербургта эшли. 1918 елның маенда инде Совет та, аның башкарма комитеты да таркала.

1919 елның сентябрендә Петроградны Юденич гаскәрләреннән саклау максатында шәһәргә Кызыл армиянең башкорт кавалерия полкы китерелә. Полкны китерү инициаторы Л.Д. Троцкий болай ди: «Башкирская кавалерийская дивизия была лишь недавно сформирована. Я с самого начала имел в виду перевести ее на несколько месяцев в Петроград, чтобы дать возможность степнякам прожить некоторое время в культурной обстановке города, сблизиться с рабочими, посетить клубы, митинги и театры. Теперь к этому присоединилось новое, более неотложное соображение: напугать финляндскую буржуазию призраком башкирского нашествия» [Троцкий, с. 406].

Язучы Исаак Бабель дә узган тормышка кабер казучы ролендә

[1] Кинофотофонодокументлар үзәк дәүләт архивы сайтында фотография 1923–1924 елларга карый диелгән. Ләкин фотосурәт 1918 елның май аеннан да соңрак эшләнгән була алмый.

төрки халыкны, бу очракта татарларны күрә. 1918 елда язылган очеркта мондый юллар бар: «Десятки татар заняты убоем лошадей. Это чисто татарское дело. Наши бойцы, сидящие без работы, до сих пор не решились приступить к нему. Не могут, душа не пускает… Настало обеденное время. Трактир был наполнен татарами – бойцами и торговцами. От них пахло кровью, силой, довольством… За столиками рослые татары трещали на своем языке и требовали себе к чаю варенья на 2 рубля. Возле меня примостился мужичонка. Мигая глазами, он сообщил, что в нынешнее время каждый татарин тысяч по пяти, а может, и по десяти в месяц зашибает, «всех лошадей скупили, дочиста всех»... Потом я узнал, что и русские за ум взялись. Тоже промышляют. «Что поделаешь? Раньше конину татары ели, а нынче весь народ и даже господа…» Солнце светит. У меня странная мысль: всем худо, все мы оскудели. Только татарам хорошо…» [Бабель, с. 45–47]. Арттыра, билгеле. Шыксыз, ач Петроградта кемгә генә рәхәт булды икән? Хакимият вәкилләренә булса гына инде.

Революциядән соң Петроград мөселманнарының составы шактый үзгәрә: шәһәр мөселманнарының бер өлеше эмиграциягә китә (күпчелеге Финляндиягә), беркадәресе Гражданнар сугышы елларында һәлак була. 1920 еллар башында Петроград мөселманнарының саны 4 тапкыр арта – Идел буендагы ачлыктан качып шәһәргә 28 мең крестьян килә [Тагирджанова. Татарские детские дома..., с. 53]. Петроградта калган революциягә кадәрге мөселман общинасы вәкилләре иҗтимагый вазифаларны башкаруны дәвам итәләр: мәсәлән, сәүдәгәр һәм меценат Мөхәммәтгалим Максутов. Яңа шартларда аларның бик азы гына мөселман общинасына элекке дәрәҗәдә йогынты ясый ала.

1917–1923 елларда Петроград Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы булып Муса Бигиев (1879–1949) хезмәт итә. 1920 еллар башында иҗтимагый-сәяси эшләре тыгыз булган Бигиев Петроград мөселманнарының рухи башлыгы вазифаларын башкара алмый, шуңа да имам-хатыйп итеп Якуб Камал улы Халиковны (1887–1951 елдан соң) чакыра. Халиков белән бергә имам булып Камалетдин Басыйр улы Басыйров (1876–1931 елдан соң) эшли. 1920–1928 елларда Басыйров Большая Московская урамы 1/3 нче йортта урнашкан мәхәллә белән җитәкчелек итә, гәрчә 1913 елда шәһәрдә Җәмигъ мәчет ачылса да. Бу мәхәллә 1928 елга кадәр эшли. Мәхәллә каршында хуҗалык эшләрен алып барган совет – «двадцатка» – оештырыла.

XX гасыр башында Петербург һәм Выборг губерналарының берничә шәһәрендә (Петербург үзе, Кронштадт, Выборг, Луга һ.б.) мәчет һәм намаз урыннары эшләп килә. Гадәттә алар берәр хәллерәк мөселман, общинаның рәсми булмаган җитәкчесе өендә бер я берничә бүлмә алып торалар. Мәсәлән, Луга шәһәрендә намаз уку урыны булып, 1919 елга кадәр Вәли Хәбибулла улы

Сапаров (1889 ел тирәсе – 1919) йорты була. 1919 елда йортка анархистлар һөҗүм ясый, Вәли Сапаров үзе шунда һәлак була[1].

Кронштадтның Петербургская урамындагы мәчет 1927 елга кадәр эшли. 1926 елда мәчетнең имамы Мөхәммәт-Фатих Зәгъфәровны (1884–?) һәм мәхәллә советыннан тагын өч кешене шәһәрдән сөрәләр. 1927 елның 27 ноябрендә мәчетне 1870 елдан бирле урнашкан бинасыннан да чыгаралар, ә мәчет милкен саткан акча казнага күчерелә. XX гасыр уртасында мәчет булган ике катлы бина да җимерелә.

1920 елларга караган фотоматериалларның күпчелек өлеше имам М. Бигиев һәм Я. Халиков варисларыннан һәм татар журналисты Кәрим Мөхәммәтша улы Сәгыйтовтан (1888–1939) алынган. Бу чорга караган берничә фотография Җәмигъ мәчете каршында төшкән коллектив фотосурәт булып тора. Мәчет янында фотога төшү традициясе мәчет нигезенә беренче таш салганда ук (1910) башлана. 1913 елда мәчет рәсми рәвештә ачылгач, Петроградка килгән мөселманнарның мәчет янында төшкән сурәтләре арта.

1930 елларга караган фотосурәтләр юк диярлек. Массакүләм репрессияләр вакытында Ленин шәһәрендә дини йолаларны фотога алган кыю кешеләр сирәк була. Аннан да бигрәк, алдагы чорда ясалган, икенче ягында татарча язу (гарәп хәрефләре белән) булган фотосурәтләр хуҗалары тарафыннан ук юк ителә. Мәсәлән, 1931 елның 16 февраль төнендә кулга алынган имам-хатыйп Якуб Халиковның бер фотосурәте дә сакланмаган. Бу төндә Ленинград мөселман общинасы чын-чынлап тар-мар ителә. Халиковтан башка тагын 26 кеше кулга алына, шулар арасында Муса Бигиевнең хатыны һәм балалары, К.Б. Басыйров, Җәмигъ мәчете советы вәкилләре була. Кулга алынуның сәбәбе – 1930 елда Муса Бигиевнең илдән чыгып китүе.

Кулга алынганнар арасында төп шәхесләр – Я. Халиков һәм К. Басыйров. Документларда әйтелгәнчә, «эти муллы, группируя вокруг себя единомышленников националистической к-р. идеологии из активных прихожан мечети (членов 20-тки и торгашеский элемент, имеющий связи с татарской эмиграцией в Финляндии), маскируясь отправлением религиозных обрядов, занимались антисоветской агитацией» [Обвинительное заключение по след. делу № 111999..., л. 368–369]. Материалларда 1930 еллар башында Ленинград мөселман общинасының якынча санын да билгеләү бар: «В результате к-р. группировка при мечети завоевала себе такой авторитет, что на молебствование по праздникам в мечеть стекалось по 5–6 тысяч человек татарской колонии, что составляет 20–25 % общего числа последней» [шунда ук, л. 369]. Күргәнебезчә, Финляндия татарлары белән элемтәдә булу гаеп эш дип классификацияләнә. 1930 еллар башына кадәр совет–фин чиге шактый иркен булу сәбәпле,

[1] Хәзерге көндә бу бинада (Урицкий ур., 54) балалар иҗаты үзәге урнашкан.

Лениград татарлары Финляндиядә яши торган татар гаиләләре белән тыгыз элемтәдә торалар, туганлык та була[1]. Революциягә кадәр үк Финляндиядә төпләнеп калган татар сәүдәгәрләре Ленинградтагы якташ-мишәрләренә булышып киләләр. Мәсәлән, М. Бигиевнең төп иганәчесе 1920 елдан Тампере шәһәрендә торган Зиннәтулла Әхсән Бере була. Кайнатасы исә – Камалетдин Бәдретдинов – Детское Селода (Пушкин шәһәре) яши, 1931 елның 16 февраль төнендә кулга алына.

«Бигиев эше» буенча кулга алынган 27 кешенең 23е ОГПУ Коллегиясенең 1931 ел 23 июль карары нигезендә төрле вакытка төрмәгә утыртыла. Бигиевнең хатыны Әсма ханым балалары белән өч елга Ленинградтан сөрелә [Обвинительное заключение по след. делу № 111999..., л. 392–393].

Мөселман общинасының җитәкчелеген юк итү шәһәрдә дини активлыкны туктатуга юл ача, шулай булса да мәчет 1940 елга кадәр эшли әле.

Блокада чоры фотосурәтләре шулай ук юк дәрәҗәсендә. Кайбер мөселманнар эвакуациягә китә, кайсы гүр иясе була. Бу елларда революциягә кадәрге мөселман зыялыларының соңгы вәкилләре дә вафат була. Иң соңгысы – блокаданың беренче кышында вафат булган Исмаил Номан улы Леманов (1871–1942), 1913–1915 елларда Петербургта IV чакырылыш Дәүләт Думасының мөселман депутатлары тарафыннан чыгарылган «Милләт» газетасы мөхәррире.

Бөек Ватан сугышыннан соңгы елларда Ленинградка яңа кешеләр килә, мөселман общинасы составы да инде икенче тапкыр тулысынча диярлек яңара (нәкъ Октябрь революциясе елларындагы кебек). Эвакуация яки фронттан кайтканнарга да еш кына яшәү урынын үзгәртергә туры килә: элек биләгән фатирларында башка гаиләләр торырга мөмкин[2].

Сугыш вакытында дингә беркадәр ирек бирелсә дә, бу исламга кагылмый. Ленинградта Җәмигъ мәчет ачуны сорап язган хатларга җавап булмый. Мөселманнар җомга я гает намазына, качып диярлек, Яңа Волков зиратының татар өлешендә җыелалар.

Яңа Волков зиратының татар ягы 1826 елда хәрби ахун Д. Хантимеров соравы буенча ачыла: мөселман зираты өчен шәһәрдән өч чакрым ераклыкта Волковка елгасы буенда 2 дисәтинә җир бүлеп бирелә. Әле Екатерина II заманында ук биредә Волковка тирәсендә яшәгән төрек әсирләрен җирли торган булалар. Октябрь революциясеннән соң, бу зиратка татар булмаган мөселман

---

[1] 1930 еллар уртасында татарларның туганнарын Финляндиягә чыгару очраклары билгеле. Мәсәлән, 1935 елда Териоки мөселманнарының элекке җитәкчесе Зиннәтулла Әхсән Бере СССРдан совет – фин чиге аша үзенең әнисе Мәрхаб Ибраһимованы (1855–1941) чыгара.

[2] Мәсәлән, үземнең дәү әнием белән дә шундый хәл була: ул сугышка кадәр һәм блокаданың беренче елында Пять углов районындагы (XX гасыр башында мишәрләр күпләп яши торган урын) Марат урамында урнашкан бүлмәдә тора. Эвакуациядән кайткач, күчәргә туры килә, бүлмәдә инде башка гаилә яши.

вәкилләре дә, мөселман икәнлеге шикле булганнар да җирләнә. Шулай да йола үтәлеп килә: мәетне кәфенгә төреп һәм табутсыз җирлиләр.

1940 елда, Җәмигъ мәчете ябылгач, мөселманнар арасында зиратның роле тагын да көчәя. Җомга намазына берничә йөз кеше җыела. Гает намазлары вакытында исә халык саны 7–8 меңгә якынлаша [Тагирджанова. В костеле..., с. 53–60]. Бөтен Ленинград һәм якын-тирә шәһәрләрдән мөселманнар татар зиратына җыелып намаз укыйлар.

1950 елларга караган фотосурәтләр арасында СССР Фәннәр академиясенең Дин тарихы һәм атеизм музее хезмәткәре Д.И. Исхаков фотолары бар. Фотолар гает я җомга намазы вакытында төшерелгәннәр, 1954 елга караган җеназа намазы фотосы да бар. Фотоларда күпчелекне картлар тәшкил итә.

1917 елга мөселман зиратлары (яки өлешләре) Лобань (XVIII гасыр уртасыннан), Царское Село (1820 еллардан башлап), Кронштадт (XIX гасыр уртасыннан), Гатчина (1851 елдан), Луга (XX гасыр башыннан), Петергоф (XX гасыр башыннан), Тосно (1905 елдан), Яңа Ладога (1906 елдан), Выборг (1911 елдан), Териоки (1916 елдан) торак пунктларында була [Беккин, с. 81–85]. XX гасыр урталарына бу зиратларның күпчелеге бетә. Мәсәлән, Луга мөселман зираты территориясендә сугыш вакытында немец гаскәрләре тора, көрәш бара [Б.Б. Таканаев белән әңгәмә].

Кайбер мөселман зиратлары сугышка кадәр үк юкка чыга. Мәсәлән, Петербургтагы татар зираты белән бер вакытта барлыкка килгән Царское Село мөселман зираты мөселманнарның үз гаебе аркасында юкка чыга. Дворцовое управление хезмәткәрләре күрсәткәнчә, зиратның мөселман өлеше 1909 елда ук шактый начар хәлдә була: «…существующее магометанское кладбище находится в большом беспорядке и требует приведения его в надлежащий вид, чтобы можно было тогда судить о том сколько на нем имеется свободных мест для погребения. Только по приведении кладбища в порядок уполномоченные магометан смогут ходатайствовать о прирезке нового участка земли» [Ответ на прошение..., л. 7].

Сугыштан соңгы унъеллык – Ленинград мөселманнарының мәчетне кайтару максатында берләшкән чоры. Шулай да Җәмигъ мәчет 1956 елда гына ачыла. Халык арасында легенда йөри: имеш, 1955 елда Ленинградка килгән Һиндстан премьер-министры Джавахарлал Неру мәчеткә кермәкче булган икән дә, ул ябык булып чыккан. Шуннан мәчетне ачырга туры килгән [Как Смольный..., с. 9]. Бу кызыклы бер хикәят кенә булса да, анда дөреслек тә бар: Ленинградта мәчет ачылу Шәрык илләреннән килгән дәүләт кунаклары белән турыдан-туры бәйле, мөселман илләре делегацияләренең экскурсия программасында «Ленинград шәһәре Җәмигъ мәчете» пункты һәрвакыт булган.

1950–1970 елларга караган фотолар арасында төп өлешне рәсми сурәтләр тәшкил итә.

Югары кунаклар белән бергә мәчетнең имам-хатыйплары Габделбарый Низаметдин улы Исаев (1907–1982), Хафиз Вәли улы Мәхмүтов (1937–2006) та бар.

Мөселман дин әһелләренең хакимият органнарына кулай ракурста төшерелгән рәсми фотосурәтләре сугыштан соңгы Ленинград мөселманнары тормышы турында сөйли алмый.

Безне күбрәк ислам йолалары күренешләрен саклаган фотосурәтләр кызыксындырды. Алар арасында исем кушу, никах, җирләү традицияләрен күрсәтергә була. Күпчелек фотолар җеназа күренешләрен саклаган: ник дигәндә, исем кушу һәм никах яшьләргә кагыла торган йолалар, ә яшьләр инде ислам традицияләреннән шактый ераклашкан. Г.В. Старовойтова китергән мәгълүматларга караганда, сугыштан соңгы чорда мәет озату традициясе мөселман йолаларының иң киң таралганнарыннан була, хәтта шәһәр шартларында да аны 67–73% татар үти [Старовойтова, с. 117–118].

Мәет озату күренешләрен саклаган фотосурәтләр арасында берничә сюжетны аерып күрсәтергә мөмкин: 1) җеназа намазы (Ленинградта мәчет ишегалдында яки зиратта); 2) мәет янында төшкән фотолар; 3) кабер янында алынган фотосурәтләр. Беренче группа фотосурәтләре рәсми төшерелгән, гадәттә профессиональ фотограф эше. Ә икенче һәм өченче группа фотосурәтләре мөселман мәет җирләү циклынннан уникаль документаль истәлекләр.

Совет чорында Ленинград өлкәсенең берничә шәһәрендә рәсми булмаган (мәчеттән тыш яки указсыз) муллалар эшли. Шулар арасында Гатчинадан Мотыйгулла Гайнулла улы Хәмитов (1897–1972) та бар [Аминов]. «Указсыз» мулла гадәттә Идел буе, Уралда дини башлангыч я урта белем алган кеше була. Указсыз муллалар эшчәнлеге Җәмигъ мәчете ябык вакытта шактый киң җәелә. 1956 елдан соң да алар эшләвен дәвам итә, кайсылары Җәмигъ мәчете имам-хатыйбына булыша. Ләкин аларга хәзер хакимият органнары белән генә түгел, рәсми руханилар белән дә әйбәт мөгалләмәдә булу кирәк була.

Указсыз муллалар исем кушу, никах, җирләү йолаларына актив җәлеп ителәләр. Шуңа өстәп мәҗлесләр үткәрү, сәдака җыю эшләрен дә башкаралар. Хакимият вәкилләре, әлбәттә, теге яки бу мулла эшчәнлеге турында белеп торалар, кирәк вакытта алар аша мөселман общинасының төп массасы белән сөйләшәләр.

М. Хәмитов – 1960–1970 елларда Ленинград мөселманнарының рәсми булмаган лидеры. Луга шәһәренең указсыз мулласы – Гани Фәзлулла улы Татуков (1892–1969). 1970 ел ахырыннан

[1] «...Совет (Дин эшләре буенча совет. – *Р.Б.*) и КГБ в конце 1975 г. проводят в Уфе пленум ДУМЕС, где протаскивают на должность муфтия «своего человека» Исаева Бария. Я выразил протест против нарушения ст. 52 Конституции СССР (Вөҗдан иреге һәм чиркәүне дәүләттән аеру турында. – *Р.Б.*) и вмешательства в церковные дела и впал в их немилость» [Х.В. Мәхмүтов автобиографиясе, б. 5].

2006 елга кадәр указсыз мулла булып Җәмигъ мәчетенең элекке имам-хатыйбы Хафиз Мәхмүтов «эшли». 1972 елда 37 яшендә имам-хатыйп булган Х. Мәхмүтов Россия мөселман диния нәзарәте рәисе Исаев тарафыннан 1977 елда урыныннан төшерелә[1].

Мәхмүтов – Исаев арасында килеп чыккан конфликт беренче карашка гына гади кебек. Чынлыкта бу ике буын, ике система бәрелеше. Исаев белән Мәхмүтов икесе ике чор вәкиле; алган белемнәре, шәригатькә карашлары белән да алар бер-берсеннән нык аерыла. Хафиз Мәхмүтов Исаев турында көндәлегенә дә теркәп куя: «Он тщеславен, консервативно настроен, себя ставит выше всех, ненавидит тех, кто знает больше него, с мнениями других не считается» [Х.В. Мәхмүтов көндәлеге, б. 5].

Рәсми эш урыныннан киткәч тә Мәхмүтов мөселманнар арасында авторитет булып кала бирә. Яңа имам-хатыйп Җафар Насыйбулла улы Пончаев (1940–2012) белеме белән дә, казанган хөрмәте ягыннан да Хафиз хәзрәттән шактый калыша, ә менә хакимият органнары өчен ул бик тә кулай була.

Мәхмүтов фатирында даими рәвештә мәҗлесләр булып тора, халык дин сабагы алырга йөри. Хатыны да, чын абыстай буларак, хатын-кызлар өчен дәресләр үткәрә [Х.В. Мәхмүтов автобиографиясе, б. 5].

Җ. Пончаев конкурент белән килешә алмый, әлбәттә. Мәхмүтов өстеннән язылган жалоба хатларының исәбе юк. Ул Үзгәртеп кору елларында да, хәтта Советлар Союзы таркалгач та язуын дәвам итә [М.Х. Мәхмүтова белән әңгәмә].

1983 елда Х. Мәхмүтов ЦК КПСС Генераль секретаре Ю.В. Андроповка илдә дингә булган карашны үзгәртүне сорап мөрәҗәгать итә. «Җавап» бик тиз килеп җитә: 1983 елның 25 апрелендә Мәхмүтов хатыны белән В.П. Сербский исемендәге Суд Психиатриясе институтына җибәрелә, аннан аларны Ленинград шәһәренең И.И. Скворцов-Степанов исемендәге 3 нче психиатрия хастаханәсенә мәҗбүри «дәвалау» өчен китерәләр. Имам-хатыйпны хастаханәдә 3 ай, абыстайны 6 ай тоталар [Заявление Президенту, конгрессу и госдепартаменту США..., л. 4]. Шулай итеп мулла диссидентка әйләнә. Хастаханәдән чыккач та Х. Мәхмүтов дини эшчәнлеген дәвам иттерә: исем куша, никах, җеназа намазларын укый (үзе әйткәнчә, «отпевание» үткәрә [мөселман дин әһелләренең христиан терминнарын куллануы турында тулырак: Bustanov, Kemper, p. 258–277]), теләгән кешеләргә дин сабагы бирә [Х.В. Мәхмүтов автобиографиясе, б. 3].

Үзгәртеп кору елларында шәһәрдә ике дини үзәк эшли: рәсми (Җәмигъ мәчете каршында) һәм рәсми булмаган (Хафиз хәзрәт Мәхмүтов). 1987 елдан К. Маркс исемендәге мәдәният йортында ислам нигезләре, Коръән, гарәп телен өйрәнү буенча курслар эшли башлый. Бу курслар М. Җәлил исемендәге Татар мәдәниятен сөючеләр клубы тарафыннан оештырыла. Соңыннан оешма Ленинград татар

мәдәни үзәге итеп үзгәртелә [Ислам в Петербурге: энциклопедический словарь].

1980 еллар уртасында татар зыялылары беренче чиратта милли мәдәниятне торгызу эшен кайгырталар, ислам икенче планга кала. Ленинград шәһәре татарлары һәм башкортлары өчен төп бәйрәм – Сабантуй[1].

1980–1990 елларда мәчеткә яшьләр дә йөри башлый. Совет чорының соңгы елларына караган фотосурәтләрдә Ленинградта һәм гомумән илдә мөселманнар арасындагы буыннар алмашы ачык күренә. Шулай да үзгәртеп кору елларында Ленинград мөселманнары этник яктан күбрәк татар, башкорт була әле. Башка милләт вәкилләре күпләп кушылу 1990 еллар уртасына туры килә. Җәмигъ мәчетенең имам-хатыйбы булып Җ.Н. Пончаев кала бирә, ә 1993 елда «Әл-Фәтх» Санкт-Петербург мөселманнары оешмасын теркәгән Х.В. Мәхмүтов Петербургның рәсми булмаган имамы булып тора.

1980–1990 еллар башында иҗтимагый, дини тормышны демократияләштерүгә карамастан, Ленинград мөселманнары элек кабул ителгән тәртип буенча яшәүләрен дәвам итә.

### Әдәбият


*Аминов Д.А.* Татары в Санкт-Петербурге: ист. очерк. СПб., 1994.

Б.Б. Таканаев белән әңгәмә. 2015 ел, 10 август. (Автор материаллары)

*Бабель И.Э.* О лошадях // Бабель И.Э. Петроградская проза: сборник. СПб., 1993. С. 45–47.

*Беккин Р.И.* Забытые мусульманские кладбища в окрестностях Петербурга // История Петербурга. 2014. № 1. С. 81–85.

*Георги И.Г.* Описание российско-императорскаго столичнаго города Санктпетербурга и достопамятностей в окрестностях онаго. СПб., 1794. [Ч. 1]. С. 282.

*Григорьев М.А.* Петербург 1910-х гг. Прогулки в прошлое. СПб., 2005. С. 251.

*Гусева Ю.Н.* Ишанизм как суфийская традиция Средней Волги в XX веке: формы, смыслы, значение. М., 2013.

Заявление Президенту, конгрессу и госдепартаменту США от гражданина СССР Махмутова Хафиза Валиевича, религиозного деятеля. (М.Х. Мәхмүтованың шәхси архивыннан)

Ислам в Петербурге: энциклопедический словарь. М. – Н. Новгород, 2009. URL: http://www.idmedina.ru/books/encyclopedia/?3389

Ислам и советское государство / сост., авт. предисл. и примеч. Д.Ю. Арапов. М., 2010. Вып. 1; Вып. 2: (1917–1936); М., 2011. Вып. 3: (1944–1990).

*Исхаков С.М.* Российские мусульмане и революция (весна 1917 г. – лето 1918 г.). М., 2004.

Как Смольный Джавахарлала Неру перехитрил // Вечерний Петербург. 2010. 15 марта. С. 9.


---

[1] Кызыклы факт: 1970–1980 елларда Сабантуй, Корбан һәм Ураза бәйрәмнәре «Бугры» совхозы территориясендә милли бәйрәмнәр буларак үткәрелә.

[Ключева М.И.]. Страницы из жизни Санкт-Петербурга 1880–1910 // Невский архив: историко-краеведческий сборник. СПб, 1997. Вып. III. С. 206.

М.Х. Мәхмүтова белән әңгәмә. 2015 ел, 28 август. (Автор материаллары)

Обвинительное заключение по след. делу № 111999 по обвинению националистической контр-революционной группировки, возглавляемой муллами Халиковым Якубом и Басыровым Кемалем, в пр.пр.ст. 58-4 УК. Л. 368–369. (Архив Центра «Возвращённые имена» при РНБ)

*Оболенский В.А.* Моя жизнь. Мои современники. Париж, 1988. С. 13.

[Ответ на прошение мусульман о расширении магометанского кладбища] // РГИА. Ф. 487. Оп. 4. Д. 686. Л. 7.

*Салахбекова З.А.* Власть и мусульманское духовенство Дагестана: история взаимоотношений (1920–1940 гг.): автореф. дис. ... канд. ист. наук. Махачкала, 2003.

Санкт-Петербург: энцикл. слов. СПб., [2007– ]. URL: www.encspb.ru/object /2803920605?dv=2853931022&lc=ru

*Сафаров М.А.* Повседневная жизнь московских мусульман в 1960–1980-х годах // Неприкосновенный запас. 2012. № 4 (84). С. 139–148.

*Сенюткин С.Б., Идрисов У.Ю., Сенюткина О.Н. и др.* История исламских общин Нижегородской области. Н. Новгород, 1998.

*Старовойтова Г.В.* Этническая группа в современном советском городе. Социологические очерки. Л., 1987. С. 117–118.

*Тагирджанова А.Н.* В костеле мог бы звучать азан… // История Петербурга. 2008. № 2 (42). С. 53–60.

*Тагирджанова А.М.* Татарские детские дома в Петрограде-Ленинграде 1920-х годов // История Петербурга. 2008. № 6 (46). С. 53.

*Троцкий Л.Д.* Моя жизнь. Опыт автобиографии. М., 1991. С. 406.

Х.В. Мәхмүтов автобиографиясе. (М.Х. Мәхмүтованың шәхси архивыннан)

Х.В. Мәхмүтов көндәлеге. 1975 ел, ноябрь. (М.Х. Мәхмүтованың шәхси архивыннан)

*Bustanov A., Kemper M.* The Russian Orthodox and Islamic Languages in the Russian Federation // Slavica Tergestina. 2013. Vol. 15: Slavia Islamica. P. 258–277.

*DeWeese D.* Islam and the Legacy of Sovietology: A Review Essay on Yaacov Ro'i's Islam in the Soviet Union // Journal of Islamic Studies. 2002. Vol. 13 (3). P. 298–330.

*Ro'i Y.* Islam in the Soviet Union: From the Second World War to Gorbachev. New York, 2000.

**Беккин Ренат Ирек улы,**
*икътисад фәннәре докторы, Россия Фәннәр академиясе Африка институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 94(47)

***А.Х. Мәхмүтова***

## АКЧУРИННАР НӘСЕЛЕ ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ

Статья посвящается жизнедеятельности журналистки Зухры Акчуриной и писательницы Махбубджамал Акчуриной, из рода сибирских купцов Акчуриных. З. Акчурина вместе с мужем И. Гаспринским участвовала в издании газеты «Тарджеман» в г. Бахчисарай, являлась автором публикаций, переводила материалы, оформляла документацию и подписку на издание. М. Акчурина в своих статьях уделяла внимание общественным и нравственным проблемам татарского общества нач. XX в. Эти и другие подробные сведения из жизни Акчуриных нашли отражение в предлагаемой вашему вниманию публикации.

**Ключевые слова:** З. Акчурина-Гаспринская, Исмагиль Гаспринский, газета «Тарджеман», М. Акчурина, публицистика, просвещение, творчество.

### *Зөһрә Акчурина-Гаспринская*

Бакчасарай шәһәрендә (Кырым) 1883 елдан төрки-татар телендә нәшер ителгән «Тәрҗеман» газетасының төрки халыкларның мәдәни, рухи тормышындагы роле күпләргә мәгълүм. Бу газетаны чыгарыр өчен җанытәне белән тырышкан, утыз елдан артык аның нашире һәм мөхәррире вазифасын башкарган атаклы мәгърифәтче Исмәгыйль Гаспринскийның (1851–1914) исеме дә шулай ук күпләргә билгеле. Ә менә аның белән бергә газета чыгаруның беренче 15–20 елында бөтен авырлыкларны күтәргән, мөхәррир белән кулга-кул тотышып эшләгән, аның иң зур терәге булган кеше – Исмәгыйль бәкнең хәләл җефете, фикердәше Зөһрә ханым икәнен бик сирәк кеше беләдер. Шуңа күрә Акчуриннар нәселе хатын-кызлары хакында сөйләүне аның исеменнән башлау урынлы булыр.

1862 елда атаклы татар эшмәкәрләре Акчуриннар нәселеннән булган Әсфәндияр Курамша углы һәм аның сөекле хатыны Фатыйма ханым гаиләсендә, Гаяз Исхакый сүзләре белән әйтсәк, «кара туткыллы, матур йөзле, үткен күзле» кызчык дөньяга килгән. Бу «сөемле, сөйкемле» балага Биби-Зөһрә исемен кушканнар. Аның сабый чагы Акчуриннарның нигезе, нәсел оясы саналган Сембер губернасы Зөябашы (Старое Тимошкино) авылында үткән. Кыз үсә төшкәч, гаилә я Курамша Акчурин сатып алган һәм мирас буларак Әсфәндияргә күчкән Коромыслово утарында, я губерна үзәге булган Сембер шәһәрендә яшәгән. Бу шәһәрдә күпсанлы Акчуриннар нәселенең һәр тармагы диярлек үз йортын тоткан. Зөһрәнең балачагы һәм яшьлек еллары бәхетле, кайгы-хәсрәтсез узган. Әти-әнисе ир балалар арасында бердәнбер булган кызларын иркәләп, кадерләп үстергәннәр, аны, халык әйтмешли, өрмәгән җиргә утыртмаганнар. Кызчык та кечкенәдән бик акыллы, тирә-юнь

белән кызыксынучан, белемгә омтылучан булган.

Кызның әтисе Әсфәндияр бай Зөһрәгә гадәти мөселман тәрбиясе бирү белән генә чикләнмәгән. Рус алпавытларын, касыймлы татар морзаларын үрнәк итеп, кызына мөрәббия (гувернантка) алган. Рус милләтеннән булган мөрәббия Зөһрәне рус теленә өйрәткән, музыка (фортепьяно, җыр) дәресләре биргән, рус әдәбияты белән таныштырган. Чынбарлык белән очрашу, ул чорда хәтта бай катлам татар хатын-кызлары өчен хас булган тормыш – күпсанлы туган-тумача даирәсе белән генә чикләнмичә, бу даирәгә бик аз билгеле булган рус дөньясы белән танышу, үзенә күрә, Сембер губернасының элитасы – чыгышы белән татар һәм рус милләтеннән булган затлы гаиләләр белән аралашу... – болар барысы да Зөһрә туташның формалашуына зур йогынты ясаган. Аңа кечкенәдән үк хас булган күзәтүчәнлек, уйлануларга бирелү кызчыкта тирә-юньдәге галәмгә, аның тәртипләренә карата тәнкыйди караш тудырган. Зөһрә туташ, бирелеп, алдынгы рус әдәбиятын үзләштергән (ә бу дәвер рус әдәбияты мәгърифәтчелек, халыкчанлык идеяләре белән сугарылуын, аның нигезендә «укымышлы катламнар халык алдындагы бурычын үтәргә, халыкка хезмәт итәргә тиеш» дигән фикер ятуын да онытмыйк).

«Шуның өстенә аңарда искиткеч иттереп кием-салым, киенә белүгә вә кием-салымны төскә-башка муафикъ, килешә торган иттереп тегәргә осталык вкусы үсә. Ул һәрвакыт төсенә-битенә, буена, биленә муафикъ кием киенә вә нинди генә җирдә күңеленә охшаган төстә тегелгән күлмәк, кием күрмәсен, бер караудa отып алып, шуның кебек итеп үзе тегеп өлгертә», – дип язган Г. Исхакый. Бу зәвыклылыкның үсешендә, һичшиксез, рус аксөяк затлары белән аралашуның йогынтысы да булгандыр. Зөһрә туташ, «буйга үсеп җиткәндә зифа буйлы, көләч йөзле, җазибәле (сокландыргыч, үзенә карата торган) күзле, тирә-юньдә иң матур кыз» булган.

Ләкин ул кешеләрнең игътибарын үзенең чибәрлеге, зифа буе, җитди, бер үк вакытта ягымлы карашы белән генә җәлеп итеп калмаган. Ул башкалардан үзенең белеме, сөйләшүенең кыюлыгы, тәнкыйди фикер йөртүе белән дә аерылып торган. Нинди генә җирдә булмасын – туган-тумача гаиләләрендәге бәйрәмнәрме ул, шәһәрнең аксөякләре арасындамы, яки пароходта сәяхәтме – Зөһрә туташ һәрвакыт игътибар үзәгендә булган. Исемен русчалатып, дуслары һәм туганнары аңа еш кына «Зоря, Зоренька» дип дәшкәннәр. Һәм бу исем аңа бик килешкән кебек: чыннан да, җиһанда таң аткан мизгелдә чыккан кояш кебек, килеп керүе белән ул тирә-юньне яктырткан, якыннарына, дусларына тереклек итәргә ярдәм иткән кебек тоелган.

XIX гасырның 70 елларында татар тормышында мондый халәт булуы шикле кебек күренә – мөселман тәрбиясен алган татар кызы, өстәмә рус-европа тәрбиясе булса да, руслар белән шулай иркен аралашканмы? Бераз

соңарып булса да, әйтеп үтим: бу мәгълүмат, нигездә, Гаяз Исхакыйның Исмәгыйль Гаспринский вафатыннан соң 1914 елның ноябрь-декабрь айларында «Ил» газетасында басылган мәкаләсеннән алынды. Шуны да күрсәтергә кирәк: Г. Исхакыйның Гаспринскийлар тормышында булган вакыйгаларны шактый тәфсилле итеп яктырткан язмасына Зөһрә ханымның туганнары Ибраһим һәм Мәхбүбҗәмал Акчуриннар үзләренең канәгатьсезлекләрен белдергәннәр һәм, язучының кайбер фикерләрен кире кагып, матбугатта мәкаләләр белән чыкканнар. Алар Г. Исхакыйны Акчуриннар һәм И. Гаспринский арасындагы мөнәсәбәтләрне дөрес күрсәтмәүдә, берьяклылыкта гаепләгәннәр.

Зөһрә туташ әле тормышта чыныгып җитәргә дә өлгермәгән чакта Акчуриннар гаиләсенә зур кайгы килгән – Зөһрә туташның яраткан әнисе Фатыйма ханым вафат булган. Әнисенең үлемен, соңрак этисенең икенче хатынга өйләнүен Зөһрә бик авыр кичергән. Үз уйлары, кичерешләре белән япа-ялгыз калган яшь кыз үз эченә йомылган, хәтта авыруга сабышкан. Бу хәл аның этисен, туганнарын кайгыга салган. Кызда ул чорның иң яман чире – туберкулез булмаса иде дип борчылган алар. 1880 елда этисенең энесе, Сембер кадетлар корпусын тәмамлап, нәсел эшенә – эшмәкәрлеккә керешкән Ибраһим Курамша углы (1859–1930 еллар башы) Кырымга ялга һәм дәваланырга барып кайтырга булган. Әсфәндияр аннан Зөһрәне дә үзе белән алуын үтенгән.

Яшь ягыннан да, рухи яктан да бер-берсенә бик якын булган абыйлы-сеңелле Акчуриннар (Ибраһим әфәнде соңрак татарлар арасында иң укымышлы, зыялы кешеләрдән танылачак) шулай Кырымга, Ялтага барып чыкканнар. Анда алар Кырымның Бакчасарай шәһәрендә шәһәр башлыгы булып эшләүче Исмәгыйль бәк Гаспринский белән танышканнар. Хәер, аның исемен Акчуриннар ишеткән булса кирәк дип фаразларга була. Бу шәхес аларның игътибарын ул чор төрки-татарларда бик сирәк очраган Төркия – Франция кебек илләрдә белем алуы белән дә, яңа гына дөнья күргән «Русское мусульманство» исемле китапчыгы белән дә җәлеп иткән булырга мөмкин. Кулларына эләккән бу китапчыкны Ибраһим һәм Зөһрә кат-кат укыганнардыр. Русия мөселманнарының киләчәгенә карата булган авторның карашлары аларны шаккатыргандыр: Русия мөселманнары җиһанда яшәсен, тәрәккый итсен өчен рус һәм Европа мәдәнияте белән коралланырга тиеш дип ассызыклаган ич ул! Исмәгыйль әфәнде алар күңелендә булган уй-фикерләрен төгәлрәк, ачыграк әйткән түгелме соң?

Шундый фикердәш, юк, фикердәш кенә түгел, остаз белән танышуларына Акчуриннар шул кадәр сөенгәннәр ки, ике дә уйлап тормыйча, алар, Исмәгыйль бәкнең үз йортына кунакка чакыруын кабул иткәннәр. Бакчасарайга барып, автор белән якыннанрак танышырга, аңа үзләренең рәхмәтләрен белдерергә, туган сорауларына җавап алырга

ашкынганнар. Менә очрашу, Исмәгыйль бәкнең туганнары белән танышу... «Сүзләре ни рәвештә йөрүе, ни булуы мәгълүм булмаса да, Гаспринский Зөһрә ханымда яхшы бер тәэсир калдырган кебек, Идел буеның зифа кызы Гаспринскийда да бик тирән тойгылар уята (*шул беренче күрешү хакында Исмәгыйль бәк үзе: «Бөтен тәнемә кайнар су койган кебек тәэсир калдырды», – дигән.* – Г. Исхакый искәрмәсе). Тагын берничә күрешсәләр дә, сүзләр күпкә китмәенчә, уйлар, тойгыларын берсен-берсе белмәенчә аерылышалар», – дип тасвирлаган Гаяз Исхакый булачак парның танышуын.

Димәк, Русия мөселманнарының язмышы хакында сөйләшүләр күп булса да, 29 яшьлек ир-ат белән 18 яшьлек кыз арасында шәхси хисләр, шәхси тойгылар турында бер сүз дә булмаган. Вакыт җиткәч, Акчуриннар туган якларына кайтып киткәннәр. Коромысловкага кайткач та, Зөһрә туташ бу танышу-сөйләшүләрдән алган тәэсирләре белән яшәвен дәвам иткән. «Зөһрә ханым өенә кайткач, уйлый-уйлый Исмәгыйль бәккә хат язу фикеренә килә. Вә һәм дә, беренче уларак, үзе хат яза (*Бу мәгълүмат шул мәсьәләне бик якыннан күргән кешенең үзеннән алынганга – дөрестер. Ике олуг кешемезнең бу хатлары, бәлки, вакыты берлә, матбугат мәйданына да куелыр*», – дип ассызыклаган Г. Исхакый). Уйлап кына карагыз: белемле һәм тәрбияле кыз, беренче булып, ир кешегә хат язган! Ул заман өчен генә түгел, хәтта егерменче гасырның урталары өчен дә мондый тәвәккәллек – иң кимендә, көтелмәгән адым дип бәяләнергә тиештер. Әлбәттә, кызның хатында сүз шәхси хисләр хакында түгел, ә Зөһрәне дулкынландырган милләт, мәгърифәт мәсьәләләре хакында булгандыр. Исмәгыйль бәк җавап хаты язган. Шулай Сембер белән Бакчасарай арасында хатлар йөри башлаган. Хатларда ике фикердәшне дулкынландырган күп кенә мәсьәләләр күтәрелгән, алар арасында, һичшиксез, шәһәр башлыгы хыялында туган төрки-татар телендә бер газета булдыру нияте дә булгандыр.

Газета чыгару фикеренә килгән И. Гаспринский 1881 елда төрки-мөселман җәмәгатьчелегенә рус телендә язылган бер мөрәҗәгать тә бастырган. Ул мөрәҗәгатькә керәчәк фикерләрнең дөреслеген Зөһрә туташта сынап та карагандыр дип фаразларга була. Булачак абүнәчеләрне һәм, мөмкин кадәр, иганәчеләрне дә эзләгән мәгърифәтче. «Билгеле, белем алу һәм гыйлем исламның асылын тәшкил итә; ләкин моны халыкның үз телендә китаплары, мәктәпләре, фәне, әдәбияты һәм басмаханәләре булганда гына тормышка ашырырга мөмкин», – дип аңлаткан ул. Исмәгыйль бәк басмаханәләрне кичектергесез булдыру кирәклеген дәлилләп чыккан, аларда нәшер ителәчәк һәртөрле басмалар милләтнең тәрәккыена хезмәт итәчәген күрсәткән. «Миллионлаган рус мөселманнары туган телләрендә эшләнгән китапларга, әдәбиятка, гомумән, матбугатка мохтаҗ», – дип ассызыклаган ул. Мөрәҗә-

гатьне ул Зөһрә туташка да юллагандыр дип уйлыйк.

Исмәгыйль бәкнең мөрәҗәгатьтәге һәм хат аша Зөһрә туташка җибәргән башка фикерләре укымышлы һәм хискә бирелүчән кызның йөрәгендә тирән эз калдыруын, һич икеләнмичә, фаразларга була. Морза булса да, байлыгы булмаган Исмәгыйль бәк, күрәсең, мәгърифәтчелек эшчәнлеген үз басмаханәсен булдырудан башлап җибәрергә уйлаган булган. Аның фикеренчә, басмаханә аңа газета чыгарыр өчен матди җирлек тә әзерләячәк. Хатларында ул Зөһрә туташка үзенең һәр адымы, юлында очраган күпсанлы киртәләр турында да язгандыр. Туташ исә, тарихтан һәм әдәбияттан мисаллар китереп, аның юлының дөреслегенә ышанычын, куелган максатына ирешү теләген ныгытырга тырышкандыр. Шулай, хат аша, ике ялкынлы йөрәк, тынгысыз җан бер-берсенә якынлашкан, булачак парның күңелләрендә беренче очрашуда ук туа башлаган хисләр ныгыган, тамыр җәйгән. Һәм, күпмедер вакыт узгач, алар язмышларын берләштерергә булганнар.

Исмәгыйль бәк 1881 елда Мәкәрҗә ярминкәсендә шул ниятне тормышка ашыру өчен Ибраһим Акчуриннан ярдәм сораган. Ләкин И. Акчурин арадашчы булудан баш тарткан. Исмәгыйль бәк үзе Коромысловкага Әсфәндияр байдан кызын сорарга киткән. Күрше рус авылына туктаган И. Гаспринский Зөһрәгә үзенең килүе хакында хәбәр җибәргән. Кич белән алар Акчуриннар бакчасында яшертен генә очрашканнар, аңлашканнар, сүз бирешкәннәр... Исмәгыйль бәк кызның этисе белән үзе очрашып сөйләшергә булган. Иртән, Зөһрәләрнең өйләренә кыз сорарга юнәлгән Исмәгыйль бәк юлда Әсфәндияр әфәндене очраткан һәм үзенең йөрәген ачып салган.

«Әсфәндияр абзый бу әллә нинди озын бүрекле, үзен язучы дип йөри торган килмешәкнең кыз – исемле кызын – батырчылык итеп соравына аптырап кала. Бу фабрикант углы түгел, мәшһүр байның нәселе түгел кара егетнең фабрикант Әсфәндияр абзый Акчуринның кызын сорауга хурлана. Исмәгыйль бәкне эт итеп тирги. Ләкин аның белән эш бетми, ул тагы искиткеч сүз сөйләп, кыз үзе разый-фәлән, дип Әсфәндияр абзыйны хурландыра. Ул ни дигән сүз, имеш, фабрикант Әсфәндияр абзыйның сөекле кызы Зөһрә әллә нинди кызыл баш, Исмәгыйль исемле бер кешене сөйсен, имеш! Бу әдәпсез егетне Әсфәндияр абзый ни дип тетмәсен тетеп җибәрмәгәндер», – дип сурәтләгән бу күренешне Г. Исхакый.

Эшнең уңышсыз тәмамлануы хакында Исмәгыйль бәк Зөһрә туташка хәбәр иткән. Кич белән алар тагын шул ук бакчада очрашканнар, ниятләреннән чигенмәскә сүз бирешкәннәр. Ул гына да түгел, «ике шаһит белән килеп, бакча буенда айның йомшак нуры астында бергә-бергә булышырга вәгъдә кылышып, алдым-бирдем ясаганнар». Икенче көн иртән, үзен мәһабәт күрсәтә торган шәһәр башлыгының укалы рәсми киемнәрен киеп,

Исмәгыйль бәк тагын Акчуриннар йортына килеп кермәсенме... «Әсфәндияр абзыйның сабыры төкәнә, өеннән куып чыгара. Аның белән генә чикләнмичә, бу әдәпсез егеткә Акчуриннар фамилиясен мыскыл итеп йөрүе бушлай калмаганны күрсәтер өчен, свисток биреп, фабриканы туктата, вә шундагы эшчеләрне Исмәгыйль бәккә гакыл өйрәтергә, кычыткан җирләрен кашырга куша», – дип язган Г. Исхакый.

И. Гаспринскийны кыйналудан алтын белән чигелгән затлы киеме генә коткарып калган: аны бакчада урап алган эшчеләр моңа кадәр күрмәгән рәсми мундир кигән кешегә кул күтәрергә кыймаганнар. Мәңге бергә булырга сүз бирешкән пар кире чигенмәгән. «Алдым-бирдем» язуын кызның туганнарыннан танытa алмагач, булачак кияү Уфага, мөфти каршына киткән: шаһитләр алдында төзелгән никах килешүе законлы документ буларак саналырга тиеш. Мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев, Исмәгыйль бәкнең дәлилләрен кабул итеп, «алдым-бирдем» язуының кануни булуын раслаган һәм И. Гаспринский кулына шуны дәлилләгән рәсми кәгазь дә биргән. Моннан тыш ул Акчуриннарның иң абруйлыларыннан булган Тимербулат Курамша углына, мәсьәләне күркәмлек белән ябарга кушып, хат та җибәргән.

Коромысловкага яңадан килгән Исмәгыйль бәк шул авылда яшәүче судебный следовательдән үзе һәм Акчуриннар арасында арадашчы булуын үтенгән. Следовательнең Әсфәндияр бай йортына килеп керүе үзе зур куркуку тудырган. Бу эшкә хөкем дә катнашкан дип уйлаган Әсфәндияр бай, агасы Тимербулатның да киңәшен тыңлап, теләсә-теләмәсә дә, ризалыгын бирергә мәҗбүр булган. Ниһаять, гади генә, никах мәҗлесенә бер дә охшамаган кыз бирүне оештырганнар. Ләкин Әсфәндияр бай, яшьләр алдына тагын бер киртә куеп, Исмәгыйль бәктән ике мең сум мәһәрне шунда ук түләүне шарт итеп куйган. Ниһаять, атаны вексельгә ризалаштырып, Исмәгыйль бәк белән Зөһрә туташ кушылганнар. Ләкин моның өчен аларга никадәр көч, никадәр энергия сарыф итәргә, күпме сүз ишетергә туры килгән!

Атаклы мәгърифәтче Ризаэддин Фәхреддиннең «Мәшһүр хатыннар» исемле әсәрендә дә татар хатын-кызлары арасында асылташ булган Зөһрә ханым хакында сөйләү өчен урын табылган. Югарыда тасвирланган вакыйганы галим болай бәяләгән: «Чынлыкта байлыгы, малмөлкәте вә каләменнән башка малы булмаган бер затка иптәш булуы мәгариф юлындагы фидакарьлегенә дәлилдер. Сөйләүләренә караганда, бу теләге шул дәрәҗәдә булган, имеш, ата вә башка якыннарының каршылыгына карамыйча, туган ягы Сембер өлкәсен ташлап, Кырымга, Бакчасарайга һиҗрәт итмешләрдер».

Уй-фикерләрнең берлеге, ике йөрәк арасында кабынган мәхәббәт, милләтнең якты киләчәгенә өмет белән карау, ул көннәрне якынайту өчен җиң сызганып эшләргә җыену – болар барысы да Исмәгыйль бәк һәм Зөһрә

ханымга бар киртәләрне җиңеп чыгарга, олуг ниятләр һәм олуг эшләр белән тулы уртак тормышны башлап җибәрергә мөмкинлек биргән. 1883 елда И. Гаспринский, ниһаять, рус һәм татар телләрендә газета чыгару өчен хөкүмәтнең рөхсәтен алуга ирешкән. Зөһрә ханым иренең башлангычын тулысынча хуплаган. Бу хуплау һәм рухи, һәм матди чагылыш тапкан: Зөһрә ханым үзенең бирнәсен һәм хәтта бизәнү әйберләрен дә тулысынча газета чыгаруга сарыф иткән.

1883 елның 10 апрелендә, ниһаять, «Тәрҗеман» исемле газетаның беренче саны дөнья күргән. Шулкадәр көч куеп, тырышып-тырмашып, тәвәккәллек, каһарманлык, катлаулы дипломатик адымнар таләп иткән эшне башкарып чыкканда, газетаның нашире һәм мөхәррире Исмәгыйль бәк Гаспринскийга 32 яшь, ә аның хатыны һәм алыштыргысыз киңәшчесе, фикердәше, ярдәмчесе Зөһрә ханымга 21 яшь булган. Менә аларның кулларында газеталарының беренче, «яңа гына мичтән чыккан коймак кебек кайнар» нөсхәсе. Әле барысы да алда: газета чыгаруга бәйле төрле авырлыклар да, абунәчеләр челтәрен булдыру да, газета тирәсенә фикердәш-теләктәшләрне туплау да, төрки-мөселман дөньясында дан-шөһрәт яулау да. Һәм барлык эшләрдә дә Зөһрә ханым ире белән кулга кул тотышып эшләгән, авырлыклар да уртак булган, шатлыклары да...

Газета чыгару нинди шартларда башланганын Гаяз Исхакый түбәндәгечә тасвирлаган: «Тәрҗеман» чыга башлый. «Тәрҗеман»ны бастырганда, Исмәгыйль бәк берлә Зөһрә ханым берсе артлы берсе Нух заманыннан калган, кул берлә әйләнә торган басма машинасын әле берсе, әле берсе әйләндерәләр. Басып беткәч, үзләре бөгәләр (*фальцевать итәләр.* – Г. Исхакый искәрмәсе). Аларга үзләре адреслар язалар, үзләре маркалар бастырып, почтага илтәләр. Номер озатылып беткәч, тагы ике дус киләчәк номерга материал хәзерләргә тотыналар. Исмәгыйль бәк яза, Зөһрә ханым аның телен аңлашырлык итәр өчен сүзләр куша, төзәтә, татарчалаштыра, тагы ишәк хезмәте булган машинаны әйләндерәләр, тагы бөгәләр, адрес язалар, почтага илтәләр...». Табигый, ике кеше көче белән шундый шартларда чыгарылган газета зур да була алмаган, тиражы да санаулы булган. Беренче елларда газета кечкенә форматлы бер бит тәшкил иткән: битнең бер ягында русча текст, икенчесендә шул ук материалның татарчасы урнаштырылган.

Газета Русиянең төрки-мөселман дөньясында милләт үсеше өчен матбугатның зарурилыгын аңлатырга кирәк булган чорда чыга башлаган. Бу күп тырышлык, көч сорый торган эшне дә И. Гаспринский башкарырга тиеш булган. Мәгърифәтченең тормышын һәм эшчәнлеген тирәннән өйрәнгән галим В.Ю. Ганкевич «газетаның аякка басу чоры никадәр авыр булуын И. Гаспринскийның газетасына языларга һәм аны таратырга өндәп күпсанлы мөрәҗәгатьләр бастыруы да дәлил булып тора», – дип яза.

Ләкин, газета чыга башлаганга берничә ел узгач та, журналист С. Филипповка биргән интервьюсында Исмәгыйль бәк матди авырлыкларга күп тукталып тормаган: алар гына булса, җиңеп булыр иде, дигән, мөселманнарның яшәү шартларының катлаулыгына аеруча борчылуын белдергән.

Ничек кенә булмасын, газета аңлаткан мәгърифәтчелек идеяләре төрки-татарлар арасында шактый тиз арада тарала башлаган. Абунәчеләр саны да арткан. «Тәрҗеман» чыга башлаган беренче елда ук аның, Кырымнан тыш, Түбән Новгород (Нижгар), Казан, Әстерхан, Ырынбур, Тифлис, Баку, Касыйм, Уфа, Орск, Иргиз, Ростов-Дон, Петропавловск һ.б. шәһәрләрдә абунәчеләре булган. Газетада 1885 елда Казан, Уфа, Ырынбур, Тубыл, Әстерхан, Самара, Саратов губерналарына 350, Кавказга – 150, Төркестанга 200 нөсхә җибәрелүе күрсәтелгән. 1891 елның 31 декабрь санында редакция мондый мәгълүмат биргән: газета чыга башлаган елның (1883) азагына газетаны кимендә 320 кеше яздырып алган булса, 1884 елда бу сан 406, 1885 елда 1000 гә, 1891 елда исә 1500 гә җиткән.

Бу саннар үзләре үк газетаның популярлыгы үсүе хакында иң көчле дәлил булып тора. Әлбәттә, саннар, бүгенге күзлектән караганда, кечкенә булып күренергә мөмкин. Ләкин бу әле эшнең башы гына икәнен онытмыйк. Газетаның нәрсә икәнен белмәгән һәм аңа шикләнеп караган халык арасында ике-өч елда мең абунәче табуны зур уңыш дип бәяләргә була. Ә бу, үз чиратында, һичшиксез, Гаспринскийларның абруе һәм мәгърифәтчелек идеяләренең йогынтысы үсүен күрсәтә.

Авырлыкларны җиңеп, җиң сызганып, газета чыгарып яткан Гаспринскийлар абунәчеләре саны шулай артуга сөенергә өлгермәгән, аларга зур хәвеф-хәтәр кичерергә туры килгән – 1885 елның 9 июлендә Бакчасарайда булган зур янгында матди чыганакларның төп нигезе булган басмаханә көлгә әйләнгән. Газетаны вакытлыча туктатып торырга мәҗбүр булганнар. Барлык көчләрен, бетмәс-төкәнмәс энергияләрен эшкә җигеп, Гаспринскийлар кыска вакыт эчендә акчасын да тапканнар, иганәчеләр ярдәме белән басмаханә өчен яңа бина да салдырганнар, яңа җиһаз да алганнар һәм 16 сентябрьдә яңартылган газетаны бастырып та чыгарганнар.

Бу хакта газетада аңлатма да урнаштырылган. Анда газетаның хәзер атнага ике мәртәбә чыгуы, программасында рәсми, сәяси, әдәби һәм төрлесеннән дигән даими бүлекләр булуы хәбәр ителгән. «Укучыларына дөнья тормышыннан хәбәрләр биреп, «Тәрҗеман» рус мөселманнары арасында тәрәккыять идеяләрен таратуга һәм аларның Ватанга якынлашуларына ярдәм итүне үзенең бурычы итеп саный. Шул ук вакытта редакция, гомумән, Шәрекъ белән кызыксынучылар өчен дә газетаның кызыктырырлык булуы хакында кайгырта... Редакция барлык зыялы мөселманнардан һәм тәрәккыятькә теләктәшлек күрсәтүчеләрдән «Тәрҗеман»ны игътибарсыз кал-

дырмауларын һәм аның үзләре яшәгән төбәктә таралуына ярдәм итүләрен үтенә, чөнки газета формасы һәм эчтәлеге ягыннан бары тик җәмәгатьчелекнең теләктәшлеге һәм ярдәме булганда гына үсә ала», – дип язылган анда.

Һичшиксез, әле озак вакытлар Русия мөселманнары арасында газета ят, сәер нәрсә булып кала биргән. Күп еллар ул, матди яктан караганда, хуҗаларыннан чыгымнар гына таләп иткән һәм үзен-үзе XX гасыр башында гына аклый башлаган. Дөрес, ул вакытта да ул зур табыш китермәгән. Ләкин газетаның үз-үзен тәэмин итә алуы үзе үк газета пропагандалаган мәгърифәтчелек идеяләренең тарафдарлары табылуы, якынча ике дистә ел эчендә Гаспринскийларның газетаның даими укучысын тәрбияләп җиткерүе хакында сөйли түгелме? Әлбәттә, бу юлда Исмәгыйль бәк һәм Зөһрә ханым бергә, фидакарьләрчә, армый-талмый хезмәт иткәннәр, халыкны агарту эшен, мәгариф таратуны киң җәелдерү өчен тырышканнар.

Биш-алты ел дәвамында алар барлык газета чыгару процессына бәйле бетмәс-төкәнмәс эшләрне икәү бергә башкарганнар. Укучылардан килгән күпсанлы хатларга җавап бирүне Зөһрә ханым үзенең бурычы итеп санаган, аларны газетада басарга әзерләгән, газетага фикердәшләр-иганәчеләр эзләп Исмәгыйль бәк сәфәргә чыгып киткән вакытларда (ә бу шактый еш булган) мөхәррир-нашир вазыйфаларын да үтәгән. Зөһрә ханым, «сөйләүләренә караганда, «Тәрҗеман» гәзитен нәшер итүдә беренче хезмәткәрдер. Һиҗри белән 1300, милади белән 1883 елда «Тәрҗеман» гәзите оешып, барлык өлкәләр хәбәрләшә башлагач, Идел вә Урал тарафындагы төркиләр сөйләшүен Исмәгыйль бәктән дә әйбәтрәк белгән Зөһрә ханым мөһим хезмәтләр язды, – дип күрсәткән Р. Фәхреддин. – [...] Исеме гәзиттә әллә ни күренмәсә дә, яхшы хезмәте вә мәгариф юлында күп тырышлыклары мәгълүм».

Зөһрә ханым, Исмәгыйль бәкне йорт мәшәкатьләреннән бушатып, аңа тулысынча газета эшләре белән шөгыльләнү мөмкинлекләрен дә тудырган. Гаспринскийларның биш балалары булган – уллары Рефат, Айдар, Мансур һәм кызлары Шәфика һәм Нигяр. Бу зур, бәхетле гаилә Бакчасарай үзәгендә урнашкан иркен йортта яшәгән. Алар йортыннан кеше өзелмәгән – туганнар, дуслар, фикердәшләр... Газета тарала башлагач, бу йортка килүчеләр тагын да арткан. Кырымга барып чыккан төрле төрки халыкларның вәкилләре, үзләренең аңын кузгаткан газета чыгаручыларны үз күзләре белән күрергә, үзләрен борчыган сорауларга төгәл җавап табарга дип еш кына Гаспринскийларның йортына да килә торган булганнар. Һәм аларның ишекләре һәркемгә ачык булган.

Төрки-татар җәмәгатьчелеген мәгърифәтчелек идеяләренә һәм газета укырга күнектерүдә Гаспринскийлар эзлеклелек юлын сайлап алганнар. «Тәрҗеман»ның беренче санында бирелгән баш мәкаләдә язылганча,

газета, көченнән килгәнчә, мәдәни дөньяның аек, файдалы мәгълүматын мөселманнар арасына таратуны һәм рус җәмгыятен мөселманнарның тормышы, карашлары, ихтыяҗлары белән таныштыруны үзенең бурычы итеп куйган. 1883 елның 16 декабрь санында редактор укучыларын халыклар тормышындагы һәм дөнья илләрендәге вакыйгалар, тарих, география, дин тәгълиматына бәйле кызыклы материаллар белән таныштырып барырга тырышачагын җиткергән. 1886 елның 7 гыйнварында газетада, башка мәгълүмат белән беррәттән, халык мәгарифе, аның ихтыяҗлары хакындагы материалларга игътибар биреләчәге күрсәтелгән. 1889 елның 8 гыйнварында исә газетаның мәгърифәтчелек юнәлешендә аяусыз эшләячәге ассызыкланган.

Баштарак газета укучысына теге яки бу вакыйга хакында иң гади хәбәрләр генә җиткергән. Мәсәлән, 1885 елның 1 ноябрендә газетада урын алган «Яңа мәктәп» дигән кыска гына язманы алыйк. Үзенә күрә реклама ролен үтәүче язмада 1883 елда Бакчасарайда ачылган мәктәптә башта барлыгы 9 укучы гына булуы, хәзер укучылар саны иллегә җитүе хакында әйтелгән. Мәктәпнең программасы хакында да хәбәр бирелгән: ул гарәпчә һәм төркичә уку, төркичә язу, ислам дине нигезләре, матур язу һәм башлангыч хисаптан торган. Язма соңында укучыларның бу белемне ике ел эчендә бик җиңел үзләштерүләре турында да хәбәр җиткерелгән. Тора-бара мондый гади хәбәрләр янында милләт язмышы, мәгариф, милләтебез алдына килеп баскан төрле проблемаларны яктырткан җитди мәкаләләр дә урын алган. Гаспринскийлар журналист осталыкларын арттыра барган саен, укучыда газета белән кызыксыну да үсә барган.

Гаспринскийлар халыкны агарту юлында хатын-кызларны укытуның мөһимлеген дә аңлатырга тырышканнар. Бу проблема газета битләрендә үзенчәлекле урын алып торган. Газета күпсанлы мәкаләләр, фельетоннар аша (ул заманда бу исем астында, безнең көннәрдәге кебек, көлкеле яки сатирик материал түгел, киресенчә, җитди, көн үзәгендә булган зур язмалар басылган. – *А.М.*) белем-мәгарифнең хатын-кыз һәм ир-егетләр өчен бер үк дәрәҗәдә кирәк булуын аңлатырга тырышкан. Бу фикерне укучыларына җиткерү өчен төрле алымнар кулланылган, төрле мисаллар китерелгән. Мәсәлән, газета мондый дәлил кулланган: белеме булган бер кызның җәмгыяткә китергән файдасы берничә белемле егет китергән файдадан артыграк, чөнки белемле кыз, ана булгач, балаларына дөрес тәрбия һәм белем бирә алачак, җәмгыять өчен файдалы шәхесләр җитештерәчәк.

Һәм Р. Фәхреддин, һәм Г. Исхакый И. Гаспринскийның мәгърифәтче булып формалашуында Зөһрә ханымның ролен бик югары бәяләгәннәр. «Исмәгыйль бәкнең шул вакыттагы бөтен ислам дөньясында хак иттереп кабул иткән фикергә ялгыз көенчә каршы чыгып, хатыннарга ирек сораучыларның иң беренчесе

булуында да, минемчә, Зөһрә ханымның бик зур мәгънәви тәэсире булган булырга тиеш. Бу мәсьәлә Исмәгыйль бәкнең нинди гамәлләренең кушуы буенча хатын-кызга ирек бирү ягында булуы, нинди сәбәпләрдән аның «Хатын-кыз өлкәсе» килеп чыгуы, шөбһәсез, безнең әдәбият тарихымыз, безнең милли фикер барышымызның тарихында бик зур урын тотачактыр», – дип, Г. Исхакый Зөһрә ханымның иренә тәэсир итүен югары бәяләгән һәм киләчәктә бу мәсьәләнең хәл ителәчәгенә зур ышаныч белдергән. Зөһрә ханымның үзенең олуг хезмәте белән белемле хатын-кызның һәрбер эшне ирләрдән ким башкармавын дәлилләргә тырышуын Риза-казый да ассызыклаган. Исмәгыйль бәк, һичшиксез, Зөһрә ханым мисалында тирән белем һәм чын зыялылык хатын-кызның мөмкинлекләрен һәм сәләтләрен ачуына нык инанган дип бәяләгән ике язучы да.

«Тәрҗеман»ны аякка бастыргач, Гаспринскийлар, газетага өстәп, хатын-кызлар өчен махсус журнал чыгару фикеренә килгәннәр. 1887 елның 30 ноябрендә Бибизөһрә Гаспринская исеменнән Русиянең матбугат эшләре буенча Баш идарәгә татар хатын-кызлары өчен «Тәрбия» исемле кечкенә генә махсус журнал бастыруга рөхсәт сорап гариза юлланган. Айга ике тапкыр чыгарылачак журналның программасында бала тәрбиясе һәм йорт гигиенасы, хуҗалык, йорт алып бару, кул эшләре, башлангыч педагогика хакындагы мәкаләләргә игътибар биреләчәге, шулай ук балалар өчен рус теленнән үрнәк дәресләр каралуы ассызыкланган була. Петербургтан махсус журнал чыгаруга рөхсәт бирелмәү Гаспринскийларны хатын-кыз мәсьәләсен, Русиядә һәм башка илләрдәге мөселманнарнең хәлен газета сәхифәләрендә киңрәк яктыртуга этәргән диярге була.

Гаспринскийлар хатын-кызлар өчен махсус орган булдыру уеннан да кире кайтмаганнар. Бу хакта 1891 елның 21 февралендә И. Гаспринский тарафыннан эчке эшләр министрына җибәргән үтенеч сөйли. Анда «Тәрҗеман» газетасына «Кадын» исемле махсус кушымтага рөхсәт алу хакында сүз бара. Мәгърифәтчеләрнең бу үтенече дә кире кагылган. Хатын-кызлар өчен «Галәме нисван (Хатын-кыз дөньясы)» исемле махсус журнал чыгаруга рөхсәтне Исмәгыйль бәк 1905 елда, революция шартларында гына ала алган. Ләкин Зөһрә ханымга ул көннәрне күрергә язмаган булган инде.

1893 елның апрелендә «Тәрҗеман» чыга башлауга ун ел тулган. Гаспринскийларны олылау йөзеннән Бакчасарайга Русиянең төрле почмакларыннан фикердәшләре җыелган. Котлаулар, чәчәкләр, бүләкләр... Зөһрә ханымның газета чыгарудагы роле хакында да сүзләр булган. Иң җылы, иң ихлас сүзләрне Исмәгыйль бәкнең дусты, шәһәр башлыгы Мостафа Давидович җиткергән. Зөһрә ханым исеменә бик күп мактау сүзләре әйтеп, ул аны Русия мөселманнәре арасында беренче журналист дип атаган һәм Кырым татарлары исеменнән

зур зәвык белән эшләнгән алтын каптырма бүләк иткән.

Армый-талмый эшләргә, төрле мәшәкатьләрне җиңәргә күнеккән Зөһрә ханымга эш табылып кына торган. Газета аякка басып, аны алмаштырырлык хезмәткәрләр алынгач (аның энеләренең дә газетада эшләвен әйтергә кирәк), ул күп вакытын балаларын тәрбияләүгә бирә башлаган. Балалар үсә төшкәч, яңа эшкә – кызлар өчен үрнәк мәктәп төзүгә керешкән. 1893 елда ул Бакчасарайда үз хисабына беренче башлангыч кызлар мәктәбен оештырган. Бу мәктәпкә үрнәк булып Зынҗырлы мәдрәсәсе янында 1883 елдан бирле эшләп килгән җәдид ир балалар мәктәбе алынган.

Ел артыннан ел узган. Кешелек дөньясы яңа гасырны башлап җибәргән. Исмәгыйль бәк Гаспринский – танылган мәгърифәтче, төрки-татарларның милли әйдәманы, «милләт бабасы». Гаспринскийларның уртак җимеше булган «Тәрҗеман» газетасының төркиләр яшәгән барлык җирләрдә үз укучылары бар, мәгърифәтченең уй-фикерләре үзенең дәвамчыларын, фикердәшләрен тапкан. Балалар да матур гына үсеп килә. Тормыш җайлашты, Зөһрә ханым да иркен сулыш ала башлады дияргә була. Ләкин... Ачы язмыш Гаспринскийларга тагын бер һөҗүм әзерләп куйган икән – Зөһрә ханым тиф авыруын йоктырган. Ул 1902 елның 13 апрелендә каты авырудан соң вафат булган. Зөһрә ханымны зурлап, Зынҗырлы мәдрәсәсе янындагы ханнар каберлегенә җирләгәннәр. Соңрак, 1914 елда, аның кабере янында Исмәгыйль бәк тә җирләнгән. Ләкин Совет чорында бу каберлек җир белән тигезләнгән. Хәзер ул урында Исмәгыйль Гаспралыга багышланган истәлек ташы гына бар.

Беренче төрки-татар газетасы «Тәрҗеман»ның редакторы һәм нашире И. Гаспринскийның яраткан хатыны, якын дусты, фикердәше һәм иң беренче ярдәмчесе, татар хатын-кызлары арасында беренчеләрдән булып һәм дини, һәм дөньяви белем алган Зөһрә ханым Әсфәндияр кызы Акчурина-Гаспринская кырык яшендә фани дөньядан китеп барган. Без аны татар хатын-кызларының иҗтимагый сәхнәгә чыгуы хакында алдан хәбәр бирүче беренче татар журналисткасы дип тулы хокук белән әйтә алабыз.

«Тәрҗеман» газетасының 1902 ел 22 апрель санында шәһәр башлыгы М. Давидович тарафыннан язылган «Вафатнамә» урын алган. Анда ул мәрхүмә Зөһрә ханымның мөхәррирнең уң кулы булуын, газета чыгаруның иң авыр елларында аның барлык язу эшләрен алып баруын ассызыклаган: «Өйләренә килеп йөрүчеләр һәрвакыт мәрхүмәне, килгән мәктүпләрне укып, дәфтәргә каид итмәк яки газетаны катлап-кушаклап почтага юлламак эше илә мәшгуль күрерләр иде». М. Давидович Зөһрә ханымның Исмәгыйль бәк өчен ышанычлы рухи терәк булуын да күрсәткән.

Зөһрә ханым вафатыннан соң И. Гаспринский исеменә, кайгысын уртаклашып, өч йөзләп хат һәм телеграмма килгән. Газета-

ның 1902 елгы 15 май санында Исмәгыйль бәк, рәхмәтен белдереп, укучыларына түбәндәге сүзләрне юллаган: «Зәүҗәи мөхтәрәмәмез вә ярдәмчемез Зөһрә ханымның вафатыннан соң бер чук вилаятьләрдән тәгъзия телеграмлары вә намәләре килеп догалары мәгълүм улындыгыннан бу агыр көннәремездә бөек тәслия (юату) улмышдыр. Вөжданлы дусларымызның бу назик хиссиятләре (нечкә, гүзәл хисләр) безне аеры-аеры тәшәккерләргә бурычлы итсә дә, җөмлия берәр намә язмая хәл вә вакытымыз мөсагыйд (мөмкинлек) улмадыгыннан ошбу мәктүб илә җөмләсенә дел-җандан тәшәккер идеб, косурымызы (кимчелек, гаеп) гафу боермаларыны нияз (үтенү) идүм».

Г. Исхакый Гаспринскийларга багышлаган язмасының азагында Зөһрә ханымның тормышына мондый бәя биргән: «Ул Бакчасарайда 22 ел яши, кызлар үстерә, егетләр җиткезә. Исмәгыйль бәккә чын мәгънәсендә иптәш булып, аның тормышының ачысын-төчесен бергә бүлешә, аның кайгысын уртаклаша, аның шатлыгын зурайтыша. Һәртөрле авырлыкны ирләрчә күтәрә. [...] Татар хатынының бөтен җәмәгать хезмәтләрендә үтәмәгән бурычларыны өстеннән төшереп, татар морза кызлары-хатыннарының татар хатыны исеменә яккан кара тапларыны юып, татар хатынының бу таҗсыз ханымы, Идел буеның унтугызынчы гасырының икенче Сөембикәсе, җәннәттә таба юл ала. Үзеннән соң киләчәк миллион-миллионнарга үрнәк булып, шул шау-шулы тормыштан үтеп, дөньяның олуг хатыннары, әүлия кызларына кушылыр өчен югарыга аша».

Р. Фәхреддин Зөһрә ханымга багышланган очеркын аның тарихтагы урынын хәдис сүзләре белән билгеләгән. «Бер бөек кешене алыгыз да, тәрҗемәи хәлен укыгыз, һәрвакыт аның янында бөеклеккә юл хәзерләп вә күңелне шатлык вә гайрәткә этәреп тормакта булган бер хатынны күрерсез!» – дип ассызыклаган ул. Мин дә язмамны шул сүзләр белән тәмамлыйм. Дөрестән дә, Зөһрә ханым Исмәгыйль бәк өчен нәкъ шундый бәяләп бетерә алмаслык хатын булган.

### Мәхбүбҗәмал Акчурина

Әдәбиятка Русиядәге беренче революциядән соң килгән хатын-кызлар арасында Мәхбүбҗәмал Акчурина (1869–1948) үзенчәлекле урын биләп тора. Бик күп тармаклы атаклы Акчуриннар нәселенең бер әгъзасы булган кыз бала Саратов губернасы Кузнецк өязе Димау авылы имамы һәм мөдәррисе Әхмәр бине Хәсән Акчура гаиләсендә дөньяга килгән. Ул башта әтисеннән белем алган, соңрак үзлегеннән гыйлемен үстергән, авылдаш кызларны җыеп, укыту-тәрбия эшендә беренче тәҗрибә алган. 1892 елда аны Самара губернасындагы Савинка авылына кияүгә биргәннәр. Монда да ул, хосусый укытучылардан дәресләр алып, белемен үстерүне дәвам иткән. Ул гомерен кызлар укытуга багышлаган, гомумән, хатын-кызларны агарту-тәрбияләү эшенә актив керешкән, үзенең

әсәрләре белән матбугатта да күренә башлаган.

М. Акчуринаның әдәби эшчәнлегендә әдәбият белгечләре берничә юнәлеш билгелиләр. «1908 елдан башлап ул Оренбургта чыга торган «Шура», соңга таба Казандагы «Сөембикә» журналларында бала тәрбиясе, гаилә-көнкүреш гигиенасы мәсьәләләренә багышланган бер төркем мәкаләләрен бастыра, – дип язган аның хакында М. Гайнуллин. – [...] Шул ук 1908–1915 еллар арасында көндәлек матбугат битләрендә яки аерым басмалар булып әдибәнең реаль тормыш вакыйгаларына нигезләп язылган [...] хикәя һәм очерклары дөнья күрә».

Чорның прогрессив карашларын чагылдырган әсәрләрендә Мәхбүбҗәмал ханым төп проблема итеп татар җәмгыятен борчыган иҗтимагый һәм әхлакый мәсьәләләрне алган. Аның «Шура» журналында басылган «Багучылар» (1910), «Аталар һәм балалар» (1910), «Аналар дикъкатенә» (1911), «Тәрбия вә җәза» (1911), «Кәриһ (ямьсез) күренешләр» (1911), «Мәхәббәт дәресләре» (1912), «Балаларның уеннары һәм уенчыклары» (1913) һ.б. әсәрләре тәрбия-әхлак проблемаларын кискен куюы белән укучыларны җәлеп иткән. Гомумән, язучының мәкаләләре публицистик үткенлеге һәм заманча актуальлеге белән аерылып торган. Мәсәлән, 1915 елда «Сөембикә»дә дөнья күргән «Кемдән бу?» исемле мәкаләсендә ул халыкның артта калуында, бигрәк тә хатын-кызларның кол дәрәҗәсендә изелеп яшәүләрендә, дини хорафатлар һәм социаль тигезсезлекне кыю гаепләгән.

Шул ук 1908–1915 елларда, көндәлек матбугатта яки аерым басмалар булып, М. Акчуринаның проза әсәрләре дә дөнья күргән: «Кыз егълату» (1911), «Таш кием» (1913), «Хаммал Ягъкуб» (1915) һ.б. Язучының проза әсәрләре арасында «Мишәрләр тормышыннан бер ләүхә (күренеш)» һәм «Шәфкатьсез ата, яки мишәрләр тормышы» хикәяләре аеруча игътибарга лаек. 1914 елда басылып чыккан (беренчесе – «Шура» журналында, икенчесе – аерым басма рәвешендә) бу әсәрләрдә Мәхбүбҗәмал ханым мишәр авылы тормышында булган вакыйгаларны сурәтләп, татар хатын-кызларының аяныч тормышын күрсәткән. Гасырлар буена авыл җирендә хөкем сөргән наданлык, җаһиллек, төрле хорафатлар һөҗүме астында хатын-кызның кимсетелүен, түбәнсетелүен оста каләме белән тасвирлаган ул.

М. Акчуринаның хикәя-парчалары, очерк-мәкаләләре арасында 1911 елда «Шура» журналында басылган «Иске әдәбиятымыз» исемле очеркы үтә дә игътибарга лаеклы. Халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, язма мирасыбызны барлау һәм өйрәнү кирәклеге хакында беренчеләрдән булып матбугатта сүз башлаган тәнкыйтьче борынгы төрки-татар әдәбияты җәүһәрләреннән булган «Таһир илә Зөһрә», «Сәйфелмөлек» әсәрләренә мәкаләсендә тукталган, М. Гайнуллин сүзләре белән әйтсәк, «укучыларны күп гасырлар буе дулкынландырып килгән бу әсәр-

ләрнең халыкка эстетик тәрбия бирү ягыннан зур әһәмиятле булуын искәрткән».

Мәхбүбҗәмал ханым: «Безем һәрбер эшемез башкаларга караганда гаксенчә (киресенчә) барган кеби, әдәбиятымыз да шул гадәттән котыла алмыйдыр. Башка милләтләрдә борынгы язучыларның көннән-көн кадере, хөрмәте арта бара. Бездә борынгы мөхәррир вә әдипләремезне гаепләүчеләр күбәя. Яшьләр тарафындан язылмыш ниндәй генә мәкаләгә күз салсак та, бер китапка тигәнләре күренми калмыйдыр, – дип мәкаләсен башлаган. – [...] Бонлар арасында иң тынычсызлыкка очраганы «Сәйфелмөлек» һәм «Таһир илә Зөһрә»дер. Яшь язучы әфәнделәр, без хатын-кыз таифәсенең тәрбиясез калуларыны шушы китапларга ишарәт кыйлып, «Сәйфелмөлек», «Таһир илә Зөһрә»не укып юкка гомер сарыф итмешләр, диләр».

Шулай М. Акчурина яшь, яңа гына әдәбият дөньясына аяк баскан язучыларның күп буыннарны дулкынландырган борынгы әдәби әсәрләргә кимсетеп карауларын кискен рәвештә тәнкыйтьләгән. «Кашки (хәлбуки), без хатын-кызлар, бу китапларны укып, мәфһүмене (эчтәлек) аңлап, гомер сарыф итмеш улса идек, без дә, бәлки, бу кадәр түбән, һичбер нәрсәдән хәбәрсез калмаган булыр идек. "Сәйфелмөлек"не аңлаган кызга башка китапларны аңлау да кыен булмас иде. Бу китапларда, түгел хатын-кызларга, камил гакыллы ирләргә дә байтак файда алачак урыннар бар», – дип кисәткән Мәхбүбҗәмал ханым.

Язучы мондый әсәрләрнең әхлакый кыйммәтен күрсәткән, аларның бөтен халыкка, бигрәк тә яшь буыннарга әхлакый-эстетик тәрбия чыганагы булуына аеруча игътибар иткән. «Без үз телемездәге әдәбиятымызны кимсетүгә тырышамыз. «Иске шапканы пичкә ор, яңа шапка китерәм» дигән кабилдән (төр, төркем; кебек), искеләрне бөтенләй ташлап йибәрсәк, искедән дә, яңадан да коры калмамызмы икән?» – дигән сорау куйган укучылары алдына Мәхбүбҗәмал ханым, борынгы мирасны кире каккан әдәбиятның киләчәге шөбһәле булуына ишарә ясап. Бу әсәрләр, дип ассызыклаган ул, «гәрчә тиешенчә фәсахәт (матурлык) илә язылмаган улса да, көче йиткән кадәр тырышкан борынгы язучыларымызга рәхмәтләр укып, җир астында табылмыш таш балта, яки чүкеч кебиләрне ташламыйча саклау тиеш улдыгы кеби, бонларны да саклау өстемездә бурычдыр дип беләм».

Яңа әдәбият үсеше күзәтелгән, гыйлем-мәгариф таралуга яңа мөмкинлекләр ачылган заманда мәгърифәтче ханымны борын-борыннан халык хәтерендә сакланып килгән риваять-дастаннарның юкка чыгу куркынычы туу борчыган: «Берүк – анадан кызга, телдән-телгә килгән, үзенең махсус көе булган бер әсәрнең югалып китү ихтималы бар», – дип кисәткән ул татар җәмгыятен. Һәрбер борынгы әсәрнең үз көе, үз моңы булуына игътибарын юнәлтеп, бу хәл үзе үк татар музыкасының тарихы еракларга барып тоташуына ачык

дәлил булып тора, дигән фикерне куәтләгән Мәхбүбҗәмал ханым.

«Таһир илә Зөһрә» китабындагы җырларны борындан калган көе илә җырлаганда, гаепләүче әфәнделәрнең күңелләре рикъкатькә (нечкәлек) килеп, аркаларындан кырмыскалар йөрүендә асла шөбһә итмим. Дәхи дә бу ике китапның һәр икәвендә борында безем музыкамыз булганлыгы ачык күренеп торадыр. Безем үз халкымызда, ул ярамый, бу ярамый дип, һәр нәрсәдән ихлас кайтару гадәте көчле улдыгыннан, музыканы һәм гаеп итә-итә, ахырында бөтенләй югалып, туйларда аракы алдында уйнала торган скрипкә илә утыз-кырык тиенлек гармундан башка нәрсә калмамыштыр», – дип күрсәткән ул. Язучының бу фикерләре бүген дә шул кадәр урынлы ки, безгә аның белән ризалашырга гына кала.

Мәхбүбҗәмал ханымның мәкаләсендә киләчәккә өмет тә яши. «Бу китапларны бөтенләй рәттән чыгаруга тырышучылар күп булса да, киләчәктә мөселман операларында «Сәйфелмөлек» куелуына өмид өзеп булмыйдыр», – дип язган ул. Дөрес, аның бу өмете, теләге әлегә тормышка ашмаган. Чыннан да, XV гасырда Хәрәзмдә яшәгән шагыйрь Мәҗлиси тарафыннан борынгы шәрекъ риваятьләре нигезендә язылган «Кыйссаи Сәйфелмөлек»нең кульъязма күчермәләре һәм күпләгән басма текстлары (беренче мәртәбә Казанда 1807 елда басылган) халык арасында киң таралыш тапкан әсәрләр арасында булган. Бәлки безнең хәзерге композитор, музыкант, язучы, артистларыбыз, XX гасыр башында «Таһир илә Зөһрә»не сәхнәләштергән элгәрләреннән үрнәк алып, бу мөкаддәс эшкә керешерләр, үз иҗатларында «Сәйфелмөлек» мотивларына да урын табарлар, дип ышанасы килә.

Революциядән соңгы елларда М. Акчуринаның әдәби-публицистик иҗаты акрынлап тукталган. 1929 елда ул Бакуга күчеп киткән һәм тормышының соңгы елларын шул шәһәрдә уздырган.

**Хәдичә туташ Акчурина**

Мәкаләне татар кызлары арасыннан булган беренче рәссам хакында кыскача мәгълүмат биреп тәмамлыйм. Ул мәшһүр Акчуриннар нәселеннән чыккан Хәдичә Мөбин кызы булган. 1893 елда постау фабрикасы механигы Мөбин Акчурин гаиләсендә дөньяга килгән Хәдичәнең балачагы бу нәселнең төп нигезләреннән саналган Зөябаш авылында узган.Ул башта шул авылның татар кызлар мәктәбендә укыган. Гасыр башына хас милли аң үзгәрешләре Хәдичәгә дә дөньяви белемгә юл ачкан. Революция елларында аны Сембер кызлар гимназиясенә илткәннәр. Гимназиянең дүрт классын тәмамлаган егерме яшьлек Хәдичә туташ 1913 елдан Мәскәү югары сәнгать-сәнәгать училищесында (бу мәктәпкә 1825 елда граф С.Г. Строганов нигез салган була һәм ул хәзер дә аның исемен йөртә) белем алган. Кечкенәдән рәсем ясау белән мавыккан кыз анда укыган елларында ук җәмәгатьчелек игътибарын үзенә җәлеп иткән. «Аң» журналы-

ның 1915 елгы бишенче санында «Сәнаиге нәфисә юлында милли адым (Хәдичә туташ Акчурина рәсемнәре мөнәсәбәте белән)» исемле кечкенә генә язма һәм Хәдичә туташның дүрт рәсеме урнаштырылган.

Рәсемнәрдә татар тормышы сурәтләнгән. Аның беренчесендә көзге алдында утыручы татар кызы ясалган виньетка булса, икенчесенә милли киемдә мишәр кызы төшерелгән. Өченче рәсемдә ачык ишектән күренгән мәчет рәсеме (алгы планда мөәзиннең азан әйтүен тыңлаучы хатын сурәте бар), ә дүртенчесендә дүрт кыз баланың уйнавы тасвирланган. Хәдичә туташ 1913–1916 елларда Казанда чыгып килгән «Ак юл» исемле балалар журналы белән дә хезмәттәшлек иткән. Хосусан, журналның тышлыгында даими урын алган рәсем (анда чыгып килүче кояшка олы юлда кул астыннан карап торучы малай сурәте төшерелгән) Х. Акчуринаныкы дип исәпләнә. Беренче тапкыр 1913 елның өченче санында урын алган бу рәсем журналның эмблемасына әйләнгән. Кызганыч, ләкин бу сәләтле рәссам хакында мәгълүмат бик аз. Әйткәннәргә шуны гына өстәп була: Рәссам үзенең әсәрләренә «Х.А.», «Г.А.» дип үзенең авторлык тамгаларын куйган. Хәдичә туташ хакында соңгы мәгълүмат: беренче бөтендөнья сугышы елларында ул, шәфкать туташы булып, Кавказ фронтына киткән һәм гражданнар сугышы елларында хәбәрсез югалган. Бу хакта мәгълүмат И. Рамеевнең әдәби сүзлегендә китерелгән.

**Әдәбият**

*Исхакый Г.* Исмәгыйль бәк, Зөһрә ханым Гаспринскийлар // Ил. 1914. № 41–44, 47.

Милләт аналары: тарихи-документаль һәм биографик җыентык / төзүче-автор А.Х. Мәхмүтова. Казан: Җыен, 2004. 560 б.

Россия дәүләт тарих архивы. Ф. 776. Оп. 12: 1887 ел. Д. 54, 87.

Татарстан Республикасының Милли архивы. Ф. 186. Оп. 1: Д. 2.

Тәрҗеман (Переводчик). 1883–1902.

*Фәхретдин Р.* Мәшһүр хатыннар. Оренбург, 1903. Б. 209–211.

Шура. 1911. № 16. Б. 508–510.

***Мәхмүтова Альта Хаҗи кызы,***
*тарих фәннәре кандидаты*

УДК 376.5

*К.К. Исмәгыйлева*

# СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРНЕ ТӘРБИЯ МАКСАТЛАРЫНДА ФАЙДАЛАНУ

Рассмотрена структура деятельностной культуры через АВС-способности личности. На этой основе исследована возможность применения социальных сетей при воспитании спецконтингента.

**Ключевые слова**: социальные сети, культура, воспитание, специальный контингент.

Мәкаләдә информацион технологияләр, аерым алганда, социаль челтәрләрнең делинквет тәртипле яшүсмерләрне тәрбияләгәндә куллану мөмкинлекләре карала. Билгеләмә буенча, делинквет тәртип (лат. delictum – гаеп эш, хата эш, ингл. delinquency – хокук бозу, гаеп) – индивидның, аерым гражданнарга, шулай ук гомумән җәмгыятькә зыян китерүче гаеп, яисә хата эшләрендә гәүдәләнгән җәмгыятькә каршы булган начар тәртибе. Фәнни тикшеренүләрдә аерым игътибар яшүсмерләр делинквентлыгына юнәлдерелә. Яшь кешеләрнең яшүсмер чагында кылган деликтлар саны үсү, алар арасында авыр җинаятьләр дә арту күзәтелү җәмгыять өчен аеруча куркыныч. Аларны булдырмас өчен, яисә, һич югында, киметү өчен деликт китереп чыгаручы сәбәпләр, аларның яшьләр арасында таралуын тәэмин итүче шартлар, делинкветның шәхесе үзенчәлекләре, аны җәмгыятькә адаптацияләү мөмкинлекләре (социализация), делинквет субкультура, профилактика чаралары, хокук бозуларны булдырмау һәм башка шундый проблемаларны тирән өйрәнү зарур. Тайпылучан тәртипне делинквет дип тану хокукый нормаларны кабул итүче һәм аны законлаштыручы дәүләт һәм аның органнарының теге яисә бу гамәлне хокук бозу сыйфатында тануыннан тора [Змановская, с. 288].

### Тәртипкә авыр бирелүче яшүсмерләр белән эш юнәлешәре

Хөкем ителгән яшүсмерләр белән тәрбия эшенең мөһимлеге җинаятьчеләрне төзәтү системасының 2020 нче елга кадәр үсеш концепциясендә ассызыклап күрсәтелә. Аның буенча, социаль һәм психологик эшнең эффективлыгын арттыру, тәрбия эшчәнлегенең яңа формаларын табу, шәхескә психологик-педагогик тәэсирне көчәйтү приоритетлы мәсьәләләр булып тора.

Шартлы рәвештә хөкем ителгән балигъ булмаган яшүсмерләрне тәрбияләү эше күп факторлы. Яшүсмер шәхесенә гаилә, мәктәп, массакүләм мәгълүмат чаралары, җәмәгать оешмалары, мохит һ.б. тәэсир итә. Алар

белән эшләүче хезмәткәр-психологның мөһим бурычы – тәрбия процессын кызыклы итеп оештыру һәм аны файдалы итү. Шуңа күрә эшнең яңа формалары табыла, хөкем ителгәннәр белән рухи һәм патриотик тәрбия эшләре камилләштерелә, алар тренинг эшчәнлегенә, клубларга һәм түгәрәкләрдә эшләргә җәлеп ителә.

Тәрбиянең тагын бер үзенчәлеге – аның яшүсмернең үзенең дә актив позициясен таләп итүче озак вакытлы һәм даими процесс булуында Тәрбия нәтиҗәләре шундук күренми, ул шартлы рәвештә хөкем ителү вакыты чыкканнан соң сизелергә мөмкин. Педагог-психологның эш нәтиҗәсе шартлы хөкем ителгән яшүсмернең тәртибендә һәм аңында сизелерлек чагылырга тиеш.

Элек закон яки тәртип бозган бала белән хокук саклау органнары һәм мәгариф системасы гына шөгыльләнсә, хәзер балага һәм гаиләгә хезмәт күрсәтүче социаль хезмәтләр бергәләп эшлиләр. Казан шәһәре Идел буе районындагы Җәзаларны башкару Федераль казна оешмасының җәзаларны башкару һәм башка хокукый чараларны куллану бүлеге хезмәткәрләре бу махсус контингентның турыдан-туры тәрбиячеләре булып тора. Шартлы рәвештә хөкем ителгән яшүсмерләр белән махсус «Ювента» психологик-педагогик бүлеге максатчан эш алып бара. Проектның максаты – зур булмаган җинаятьләре өчен шартлы сроклар алган яшүсмерләргә кабаттан хокукка каршы гамәлләр кылмаска ярдәм итү. РФ Юстиция министрлыгының ТР буенча Җәзаларны башкару идарәсе мәгълүматларына караганда, Казан тәрбия колониясендә җәза үтәүче балигъ булмаганнар арасында сынау яки шартлы срок чорында җинаять кылган өчен хөкем ителгәннәр бар. «Ювента» оешмасы хезмәткәрләре эшенең төп юнәлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

– шартлы рәвештә хөкем ителгәннәр арасындагы деструктив күренешләрне (шәхесара һәм төркемара конфликтларны) өйрәнү, алдан күрү, аларның килеп чыгу сәбәпләрен анализлау, аларны кисәтү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

– хөкем ителгәннәр белән төркемләп һәм индивидуаль рәвештә психокоррекцион эш үткәрү;

– психопрофилактик һәм мәгърифәти эш үткәрү;

– соралган очракта хөкем ителгәннәрнең туганнарына психологик консультация үткәрү.

Җәзалар башкару инспекцияләрендә айга өч тапкыр педагог-психологлар шартлы рәвештә хөкем ителгән яшүсмерләр белән тренинг үткәрә. Тренингларда алар «Тормыш кыйммәтләре», «Басымга кршы тору», «Кризис: чишелеш бар», «Минем киләчәгем. Уңыш стратегиясе» һ.б.ш. темаларны өйрәнәләр, аралашу, ситуацияне һәм үз тәртибеңне анализлау, контрольдә тоту күнекмәләрен алалар. Шулай ук сәламәт тормыш рәвешен формалаштыру һәм үз сәламәтлегең өчен җаваплылык тудыру буенча дәресләр һәм чаралар үткәрелә.

Үткәрелгән чаралар нәтиҗәсендә аерым шәхесләрнең тискәре сыйфатлары, уңай тәэсиргә каршы торучанлыгы кими, төркемнең ышанычы арта, коммуникатив һәм социаль компетентлык күнекмәләре формалаша, психоэмоциональ көчәнеш алып ташлана.

Үзгәрү процессы, ягъни аңны һәм тәртипне үзгәртү бик катлаулы процесслар, чөнки тотрыклы характердагы тәртип стереотиплары үзгәрергә тиеш.

Тәрбия эше социаль хезмәткәрнең хөкем ителгән шәхескә турыдан-туры тәэсире нәтиҗәсендә түгел, ә бәлки аларның социаль тәэсир итешүе вакытында гына эффектив була ала. Димәк, шартлы хөкем ителүчеләр үзләре тәрбия процессында актив катнашырга, социаль һәм рухи тәҗрибәгә, кыйммәтләргә омтылырга тиеш. В. Сухомлинский әйткәнчә, кеше үз-үзен тәрбияләмәсә, аны беркем дә тәрбияли алмый.

## Шәхеснең эшчәнлек культурасы моделе һәм аны куллану

Махсус контингент белән тәрбия процессын тикшерү һәм аның эффективлыгын арттыру өчен индивидның сәләтләре аша тәэсир итү механизмын карыйк. Кешенең сәләтләре шактый зур дәрәҗәдә социаль һәм конкрет эшчәнлеге процессында формалаша. Сәләтләр үсешенә шартлар булу яисә булмауга карап алар актуаль яисә потенциаль булырга мөмкин. Боларны тирәнрәк карыйк.

Потенциаль сәләтләр сыйфатында конкрет эшчәнлек вакытында реализацияләнми, ләкин тиешле социаль шартлар булганда актуальләшә торган сәләтләр карала. Актуаль сәләтләргә исә, кагыйдә буларак, нәкъ бу мизгелдә кирәкле һәм эшчәнлекнең конкрет төрендә реализацияләнүче сәләтләр керә. Потенциаль һәм актуаль сәләтләр кеше яши торган социаль шартларның бер күрсәткече дә булып тора. Нәкъ менә социаль шартлар характеры потенциаль сәләтләрне үстерә яисә аларның үсешен тоткарлый, аларның актуаль сәләтләргә әверелүен тәэмин итә, яисә аңа комачаулый [Маклаков, 2015].

Г. Айзенк, Л. Кэмин, Б. Айсмонтас хезмәтләрендә сәләтләр – шәхеснең билгеле бер эшчәнлеге шартлары булып торучы индивидуаль үзенчәлекләре диелә [Айзенк, Кэмин, с. 352; Айсмонтас, с. 209]. Сәләтләр белем, осталык, күнекмәләргә генә кайтып калмый, ләкин аларны тиз үзләштерү, фиксация һәм эффектив практик куллануны тәэмин итә. Аларны исә эш алымнарының тиз, тирәнтен һәм нык үзләштерелүеннән белеп була. Теге яисә бу факторның сәләтләр үсүенә тәэсирен анализлау өчен Н.К. Нуриев хезмәтендә күрсәтелгән ысулны кулланыйк [Нуриев, с. 244].

Тормыштагы теләсә нинди проблеманы (мәсьәләне) чишүнең өч буыны (фазасы) бар: танып белү фазасы, чишелешнең алгоритмын төзү фазасы, башкару фазасы. Шулай итеп, проблеманы чишү башкаручының эшчәнлеге белән тәэмин ителә һәм аның өч сәләтенә (индивидуаль технологияләренә) нигезләнә.

Бу танып белү (формализация), конструктив (төзү) һәм башкару сәләтләре. Алар нигезендә, А.Ф. Галимьянов, К.К. Исмагилова хезмәтенә таянып, шәхеснең эшчәнлек культурасы моделен төзергә мөмкин [Деятельностная концепция культуры]. Культураның эшчәнлеккә нигезләнгән концепциясе культураны тикшерүдә иң йогынтылы агымнарның берсе булып тора. Биредә ике юнәлеш бар. Беренчесе культураны иҗтимагый тормышның универсаль үзлеге буларак характерлый (В.Е. Давидович, Ю.А. Жданов, М.С. Каган, З.И. Файнбург, Э.С. Маркарян һ.б.). Культура иҗтимагый процессның технологик аспекты кебек карала. Ул кеше эшчәнлегенең биологик чыганаклы булмаган катлаулы механизмнардан торган бер төре. Алар ярдәмендә кешеләрнең иҗтимагый активлыгы, шулай ук бу активлыкны стимуляцияләү, программалау һәм координацияләү тормышка ашырыла. Эшчәнлеккә нигезләнгән концепция тарафдарлары кеше эшчәнлегенең түбәндәге үзлекләренә басым ясыйлар: 1) ул иҗади һәм гамәли; 2) аны сәнәгать белән тәңгәлләп була һәм ул хайваннардагы шикелле спонтан түгел, ә максатчан; 3) ул башыннан ахырына кадәр социаль. Эшчәнлек өч аспектта карала: эшчәнлек субъекты күзлегеннән (гамәл кылучы күзлегеннән); эшчәнлек багышланган өлкәләрдән (кеше гамәле нәрсәләргә юнәлдерелә); эшчәнлек ысулыннан (кеше гамәле ничек башкарыла һәм аның тулаем эффекты ничек барлыкка килә). Шулай итеп, кеше эшчәнлеге адаптацияләүче-адаптив характерга ия. Ягъни, кеше табигатьне (тирә-юньне) үзенә яраклаштырып үзгәртә генә түгел, үзе дә шартларга яраклаша.

Культураның эшчәнлеккә нигезләнгән концепциясенең икенче юнәлеше (Э.А. Баллер, Л.Б. Коган, В.М. Межуев һ.б.) культура анализы нигезенә кешенең шәхес буларак үсешен сала. Культура үсеше критерие булып кешенең шәхес буларак үсеше тора. Культура теориясе кешеләр арасындагы предметлашкан (эшчәнлек нәтиҗәсе булган) мөнәсәбәтләрне тикшерми. Ул индивидларның эшчәнлек вакытында үзгәрешен тикшерә. Э.Г. Юдин эшчәнлекне тирә-юньдәге дөньяга кешегә генә хас булган актив мөнәсәбәт буларак билгели. Аның эчтәлеген исә культура формаларын үзләштерү һәм үстерү нигезендә бу дөньяны максатчан үзгәртү һәм үстерү тәшкил итә [Николаенко].

Эшчәнлекле культура үсеше чагыштырма бәяләмәгә мохтаҗ. Факторлар билгеле бер шартларда шәхес үсешенә тәэсир итә. Факторларның эшчәнлекле культура үсешенә йогынтысын күрсәткечләр һәм критерийлар нигезендә анализларга мөмкин. Эшчәнлек, эшчәнлеккә сәләтне эшчәнлек проблемасы чишелеше күзлегеннән карыйк. Эшчәнлекле культура структурасын А.Ф. Галимьянов, К.К. Исмагилова хезмәтенә нигезләнеп билгелик. Аның нигезендә, теләсә кайсы проблеманы чишү сәләте <A, B, C> сәләтләре өчлеге белән билгеләнә. Биредә A – танып-белү-формализацион сәләтләр,

В – иҗади-конструктив сәләтләр, С – башкару сәләтләре. Ул вакытта А-сәләтләр шәхеснең танып белү-мәгълүмати сыйфатына изоморф, В – сәләтләр төзү-иҗади, С – сәләтләр башкаручанлык сыйфатларына изоморф. Бу вакытта, шәхеснең эшчәнлекле культурасын (F1(A), F2(B), F3(C), F4(A,B), F5(A,C), F6(B,C), F7(A,B,C)) векторы рәвешендә карап була. Беренче якынайтуда функцияләрне болай тасвирларга мөмкин: F1(A)=A, F2(B)=B, F3(C)=C, F4(A,B)=A+B, F5(A,C)=A+C, F6(B,C)=B+C, F7(A,B,C)=A+B+C. Билгеле, болай эшләгәндә A, B, C күрсәткечләрен бәяләү критерийлары булдырылырга тиеш, аларны исә төрле тестлар, мәсьәләләр чишелешләре ярдәмендә бәяләп була [Галимьянов, Исмагилова]. Шулай итеп, биредә билгеләнгән җиде функция эшчәнлекле культураның җиде блогын күрсәтә:

1. Танып белү-мәгълүмати блок: (эрудиция һәм мәгълүмати сыйдырышлылык). Кеше күп төрле мәгълүмат ала, ул алардан кирәклесен сайлый алырга, аларны бәяләргә, истә калдырырга тиеш. Бу блок шәхеснең танып белү – формализацион сыйфатына изоморф.

2. Эмоциональ-бәһалы блок танып белү-мәгълүмати һәм конструктив-иҗади сәләтләрнең бинар композициясенә изоморф. Куллану-мотивацион блогы булып тора. Кеше, үзе өчен кыйммәтле булган мәгълүматны ала яисә алырга тырыша һәм бу юнәлештә эшли – иҗат итә.

3. Төзү-иҗади блок конструктив-иҗади сәләткә изоморф.

4. Ихтыяҗи-мотивацион блок танып белү – формализацион һәм башкаручанлык сәләтләренең бинар композициясенә изоморф. Хәзерге җәмгыятьтә ихтыяҗларның һәрчак яңаруы (артуы) һәм бу юнәлештә гамәлләр башкару гадәти күренеш.

5. Эшчәнлек блогы башкаручанлык һәм төзү-иҗади сәләтләрнең бинар композициясенә изоморф.

6. Башкаручанлык блогы башкаручанлык сәләтенә изоморф.

7. Үзреализация блогы барлык өч сәләтнең композициясенә изоморф, ягъни, шәхеснең үз-үзен реализацияләү тулаем аның танып-белү, төзү-иҗат итү, башкара алу сәләтләрендә чагылыш таба.

Хәзер исә мәгълүматлаштыруның шәхеснең эшчәнлек культурасына йогынтысын карыйк. Бөтен даирәләрне компьютерлаштыруның зур тизлек белән баруы, югары тизлекле интернет белән эшләү мөмкинлеге, хәзерге заман элемтә чараларының киң таралуы билгеле, уңай күренеш. Моннан ун гына ел элек бөтенләй күрелмәгән яңа мөмкинлекләр ачыла. Бөтендөнья компьютер челтәре аша аралашу – бу этапта җәмгыятьнең үсү юнәлешен чагылдыручы, кире кайтарылмаслык процесс. Бу процесс кысаларында социаль челтәрләр һаман да зуррак урын ала башлады.

Махсус контингент белән, ягъни, тәрбиягә авыр бирелүче яшүсмерләр, балигъ булмаган шартлы рәвештә хөкем ителгәннәр белән эш вакытында бу факторны исәпкә алу гына тү-

гел, аны тәрбияви максатлар өчен файдалану зарур. Шулай ук шартлы рәвештә хөкем ителгән балигъ булмаган яшүсмерләрнең җинаятьләрен кисәтү бик мөһим. Кисәтүнең гомумсоциаль чаралары шартлы рәвештә хөкем ителгән яшүсмерләрнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләре, халыкара актлар тарафыннан тәкъдир ителгән хокукларын торгызуга кайтып кала. Алар исә, кимендә, дүрт даирәне: гаилә-көнкүреш, мәгариф, яшүсмернең файдалы хезмәте һәм эшкә урнашуы, буш вакыт даирәләрен колачлый.

### Социаль челтәрләр һәм тәрбия

Җәмгыятьнең яшүсмерләрнең физик һәм психик сәламәтлеге турында кайгыртуы да бик зур әһәмияткә ия. Биредә телекоммуникация чаралары, шул исәптән социаль челтәрләр дә зур роль уйный ала; чөнки алар белән барлык яшүсмер диярлек файдалана. Социаль челтәрләр һәм аларны куллану даирәсен тирәнрәк карыйк.

«Социаль челтәр» термины информацион технологияләр өлкәсендә интерактив, күп кулланучыга исәпләнгән веб-сайтны белдерә, аның эчтәлеген файдаланучылар үзләре тутыра. Бу билгеләмә социологиядә кулланылучы билгеләмәдән аерылып тора. Анда исә социаль челтәр дип социаль объектлар һәм алар арасындагы элемтәләрне тәшкил итүче төеннәр төркеменнән торган социаль структура атала. Сайт исә автоматлаштырылган социаль мохиттан гыйбарәт, ул ниндидер уртак мәнфәгатьләр берләштергән кулланучыларга аралашырга мөмкинлек бирә.

Социаль челтәрнең төп принциплары түбәндәгедән гыйбарәт:

1. Идентификация. Үзең турында мәгълүматны (мәктәп, университет, туган көн, кызыксыну даирәсе (хобби), яраткан китаплар, җырлар, кинофильмнар һ.б.ш.) тәкъдир итә алу мөмкинлеге.
2. Сайтта булу, ягъни хәзерге мизгелдә сайтта кемнәр бар икәнлеген күрү һәм алар белән аралаша алу.
3. Мөнәсәбәтләр – кулланучылар арасындагы мөнәсәбәтләрне (дуслар, гаилә әгъзалары, дусларның дуслары һ.б.ш.) тасвирлый һәм тәкъдир итә алу.
4. Аралашу – челтәрнең башка кулланучылары белән аралашу (шәхси хәбәр җибәрү, куелган материалларга комментарийлар язу, ошау-ошамауны билгеләү (лайклар кую) һ.б.ш.) мөмкинлеге.
5. Төркемнәр – социаль челтәр эчендә мәнфәгатьләр буенча төркемнәр булдыру һәм аларга катнашу мөмкинлеге.
6. Репутация – башка кулланучының статусын белү, аның челтәрдәге гамәлләрен карап бару мөмкинлеге.
7. Алмашу – башка кулланучылар белән алар өчен әһәмиятле булган материаллар (фотографияләр, документлар, сылтамалар, презентцияләр һ.б.ш.) белән алмашу мөмкинлеге.

Социаль челтәрләрне биш төргә аерып була:

1. Эш эзләүчеләр, эш бирүчеләр өчен яисә аерым юнәлешләрдә эшләүчеләр өчен булган профессиональ социаль челтәрләр;

2. Блог-челтәрләр;

3. Танышу челтәрләре;

4. Кешеләрне эзләү өчен билгеләнгән челтәрләр.

5. Гомумсоциаль челтәрләр.

Махсус контингентның эшчәнлекле культура дәрәҗәсен күтәрергә, җәмгыятькә керү – социальләшү дәрәҗәсен арттырырга әзерлеген тикшерү өчен 3 шартлы төркем билгеләнде:

1. Югары мотивацион һәм интеллектуаль әзерлекле төркем. Кагыйдә буларак, алар авыр булмаган яисә саксызлык аркасында килеп чыккан җинаять эшләүдә гаепләнүчеләр. Мотивацион әзерлекләре һәм социаль адаптация өчен потенциаль мөмкинлекләре зур. Кагыйдә буларак, гаиләләре белән мөнәсәбәтләре сакланган. Төп белем дәрәҗәсе канәгатьләнерлек.

2. Уртача мотивацион һәм интеллектуаль әзерлекле төркем. Мотивацион эшчәнлек, гадәттә, эшчәнлектә ситуатив нәтиҗәгә ирешүгә юнәлдерелә.

3. Түбән әзерлекле төркем. Алар арасында наркотик кулланучылар да булырга мөмкин, бу исә аларның психофизиологик әзерлегенә тискәре йогынты ясый. Мотивацион һәм интеллектуаль әзерлек түбән. Социаль челтәрләргә кайвакытта кызык эзләү өчен генә керәләр. Социаль адаптация дәрәҗәләре түбән.

И.С. Кара хезмәтендә билгеләп үтелгәнчә, буш вакытны оешкан төстә, җәмгыятькә файдалы итеп үткәрү яшүсмерләр үсешенә уңай тәэсир итә, аларда яңа уңай мораль идеаллар һәм принциплар уята. Шуңа күрә шартлы рәвештә хөкем ителгән яшүсмерләрнең эштән һәм укудан буш вакытын аның шәхесенә уңай тәэсир булырлык итеп үткәрергә кирәк. Ләкин, буш вакытны оештырудан башка, аларны контрольдә тоту һәм кирәк булганда аларга ярдәм итү дә зарур. Чөнки нигә дә булса кызыксыну уятыр өчен башта ул юнәлештә аз булса да уңай нәтиҗәләргә ирешү лазем. Ә моның өчен, барыннан да бигрәк, яшүсмерне секциягә яисә мәнфәгатьләр буенча түгәраккә тартырга, аны кечкенә булса да бик мөһим җиңүгә китерергә кирәк. Файдалы эштә кечкенә генә җиңү зур җиңүгә – җәмгыятьнең позитив әгъзасы формалашуга китерәчәк [Кара, с. 242].

Шулай итеп, ирекле, ләкин кызыксындырып өйрәнүне контроль белән аралаштырып, девиант тәртипле яшүсмерләрне тәрбияләүдә уңай нәтиҗәләргә ирешеп була. Телекоммуникацион чараларны, шул исәптән социаль челтәрләрне дә махсус контингентны тәрбияләү максатында мондый юнәлешләрдә кулланырга була:

1. Мониторинг. Төркемнәр, дуслар, статуслар буенча карап, яшүсмернең кызыксыну даирәсен яисә аның башкаларга нинди булып күренергә теләвен билгеләргә мөмкин. Моннан соң, аны сиздермичә генә, танып белү-мәгълүмати юнәлеш буенча коррекцияләп була.

2. Челтәрдә турыдан-туры аралашу. Тәҗрибә күрсәткәнчә, кагыйдә буларак, махсус контин-

гент яшүсмерләренең аралашу ихтыяҗы бик зур.

3. Челтәр буенча сорашу, тест үткәрү.

Социаль сервисларда аралашу турыдан-туры аралашуга караганда берничә өстенлеккә ия. Болар: анонимлыкның югары дәрәҗәсе, тышкы факторлар булмау, физик агрессиянең мөмкин түгеллеге. Ә бу исә социализация дәрәҗәсе түбән булган затлар өчен бик мөһим. Бу факторлар яшүсмергә башка яклардан ачылырга, үзенең кызыксынуларын, хоббиен күрсәтергә, яисә, киресенчә, ул күрсәтергә теләмәгән якларын яшерергә мөмкинлек бирә. Бу яктан челтәрләр бик лояль һәм социаль юнәлешле. Шулай итеп, бу типтагы сайтлар затны хәзерге мизгелдә ничек яхшырак, шулай ачарга мөмкинлек бирә. Моннан тыш социаль челтәрләр уртак мәнфәгатьләрне табарга ярдәм итә. Социаль челтәрләрдә кеше үзенең кызыксынуларын белдерә, тиеш тапкан график, видео, аудиоматериаллар урнаштыра һ.б.ш. Шуңа күрә, социаль челтәрләрдән кешене башкача танып-белеп һәм аның белән аралашуны башка дәрәҗәдә дәвам итеп була.

## Йомгаклау

Хәзерге вакытта социаль челтәрләрнең махсус контингентка тәэсирен җентекләп тикшерү башланып кына килә. Ләкин башлангыч нәтиҗәләр инде бар. Аларны аерым-аерым, эшчәнлек культурасының һәр блогы буенча карыйк.

Танып белү-мәгълүмати блок буенча анык үсеш күзәтелә. Социаль челтәр мөмкинлекләрен файдаланып, яшүсмер күбрәк мәгълүмат ала һәм мәгълүмат белән эшләргә өйрәнә. Хезмәткәрләр тарафыннан һәр яшүсмергә хокукый мәгълүмат булган сайтлар күрсәтелде, аларны карап бару контрольдә тотыла.

Эмоциональ-бәһалы блок буенча шулай ук үсеш бар, һәр яшүсмер үзенә кирәкле мәгълүмат табарга өйрәнә.

Төзү-иҗади блок буенча аз гына булса да үсеш күзәтелә. Кайбер яшүсмерләр социаль челтәрләрнең хокукый битләреннән үзләренә кирәкле материалны җыеп ала алды.

Ихтыяҗи-мотивацион блок буенча шулай ук үсеш бар. Һәр кулланучы үзенә кирәкле мәгълүмат табу күнекмәләренә өйрәнә.

Эшчәнлек һәм башкаручанлык блоклары буенча прогресс күзәтелмәде.

Үзреализация блогы буенча үзгәрешләр бар, ләкин аны бәяләгәндә (башка блокларны бәяләгәндәге кебек үк) бик сак булу зарур.

**Искәрмә.** Безнең моннан алдагы эшләрдә (мәсәлән, [Галимьянов, Исмагилова]) культураның барлык блоклары үсеше уңай. Ләкин, контингентның үзенчәлеген исәпкә алсак, безнең очракта алар тискәре бәяләнергә дә мөмкин. Шулай итеп, мәсәлән, без нинди булса да блок буенча сыйфатны үстерү нәтиҗәсендә аны кирәкле юнәлештә кулланмаучы индивид килеп чыгарга мөмкин. Шуңа күрә модельләү һәм куллану вакытында бу исәпкә алынырга тиеш.

**Әдәбият**

*Айзенк Г., Кэмин Л.* Природа интеллекта – битва за разум. М.: ЭКСМО-Пресс, 2002. 352 с.

*Айсмонтас Б.Б.* Педагогическая психология. Схемы и тесты. М.: ВЛАДОС-ПРЕСС, 2002. 209 с.

*Галимьянов А.Ф., Исмагилова К.К.* Развитие математической культуры студентов, обучающихся на гуманитарных факультетах в вузе // Международный электронный журнал «Образовательные технологии и общество (Educational Technology & Society)». 2011. V. 14. № 1. С. 380–390. ISSN 1436–4522. URL: http://ifets.ieee.org/russian/periodical/journal.html

Деятельностная концепция культуры [Электрон ресурс]. Керү режимы: http://terme.ru/dictionary/858/word/dejatelnostnaja-koncepcija-kultury (мөрәҗәгать: 26.12.2015)

*Змановская Е.В.* Девиантология. Психология отклоняющегося поведения. М.: Академия, 2004. 288 с.

*Кара И.С.* Криминологическая характеристика и профилактика преступлений, совершаемых условно-осужденными несовершеннолетними: дис. ... канд. юрид. наук. Рязань., 2009. 242 с.

*Маклаков А.* Общая психология. [Электрон ресурс]. Керү режимы: http://www.gumer.info/bibliotek Buks/Psihol/makl/23.php (мөрәҗәгать: 26.12.2015)

*Николаенко И.Н.* Деятельностная интерпретация культуры как один из важнейших аспектов рассмотрения культуры. [Электрон ресурс]. Керү режимы: http://www.pglu.ru/lib/publications/University Reading/2009/XII/uch/2009/XII/00022.pdf (мөрәҗәгать: 26.10.2014)

*Нуриев Н.К.* Дидактическое пространство подготовки компетентных специалистов в области программной инженерии. Казань: Казан. ун-т, 2005. 244 с.

***Исмәгыйлева Кадрия Котдус кызы,***
*педагогика фәннәре кандидаты, доцент, Казан шәһәре Идел буе районындагы җәзаларны башкару Федераль казна оешмасы инспекторы*

УДК 372.881.512.145

*Л.И. Яруллина, Э.Р. Яруллина*

# Р.З. ХӘЙДӘРОВА ЭШЧӘНЛЕГЕНДӘ РУС ТЕЛЛЕ БАЛАЛАРГА ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘТҮ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

В статье рассматривается научно-исследовательская и методическая деятельность известного педагога, автора ряда учебников, методических разработок в области обучения русскоязычных учащихся татарскому языку Р.З. Хайдаровой. Оценивается вклад ученого-педагога в развитие национальной системы образования. Анализируются взгляды ученого на содержание и структуру учебников по обучению татарскому языку; на структуру урока; роль педагога в образовательной деятельности. Также рассматривается вопрос концепции коммуникативно-развивающего обучения на уроках татарского языка.

**Ключевые слова:** Р.З. Хайдарова, русскоязычные учащиеся, учебники татарского языка, цикл, методика обучения, учебно-методический комплекс.

Татар телен чит аудиториягә укыту юнәлешендә соңгы елларда зур эш башкарылды: уку-укыту методикасы зур үзгәрешләр кичерде, ул коммуникатив технологияләргә, техник чараларны актив куллануга йөз белән борылды. Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә әлеге технологияне уку-укыту процессына кертеп җибәрүнең чишмә башында торучыларның берсе – педагогия фәннәре кандидаты, халык мәгарифе отличнигы Хәйдәрова Роза Зәки кызы.

Роза Зәки кызы 1953 елның 26 августында Татарстанның Актаныш районы Теләкәй авылында дөньяга килә. 1969 елда – Теләкәй урта мәктәбен, 1973 елда Минзәлә училищесын бик яхшыга тәмамлый. 1978 елда Казан дәүләт университетында татар теле һәм әдәбияты укытучысы дигән белгечлек ала, ә 1984 елда исә Казан дәүләт педагогия институтының тарих факультетын да тәмамлый.

Укытучы-галимәнең фәнни-педагогик эшчәнлеге гаять киңкырлы. Ул хезмәт юлын Актаныш районы Теләкәй мәктәбендә (1978–1986), Мөслим районында (1986–1987) тарих, татар теле һәм әдәбияты укытудан башлап җибәрә. Алга таба Роза Зәки кызы – Татарстанның Чаллы шәһәре Автозавод районы мәгариф бүлегендә методист, Чаллы шәһәрендә укытучыларның өзлексез белем күтәрү институтында (ИНПО) милли мәгариф факультеты деканы (1992–1996), педагогика һәм психология кафедрасы мөдире, телләрне коммуникатив технология нигезендә өйрәнү лабораториясе мөдире (1988–1999), филология кафедрасы мөдире (2002–2010), доцент (2003), Яр Чаллы социаль педагогик технологияләр һәм ресурслар институтының «Рус телле балаларга татар теле укытуның теоретик һәм методик нигезләре» лабораториясе мөдире (2011).

Р.З. Хәйдәрова Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы тарафыннан почет грамоталары белән бүләкләнә (1991, 1998). 1994 елда аңа «Халык мәгарифе отличнигы», 2004 елда – «Татарстан республикасының атказанган укытучысы» исеме бирелә.

Р.З. Хәйдәрова – педагогика фәннәре кандидаты. 1999 елда «Коммуникатив принципларның рус телле укучылар өчен төзелгән татар теле дәреслекләрендә чагылышы» темасына кандидатлык диссертациясе яклый. 2002 елдан бүгенге көнгәчә Р.З. Хәйдәрова – ИНПОның филология кафедрасы җитәкчесе. 32 ел эш стажының 27 сен ул мәгариф өлкәсенә багышлый.

Роза Зәки кызы Яр Чаллы Өзлексез педагогик белем бирү институтының гыйльми советы, «Фән һәм мәктәп» журналы әгъзазы. Аның фәнни-педагогик эшчәнлегенең төп юнәлешләре булып рус телле балаларны татар теленә коммуникатив технология нигезендә өйрәтү буенча фәнни-методик тикшерү, шул юнәлештә укыту-методик комплектлар, методик әсбаплар әзерләү тора.

Роза Зәки кызының югары дәрәҗәдәге фәнни-методик эшчәнлеге, татар мәктәпләрендә укыту-тәрбия эшен тирәнтен белүе аңа милли мәгариф системасы үсешенә җитди өлеш кертергә мөмкинлек бирә. 1980 еллар ахырында Яр Чаллы шәһәренең Автозавод районы халык мәгарифе бүлегендә эшләү вакытында ул, беренче татар класслары ачу, аларны укыту-методик әдәбият белән тәэмин итү, бу тип мәктәпләр өчен педагогик кадрлар әзерләү белән җитәкчелек итә.

ИНПОның милли мәгариф факультетына Роза Зәки кызы килү белән Эльконин-Давыдовның үстерелешле (развивающий) укыту технологиясе, әдәбияттан А. Яхинның укыту методикасы, телләрне өйрәтүдә коммуникатив технология кебек инновацион педагогик технологияләрне кертү һәм куллану процессы башланып китә. Р.З. Хәйдәрова республикада беренче тапкыр «Рус телле укучыларны татар теленә өйрәтүнең психологик һәм педагогик нигезләре» дип исемләнгән 72 сәгатьлек махсус курс эшли. 1992 елдан ул укытучыларның иҗади төркемнәрен оештырып, рус балаларына татар телен өйрәтү буенча укыту-методик комплекслары төзү эшен башлап җибәрә. Р.З. Хәйдәрова – укыту-методик проблемаларга багышланган 42 хезмәт авторы.

Р.З. Хәйдәрова 1–7 нче сыйныфлар өчен УМК төзи. Әлеге комплекс үз эченә һәр сыйныф өчен дәреслек, укытучы өчен методик ярдәмлек, дәресләрнең тематик планын ала. Дәреслекләрнең нигезендә коммуникатив-үстерелешле концепция ята. Аларның эчтәлеге һәм оештыру нигезләре балаларның яшь үзенчәлекләренә, танып-белү эшчәнлегендәге кызыксыну даирәләренә, интеллектуаль үсешенә җавап бирә. Иң мөһим моментларның берсе шул: автор дәреслекләре балаларның фикер йөртү эшчәнлекләрен активлаштыра, укучыларга әхлакый тәрбия бирүдә мөһим роль үти.

Бүгенге көндә Р.З. Хәйдәрова тарафыннан төзелгән УМК буенча Казан шәһәренең шактый мәктәпләрендә укыталар, шулай ук Әлмәт, Алабуга, Чистай, Түбән Кама, Зәй, Менделеевск, Минзәлә, Яшел Үзән шәһәрләрендә дә Р.З. Хәйдәрова дәреслекләреннән теләп файдаланалар. Шулай ук, Роза Зәкиевнаның укытучыларның квалификациясен күтәрү буенча авторлык курслары төзүен, шул курслар нигезендә Татарстанның төрле районнарында, Самара, Ижевск, Санкт-Петербург шәһәрләрендә лекцияләр укуын да әйтеп үтәргә кирәк.

Р.З. Хәйдәрова дәреслекләреннән белем алган укучыларның тест, контроль эш, анкета, интервью нәтиҗәләре дә әлеге хезмәтләрне куллануның нәтиҗәсе зур булуы хакында сөйли.

Р.З. Хәйдәрова рус укучыларына татар әдәбиятын укыту буенча төзелгән программалар конкурсында да катнаша. Р.Л. Малафеева белән бергәлектә төзелгән әлеге программа ТР Мәгариф министрлыгы тарафыннан рус группаларында укыту өчен тәкъдим ителгән.

Галимә югары квалификацияле укытучы, аның тарафыннан «Инновацион педагогик технологияләр», «Белем бирүне яңарту һәм профильләштерү», «Хәзерге заман дәресенең дидактик аспектлары» дигән махсус курслар эшләнгән.

Р.З. Хәйдәрова уку-укыту проблемаларына багышлап шактый мәкаләләр яза. Соңгы дистә ел эчендә матбугат битләрендә авторның дәрес структурасы, дәресне анализлау, дәрестә укытучы шәхесе, уку-укыту процессында заманча технологияләр куллану, дәрес материалын үзләштерүдә метод һәм алымнарның эффектлылыгы проблемаларын яктырткан дистәләрчә мәкаләсе дөнья күрде. Галимә фикеренчә, «дәреснең бөтенлеген саклап, аны анализлый белү укытучыдан тирән белем, күнекмәләр, педагогик культуралылык таләп итә» [Хәйдәрова, 2004, б. 22].

Р.З. Хәйдәрованың татар телен укыту методикасына нисбәтле язылган хезмәтләренең үзәгендә торучы төп мәсьәләләрнең берсе – рус телле балаларны татар теленә өйрәтү дәресләре. Дәресне «төп тәрбия учагы» [Хәйдәрова, 2003, б. 70] буларак бәяләүче галимә мондый тип дәресләрне анализлауның да башка төр анализлардан әчтәлеге белән аерылып торуына басым ясый. Автор әлеге дәресләрне анализлауның төп критерийлары буларак «укучының чит телдә сөйләшергә өйрәнүен күзәтү; өйрәтү ысуллары, чараларының методик яктан камиллеген бәяләү, дәреснең психологик, дидактик яктан дөрес оештырылуын күзәтү» [Хәйдәрова, 2004, б. 22–23] һәм бәяләүне төп моментлар буларак билгели. Мондый тип анализлар, һичшиксез, укыту процессын оештыруның нәтиҗәлелеген күтәрә. Автор карашынча, «дәрес анализлауның максаты – укытучы эшендәге кимчелекле якларны эзләп табу түгел, бәлки дәреслекне ачыклап, аңа эшлекле ярдәм күрсәтү» [Хәйдәрова, 2004, б. 23]. Галимә шулай ук дәреснең психологик-педагогик яктан дөрес

оештырылуына, укучыларның иҗади фикерләү сәләте нинди алым һәм чаралар ярдәмендә үстерелүенә дә игътибар итәргә кирәклеген искәртә. Р.З. Хәйдәрова фикеренчә, укучыларга белем һәм тәрбия бирү, аларның сәләтен үстерү – педагогикадагы мәңгелек проблема [Хәйдәрова, 2003, б. 70].

Рус телле балаларны татар теленә өйрәтү дәресләре алдан уйланылган билгеле бер эзлекле структурага корылуны, системалылыкны, дәреснең эчтәлеген сайлауга проблемалы якын килүне таләп итә. Мондый дәресләрнең нигезендә, һичшиксез, коммуникатив технология ятарга тиеш. «Коммуникатив технологиянең иң югары өстенлеге – укыту процессында сөйләм материалын барлык балаларның да үзләштерә алуы өчен шартлар тудыру» [Хәйдәрова, 2003, б. 71]. Галимә карашынча, барлык укучыларның да уку эшчәнлегенә тартылуы өчен укыту процессы үзләштерү этапларын бозмыйча оештыру сорала, ягъни сөйләм материалын кабул итү, фикерләү, гомумиләштерү, аңлау, куллану этапларын саклау һәр бала белән индивидуаль эшләү мөмкинлекләре бирә. «Циклдагы дәресләрне оештыру дәвамында авыр фикерләүче балалар да материалны үзләштерү дәрәҗәсенә килеп җитә, шулай ук сәләтле балаларга да эш җитәрлек, укытучының үз укучыларының үзенчәлекләрен аңлап эш итә белү осталыгы гына кирәк [Хәйдәрова, 2003, б. 71].

Уку-укыту процессында иң үзәк элементларның берсе – дәреслек. Р.З. Хәйдәрова, Р. Малафеева кече яшьтәге мәктәп балалары өчен коммуникатив технология нигезендә төзелгән дәреслекләргә хас сыйфатлар буларак түбәндәгеләрне күрсәтәләр: кече яшьтәге укучылар өчен төзелгән дәреслекләр әкияти сюжетка корыла, дәреслектә дәресләр челтәре коммуникатив максат тирәсендә берләшә, грамматик кагыйдәләр функциональ төстә бирелә [Хәйдәрова, Малафеева, 2007, б. 33–34].

Р.З.Хәйдәрова уку-укыту процессын, методика һәм педагогика проблемаларын теоретик планда өйрәнүче генә түгел, ул, беренче чиратта, тәҗрибәле укытучы, дистәләгән дәреслекләр авторы. Р.З. Хәйдәрова үзенең дәреслекләрен циклик структурага кора, ә цикллылык коммуникатив технологиянең нигезендә ята.

Р. Хәйдәрова – рус һәм башка милләт балаларын татар теленә өйрәтү өлкәсендә актив эшләүче авторларның берсе. Ул 1–11 нче сыйныф укучылары өчен татар теле дәреслекләре төзи. Бу китаплар барысы да Р.З. Хәйдәрованың уку-укыту өлкәсендәге күпьеллык тәҗрибәсе нәтиҗәсендә язылганнар. Аның башлангыч сыйныфларга адресланган дәреслекләре коммуникатив принципка корылган: автор биремнәрне төрләндерергә, аларны кызыклы формада бирергә омтылган.

Р.З. Хәйдәрованың урта һәм югары сыйныфлар өчен төзелгән дәреслекләре тема төрлелеге белән аерылып тора. Автор башта текст тәкъдим итә. Аннары шул текстны ныгыту юнәлешендә эш алып бара. Мисал

өчен, текстка карата диалог төзү, сорауларга җавап бирү, диалогны рольләргә бүлеп уку һәм сәхнәләштерү кебек биремнәр тәкъдим ителә. Шул рәвешчә башта сөйләм күнекмәләрен формалаштыру этабы бара, аннары сөйләм күнекмәләрен камилләштерү өлеше башлана. Ахырда диалогик һәм монологик сөйләм буенча биремнәр карала. Р.З. Хәйдәрова дәресләр арасында тыгыз бәйләнеш сакларга, укыту процессын системалы һәм эзлекле, циклы алып барырга омтыла. Дәреслекләренең уңай ягы шунда: яңа текстны үзләштерүгә әзерлек 2–3 дәрес алдан башлана (текст алды этабы), аннары гына таныш сүзләр, сүзтезмәләр, җөмләләр өйрәнгән яңа текст бирелә (текст этабы). Текст белән танышудан соңгы этапта алган белемнәрне, әлеге текст нигезендә үзләштерелгән грамматик формаларны ныгытуга зур игътибар ителә. Бу башлангыч, 5, 6, 7 нче сыйныфлар өчен уңышлы алым.

Р.З. Хәйдәрова дәреслекләрендә урын алган текстлар укучының яшь үзенчәлекләрен, тәрбияви моментларны истә тотып сайланган. Автор дәреслекләрендә сөйләм күнекмәләрен формалаштыру һәм камилләштерү, диалогик һәм монологик сөйләмне үзләштерү этапларына җитди һәм системалы якын килә. Текст белән эш, бәйләнешле сөйләм үстерү көчле куелган. Гомумән, Р.З. Хәйдәрова төзегән дәреслекләр укытучылар тарафыннан бүгенге көндә иң уңышлы дәреслекләрнең берсе итеп бәяләнә.

Бүгенге көн уку-укыту системасы Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү чорын кичерә. Әлеге шартларда белем бирүнең «төп үсеш юнәлеше – системалы-эшчәнлекле юнәлеш, ә системаны барлыкка китерә торган төп компонент – нәтиҗә: шәхси, метапредмет, предмет нәтиҗәләре дип билгеләнә» [Хәйдәрова, Әхмәтҗанова, 2015, б. 3]. Р.З. Хәйдәрова фикеренчә, татар теле һәм татар әдәбияты укытуның дәрәҗәсен саклыйк дисәк, кичекмәстән, бала шәхесенә ориентлашкан, аның теләп укуын һәм укый алуын тәэмин итә ала торган педагогик технологияләрне өйрәнү, аны компьютер технологияләренә салып, укыту процессына кертүне оештыру кирәк [шунда ук, б. 4]. Р.З. Хәйдәрова бу уңайдан Чаллы социаль-педагогик технологияләр һәм ресурслар институты эшчәнлеген мисал итеп китерә. Монда Л.В. Занковның дидактик системасы, Эльконин-Давыдовның үстерелешле укыту технологиясе, А.З. Рәхимовның иҗади үсеш технологиясе, А.Г. Яхинның әдәбият укыту системасы, Е.И. Пассовның коммуникатив технологиясе, коллектив ысул белән укыту системалары педагогик процесска тәкъдим ителә [шунда ук, б. 5].

Р.З. Хәйдәрованың Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ә. Гыйниятуллина белән берлектә рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар телен өйрәнүчеләр өчен төзелгән һәм «Күңелле татар теле» сериясе астында дөнья күргән дәреслекләре – бүгенге көндә иң актив кулланылучы уку

әсбапларының берсе. Бу дәреслекләр Е.И. Пассовның коммуникатив технология концепциясенә нигезләнгән. Әлеге зур форматлы, матур дәреслекләргә, белем һәм күнекмәләрне ныгыту максатыннан, эш дәфтәрләре дә төзелгән. Укытучыга ярдәмгә методик кулланмалар да эшләнгән. Алар барысы бергә рус телле балаларны татар теленә өйрәтүне максат итеп куйган УМК тәшкил итәләр. Үзләренең төп максатларын авторлар «телне аралашу чарасы буларак үзләштерүне тәэмин итү, көндәлек тормышта, полиэтник җәмгыятьтә үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек итү күнекмәләрен формалаштыру» дип билгелиләр. Татар телен дәүләт теле буларак укыту – укучыларны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү, аларның аралашу культурасын формалаштыру, башка халыкларга карата хөрмәт хисе, мәдәниара диалогка осталык кебек универсал күнекмәләр булдыру чарасы, дигән караштa торалар [Хәйдәрова, Гыйниятуллина, Газизуллина, б. 3].

«Күңелле татар теле» сериясендә дөнья күргән УМКларның беренчел максаты – укучыларда коммуникатив компетенция формалаштыру. Бу әсбаплар телне аралашу аша, актив фикерләп өйрәнү, укыту процессын шәхси индивидуальләштерү, телне функциональ төстә өйрәнү кебек принципларга корылганнар. УМК өчен материал укучыларның яшь үзенчәлекләрен, аларның аралашу даирәләрен исәпкә алып сайланган.

Р.З. Хәйдәрова бүгенге көндә дә уку-укыту процессы, белем бирүне камилләштерү, хәзерге заман дәресенең педагогик-психологик, методик, технологик аспектлары һәм башка бик күп юнәлешләрдә эшләвен, эзләнү-тикшеренүләрен дәвам итә. Галимәнең татар мәгарифе өлкәсенә керткән өлеше, һичшиксез, зур бәягә лаек һәм ул алга таба эзләнү-тикшеренүләр өчен дә ныклы нигез булып тора.

**Әдәбият**

*Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗанова Т.М.* Федераль дәүләт белем бирү стандартларына күчү шартларында татар теле һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту. Яр Чаллы, 2015. 52 б.

*Хәйдәрова Р.З.*Укучыларның фикерләү сәләтен үстерик // Мәгариф. 2003. № 8. Б. 70–71.

*Хәйдәрова Р.З., Малафеева Р.Л.* Коммуникатив технология нигезендә төзелгән татар теле дәреслекләре // Фән һәм мәктәп. 2007. № 12. Б. 33–35.

*Хәйдәрова Р.З.*Дәрес анализлау // Мәгариф. 2004. № 5. Б. 22–23.

*Хәйдәрова Р.З., Гыйниятуллина Л.Ә., Газизуллина Г.И.* Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту. 3 нче сыйныф: укытучылар өчен методик кулланма. Казан: Татармультфильм, 2013. 80 б.

*Хайдарова Р.З., Гиниятуллина Л.А.* Книга для родителей. В помощь родителям русскоязычных учащихся 1–2 классов по изучению татарского языка. Казан: Татармультфильм, 2012. 60 с.

*Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М., Гыйниятуллина Л.Ә.* Татар теле. 4 сыйныф: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 2 кисәктә. Казан: Татармультфильм, 2014. 1 нче кисәк. 152 с.: рәс б-н.

*Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М., Гыйниятуллина Л.Ә.* Татар теле. 4 сыйныф: рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). 2 кисәктә. Казан: Татармультфильм, 2014. 2 нче кисәк. 128 с.: рәс б-н.

*Хәйдәрова Р.З., Әхмәтҗанова Г.М.* Татар теле. 5 сыйныф: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен). Казан: Татармультфильм, 2014. 128 с.: рәс б-н.

*Хайдарова Р.З., Малафеева Р.Л.* Татарский язык. 8 класс: учебник для образовательных организаций основного общего образования с обучением на русском языке (для изучающих татарский язык). Казань: Татармультфильм, 2015. 96 с.

***Яруллина Ләйсән Илсур кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге өлкән фәнни хезмәткәре*
*e-mail: liysan-jarullina@mail.ru*

***Яруллина Эльза Равил кызы,***
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*e-mail: ravilevna3008@yandex.ru*

УДК 792.075=512.145

*М.Г. Арсланов*

## ГАБДУЛЛА КАРИЕВ – «ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ АТАСЫ»

Статья посвящена жизни и творчеству драматурга, актера, режиссера, основателя профессионального татарского театра Габдуллы Кариева.

**Ключевые слова:** Габдулла Кариев, татарский театр, режиссерское искусство, труппа «Сайяр», актерство, школа Г. Кариева, репертуар.

Татар театр сәнгате – XX гасыр дөнья мәдәниятенең тирән игътибарга лаеклы аерылгысыз өлеше. Быел аңа 110 ел тула. Төрки телле халыклар сәнгатендә иң беренчеләрдән диярлек барлыкка килгән бу театр бүген инде бай тарихы, зур казанышлары, олуг шәхесләре белән дөньяга танылды. Халкыбыз хаклы рәвештә горурлана ала: татар театры һәрвакыт гомумкешелек кыйммәтләрен алга куйды, демократик идеяләргә хезмәт итте. Аның сәхнәсеннән бервакытта да милли дошманлык, сугыш, конфронтация идеяләре пропагандаланмады, шәхес ирегенчикләү, кысу, кыерсыту, шулай ук көч культы, порнография, җенси азгынлык кебек түбән омтылышлар макталмады. Әгәр милли сәхнә сәнгате халык өчен чын мәгънәсендә тәрбия мәктәбе булып үскән, үзенең эшчәнлеге, ирешкән казанышлары белән дөньякүләм танылу алган икән, бу уңышларда, һичшиксез, татар театрының атасы, режиссер һәм актер Габдулла Кариевның да өлеше гаять зур.

Габдулла Хәйрулла улы Кариев (Миңлебай Хәйруллин) элеккеге Чистай өязе Колбай Мораса авылында 1886 елның сигезенче (яңа стиль белән егерменче) маенда дөньяга килә. Унике яшенә кадәр туган авылында белем алганнан соң, 1896 елдан күрше Такталы авылы мәдрәсәсендә укый башлый. Гаҗәеп сәләтле, зирәк, унике яшендә ук Коръәнне яттан белгән шәкерткә Такталы мәдрәсәсе мөдәррисе Зариф мулла: «Мужик исеме йөртмәсен», – дип, Габдулла исеме бирә. Шуннан соң Миңлебай Хәйруллин халык арасында Габдулла карый булараk танылa.

Такталы мәдрәсәсен 1904 елда тәмамлаганнан соң, Габдулла Уральск шәһәрендәге мәдрәсәгә укырга керә. Биредә ул Габдулла Тукай, Камил Мотыйгый-Төхфәтуллин кебек заманның күренекле шәхесләре белән таныша һәм аралаша. Ә 1907 елда Габдулла Түбән Новгород шәһәрендә «Сәйяр» артистлары белән очраша һәм тормышын мәңгегә татар театры белән бәйли. 1911 елның декабрь аеннан, ягъни «Сәйяр» труппасы Шәрык клубына штатка алынганнан соң, Габдулла Кариев гомеренең

ахыргы көннәренә кадәр Казанда яши.

Татар театр сәнгате турындагы күп кенә хезмәтләрдә, газета-журнал мәкаләләрендә, мәдәният әһелләре арасындагы сөйләшүләрдә «Кариев мәктәбе», «Кариев традицияләре», «Кариев мәктәбе традицияләре» кебек сүзләр шактый еш кулланыла. Шулай күп кабатланса да, бүгенгә кадәр бу тәгъбирне һәркем үзенчә аңлый. Чөнки Кариев мәктәбенең принциплары, үзенчәлеге, закончалыклары турында әлегәчә язылганы булмады. Дөрес, кайбер хезмәтләрдә Г. Кариев традицияләренә кагылган фикерләр әйтелә, аерым үзенчәлекләре күрсәтелә. Әмма алардан чыгып кына Кариев мәктәбен тулы күзаллау, аның төп сыйфатларын, үзенчәлекле якларын тану мөмкин түгел.

Габдулла Кариев – театр сәнгатенең төрле өлкәләрендә мәктәп тудырган шәхес. Шуңа күрә гомумирәк булган «Кариев мәктәбе» терминын «Кариевның актерлык мәктәбе», «Кариевның режиссура мәктәбе» кебек төшенчәләргә бүлеп карау дөресрәк булыр.

Татар актер кадрларын үстерү, милли башкаручылык мәктәбе тудыру – театр сәнгате үсешенең беренче бишьеллыгында Г. Кариев үтәгән төп бурычларның берсе булып тора. Милли театр труппалары дөньяга килү белән үк, аның үзәгендә тормыш дөреслеге, хис, кичереш дөреслеге принципларына нигезләнгән реалистик сәнгать үсә башлый. Татар театрының әйдәп баручы иң көчле артистларның берсе буларак бу юнәлешне Г. Кариев үзе җитәкли. Әлбәттә, аңа бик җиңел булмый. Чөнки ул да тигезләр арасында беренче генә, аның да башкалар шикелле үк махсус театраль белеме юк. Әмма шулай булса да, табигать тарафыннан бирелгән олы талант, зур тырышлык, аналитик акыл, армый-талмый үз өстендә эшләү үзенекен итә. Нәтиҗәдә, театр сәнгате өлкәсендә тиңдәше булмаган бөек шәхес тәрбияләнә.

Киң җәмәгатьчелеккә Г. Кариев иң элек актер сыйфатында танылa. Г. Камал, Г. Исхакый, Я. Вәли әсәрләрендә «Сәйяр» труппасы эшчәнлегенең беренче елларында ук ул иҗат иткән Кәрим («Бәхетсез егет»), Хәмзә («Беренче театр»), Әхмәтҗан («Бүләк өчен»), Мөхәммәтҗан Хафиз («Безнең шәһәрнең серләре»), Сиражетдин Туктагаев («Банкрот»), Закир («Мөгаллим»), Садыйк бай («Оят яки күз яше») кебек образлары аны тиз арада татар сәхнә сәнгатенең иң алдынгы сафларына алып керә, милли характерлар остасы итеп таныта. Аларда Г. Кариевның драматик таланты, көлкеле персонажлар тудыру мөмкинлекләре ачыла. Ә инде Надиршаһ (Н. Нәриманов, «Надиршаһ»), Городничьи (Н. Гоголь, «Ревизор»), Президент (Ф. Шиллер, «Мәкер һәм мәхәббәт»), Әлмансур (Г. Гейне, «Әлмансур») кебек дөньякүләм танылган рольләрне башкарып артист үзенең киң колачлы, иркен сулышлы, масштаблы трагик образлар тудыра алуын исбатлый. Аның иҗат офыклары шулкадәр киң ки, хәтта аны чикләрдәй роль бөтендөнья классик драматургиясе мирасын

тулысынча барлап чыкканда да табылмас кебек тоела.

Татар театры туган елларда Г. Камал иҗатының чәчәк атып килгән чагы. Шушы ук чорда Г. Исхакый, Г. Коләхмәтов, Ф. Халиди, Я. Вәли кебек әдипләрнең дә яңа әсәрләре бер-бер артлы язылып тора. Көндәлек тормыштан алынган вакыйгаларны, прототипларын урамда очратырга мөмкин булган геройларның уй-кичерешләрен, хис-хыялларын сурәтләгән көнкүреш драмаларын сәхнәләштерү реалистик алым куллануны, тормыш дөреслеге саклануны сорый. Шушы ук вакыт аралыгында, хәтта бераз алдарак та, Н.В. Гогольнең, А.Н. Островскийның, А.П. Чеховның аерым әсәрләре татар теленә тәрҗемә ителә башлый. Милли әдипләрнең пьесалары һәм рус классик драматургиясе үрнәкләреннән төзелгән репертуар татар режиссура сәнгате үсешенең беренче чорында нигез хезмәтен үти.

Тәүге чорда бердәнбер профессиональ «Сәйяр» труппасы күчмә хәлдә яши. Әлегә труппаның режиссеры Г. Кариевның даими эш урыны да юк, спектакльне әзерләү өчен шартлары да җитәрлек түгел. Репетицияләр тимер юл вагоннарында, кунакханә бүлмәләрендә үткәрелә. Труппаның үз декорацияләре дә, аерым образларга атап тегелгән киемнәре дә, әзерләнгән бутафорияләре дә, реквизитлары да юк. Спектакльләр урындагы әзер декорацияләрдән сайлап җиһазландырыла. Артистлар үз киемнәрендә уйныйлар. Мондый шартларда костюмнарның ансамбльлеге, яктырту, музыка, театраль шау-шулар куллану турында уйлау да мөмкин түгел. Шуңа күрә Г. Кариев бар көчен, энергиясен артистлар белән эшләүгә, аларны сәхнә хадимнәре итеп тәрбияләүгә, иҗатларын киңәйтү-үстерүгә юнәлтә. Г. Кариев татар режиссурасы үсешенең беренче этабында әйтәсе фикерләрен сәхнәнең төрле сурәтләү чаралары, аерым режиссура алымнары кулланып түгел, бәлки бары тик артистлар уенына гына таянып тамашачыга җиткерә.

Мәскәү художество театрының әхлак принципларын эшләгән К.С. Станиславский кебек үк, Г. Кариев артистларда югары гражданлык, әхлаклылык сыйфатларын тәрбияләү эшен даими алып бара. «Татар театры атасы» салган әнә шул нигездә халыкның яңа сәнгате төзелә. «Артист өчен театр – тормыш мәгънәсе!» Үзенең көндәлек тәрбия эшендә Г. Кариев менә шушы девизны маяк итеп ала. Аңа үз һөнәрен бөтен нечкәлекләренә кадәр белгән, җәмгыять алдындагы югары миссияне аңлаган иҗатчылар кирәк була. Ачлык, ялангачлык, бертуктаусыз янау, куркыту шартларында труппа эшен дәвам иткән Г. Кариев сәнгать өчен үз-үзләрен аямый торган, авыр, ләкин мактаулы хезмәтләренең халыкка кирәклеген тойган артистлар тәрбияләү максатына ирешә. «Татар театры атасы»-ның шушы юнәлештәге системалы хезмәте нәтиҗәсе буларак, «Сәйяр» труппасында бик көчле артистлар үсеп чыга. Башка беркем дә булдыра алмаганча кеше-

нең талантын күрә белгән, даими эзләнүдә булган, халык арасыннан талантлы шәхесләрне табып труппага җәлеп иткән Г. Кариевның нәкъ менә реалистик театр актерларын, сәхнәдә «кеше рухының тормышын» гәүдәләндерә алырга сәләтле психологик портрет осталарын тәрбияләве гаять мөһим. Аның тынгысыз кайгыртучанлыгы нәтиҗәсендә татар театры чагыштырмача тиз арада С. Гыйззәтуллина-Волжская, Г. Болгарская, Ф. Ильская, Н. Таждарова, Н.Арапова, К. Тинчурин, З. Солтанов, К. Шамил, Камал I, Камал II, Г. Мангушев кебек тиңдәшсез актерлар йолдызлыгына әйләнә һәм алар уйнаган күп кенә спектакльләр, бизәлеше һәм костюмнары ярлы булуга карамастан, реалистик режиссураның төп таләбенә – ансамбльлелеккә җавап бирә иде.

Татар режиссурасы үсешендә Г. Кариев чишкән иң зур проблемаларның беренчесе – нәкъ менә үз профессиясенең бөтен нечкәлекләренә кадәр төшенгән артистлар тәрбияләү, хис-кичереш дөреслегенә, табигыйлеккә, гадилеккә, тормышчанлыкка нигезләнгән башкару мәктәбе тудыру. Ул хәл иткән икенче зур мәсьәлә – психологик реализм театры принципларына нигезләнеп, тирән, игътибарлы тынлыкка һәм «дүртенче стена» артында барган вакыйгаларга теләктәшлек күрсәтергә сәләтле милли тамашачы тәрбияләү. Мондый проблема театр эшлеклеләре алдында театр барлыкка килгән көннән үк тора. Алдынгы идеяләрне пропагандалау мәсләген тоткан театр үзенең эшчәнлеген прогрессив зыялыларга, киң катлам демократик публикага юнәлдерә һәм ялгышмый.

Икенче мәсьәлә белән өченчесе дә тыгыз бәйләнгән. Монысы заманча спектакльләр тудыру, аларны куюу принципларын булдыру һәм урнаштыру. Ислам дине кагыйдәләрендә тәрбияләнгән тамашачы массасын, аның күңеленең иң нечкә кылларына кагылып, заманның иң кискен проблемаларын күтәреп кенә театрга җәлеп итәргә мөмкин иде. Шуңа күрә дә заман темаларына куелган спектакльләрнең төп үзенчәлекләре актуальлек, көндәлек тормыштан алынган материалга таяну булды. Реалистик театр игълан иткән чынбарлыкны «тормышның үз формалары» ярдәмендә чагылдыру принцибы киң катлам публиканың театрга килүен тәэмин итте дә инде.

Шулай итеп, заманча спектакльләр тудыру проблемасы – беренче этапта Г. Кариев чишкән зур проблемаларның өченчесе. Шуңа күрә дә «Сәйяр»нең 1907–1911 еллардагы репертуарын җентекләп караганда, заман темасын яктыртмаган спектакльләр анда бик аз табылыр. Бу чорда тәрҗемә әсәрләр чагыштырмача сирәк куела. Куелганнарының да күбесе татарның үз тормышына яраклаштырып, «түбәтәй кигертеп» сәхнәләштерелә. Заман темасына багышланган спектакльләр проблемасын чишүнең төп юлын Кариев милли драматургияне үстерүдә күрә һәм игътибарын шуңа юнәлтә. Бу очракта да режиссер хаклы булып чыга. Замандашлары Г. Камал, Г. Исхакый, Я. Вәли

кебек авторларның пьесалары нәкъ менә режиссер күзаллаганча, халыкка аңлаешлы, күңелгә якын, сәхнәгә кую өчен уңай булалар. Татар режиссурасы үсешенең беренче чорында бу авторларның әсәрләрен күбрәк сәхнәләштерү һич тә очраклы түгел һәм әлеге әсәрләр турыдан-туры тормыш тәңгәллекләре театры принциплары нигезендә уйналалар да. Г. Кариев куйган «Бәхетсез егет» (Г. Камал), «Ачлык кушты» (Я. Вәли), «Низамлы мәдрәсә», «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин» (С. Рәмиев) кебек спектакльләрдә вакыйгалар «бүген, хәзер, монда», тамашачылар күз алдында үтә торган чын тормыш күренешләре тәэсирен калдыралар. Аларда труппа тормышның үзенә мөмкин кадәр якын килергә, төп-төгәл «тормыш кисәге» репродукциясен күрсәтергә омтыла. Тамаша драма сайлап алган чынбарлык фрагменты барышында булган барлык вакыйгаларны «тормышның үз формалары» ярдәмендә имитацияли. Биредә информация ни кадәр дөресрәк, ни кадәр нечкәрәк – шул кадәр яхшырак. Ә актерларның бурычы – пьесадагы герой кичергәннәрнең барысын да мөмкин булган кадәр йөрәгең аша үткәрү.

Спектакльләр барышында әйләнә-тирәдәге чынбарлыктан алган күзәтүләрне Г. Кариев билгеле бер идея концепциясенә буйсындыра һәм аларны эстетик яктан оештыра. Ә иҗат ителгән образлар табигате, характерлар төрлелеге, башкаручы актерның шәхси тәҗрибәсе тирәнлегенә, режиссерның сурәтләнгән тормышны ни кадәр яхшы белүенә бәйле. Алда билгеләп үтелгәнчә, тормышчан театрда иң мөһиме – чынбарлыкны дөрес, төгәл гәүдәләндерү, аңа мөмкин булган кадәр якын килү. Нәкъ менә шушы принципны төгәл саклаганга күрә дә Г. Кариевның иң яхшы спектакльләрендә барысы да «тормыштагыча» була. Рампа янында күзгә күренми торган «дүртенче стена» үсеп чыга, ә аның артында тормыш үзе – театр шартлылыгыннан азат тормыш бара. Табигать күренешләрендә сәхнә мәйданы киң, офыкка кадәр сузылган, бүлмәләр, кешеләр яши торган өйләр шикелле уңайлы, акшарланган мичләр җылы булып күренү зарур. Тәрәзәгә яңгыр бәреп яварга, морҗада җил уларга мөмкин һ.б. Шундый детальләрдән, төсмерләрдән тере сәхнә атмосферасы барлыкка килә. Монда, аерым төсле таплардан, сызыклардан, нокталардан төзелгән сурәтләрдәге кебек, бөтен нәрсә, әйтерсең, үзара бәйләнеп бара: актерның салынган иңбашлары, ярым ачык ишектән саркылган яктылык, идәнгә ташланган уенчык, җилнең морҗада эчпошыргыч улавы – барысы да гомуми атмосферага «хезмәт итә», бердәй рухта була, төгәллек хисе тудыра.

Югарыда китерелгән тасвирламаниндидер бер аерым спектакльдән түгел. Бу – Г. Кариев спектакльләренең гомумиләштерелгән образы. Ул Кариев театрында бердәм рухтагы тулы күренеш оештыруда һәр көнкүреш детале, һәр сәнгать чарасы нинди әһәмияткә ия икәнлеге,

«кеше рухының тормышын» сәхнәдә гәүдәләндерүче актерның алар белән ничек бәйле булуы турында сөйли.

Революциягә кадәр Г. Кариев җитәкләгән татар театры башлыча реалистик театр, турыдан-туры тормыш тәңгәллекләре сәнгате буларак үсте дип билгели алабыз. Башыннан ук ул реалистик драматургиягә, яшәешне «тормышның үз формаларында» чагылдырган драматургиягә нигезләнде. Шул вакытта ук дөнья сәхнәләрен яулап алырга өлгергән Л. Андреев, М. Метерлинк, Г. Гауптман, Г. Ибсен, К. Гамсун, А. Блок һәм башкаларның символик драмалары әлегә күптән түгел генә барлыкка килгән милли театр эшлеклеләре өчен буй җитмәслек югарылыкта иде. Ә татар драматургиясендә шартлы-метафористик театр алымнарын кулланып язылган бердәнбер әсәр – Г. Колахметовның «Ике фикер» пьесасы, патша цензурасының тыюы нәтиҗәсендә, сәхнәгә барып җитми. Шулай итеп, милли драматургия сәхнәне шартлы театр идеяләре белән туендыра алмый, ә яшь режиссура әлегә мондый проблемаларны мөстәкыйль хәл итәргә әзер булмый. Бу шартларда «татар театрының атасы» Г. Кариев сайлап алган реалистик сәхнә сәнгате моделендә үсү юлы тулысынча мантыйклы һәм закончалыклы була. Шуңа да милли режиссерларның революциягә кадәрге чорда хәл иткән барлык мәсьәләләре тормышчанлык театры, психологик реализм принциплары белән тыгыз бәйле була.

1911 елның декабрь аеннан «Сәйяр» труппасы Шәрык клубы штатына алына. Шушы вакыттан татар театры үсешенең икенче этабы башлана. Штатка алу – гастрольләрдә йөргәндә артистларга даими эш хакы түләнү, иҗат өчен өстәмә мөмкинлекләр ачу гына түгел, бәлки татар режиссурасы, гомумән, татар театр үсешенә яңа шартлар булдыру дигән сүз дә. Ниһаять, режиссер Г. Кариевның да даими эш урыны була, репетицияләр гел бер урында уздырыла, нәтиҗәдә, спектакльләрнең сыйфаты яхшырганнан яхшыра бара. Инде җәмгыять тарафыннан шактый танылу алган милли театр режиссураның сәнгать чараларын үзләштерүне дәвам итәргә мөмкинлек ала. Акрынлап аның спектакльләренә музыка килеп керә, герой белән аның әйләнә тирәсендәге «әйберләр дөньясы»ның бәйләнеше арта. Тиздән һәр постановканы үзенчә, аерым бизәү гамәлгә кертелә. Ансамбльлелек таләпләренә сәхнә костюмы да буйсындырыла. Шул рәвешчә, татар сәхнә сәнгате яңадан-яңа режиссура чараларына байый. Милли сәхнәләштерү сәнгате үсешенең икенче чорында татар театрының репертуары сизелерлек киңәя. Г. Камал, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, К. Тинчурин, И. Богданов, Ф. Сәйфи-Казанлы кебек чордаш драматургларның ул вакытта еш куелган әсәрләре белән беррәттән, сәхнәгә чит ил һәм рус авторларының пьесалары да чыга. Революциягә кадәр булган өч труппада – «Сәйяр», «Нур», «Ширкат» труппаларында А.Н. Островский, Ф. Шиллер, Ж.-Б. Мольер, Н.В. Гоголь, С. Найденов һ.б.ларның әсәрләре

куела. 1912 елда «Сәйяр»гә Г. Кариев чакыруы буенча татар театрының беренче рәссамы Сабит Яхшыбаев килә. Хәзер инде Г. Кариевның реалистик режиссурасы спектакльләрнең тулы бөтенлегенә омтыла.

1912–1915 елларда татар театрының тагын ике труппасы – «Нур» һәм «Ширкәт» төзелә. Татарның беренче артисткасы С. Гыйззәтуллина-Волжская, соңрак Ш. Шамильский һәм М. Мутиннар да режиссерлык эшенә алыналар. Әмма «Сәйяр» труппасы җитәкчесе Г. Кариев бу өлкәдә үзенең беренчелеген саклый.

Татар режиссурасы үсешенең икенче чорында зур классик драма үрнәкләрен сәхнәләштерү проблемасы туа. Бу мәсьәләгә үтә җитди якын килеп, үз иҗатына соң дәрәҗәдә таләпчән Г. Кариев дөнья классикасы әсәрләрен кую өчен рус режиссерларын чакыруны кагыйдә итеп ала. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1913–1917 елларда «Сәйяр»дә П. Громов, Н. Михаленко кебек режиссерлар эшли. Репертуардагы бу зур үзгәреш Г. Кариев иҗатын яңа алымнарга, сурәтләү чараларына баета. Шушы ук чорда Г. Кариев режиссура мәктәбенең төп принциплары формалаша.

Сәнгатьтә реалистик юнәлеш тарафдары Г. Кариев сәхнәдә тормыш вакыйгаларын бөтен байлыгы, тулылыгы белән күрсәтүгә омтыла. Шуңа күрә ул куйган спектакльләрдә сәхнә бизәлеше һәрвакыт тормыш дөреслеге принцибына туры килә. Труппага С. Яхшыбаев кабул ителгәч, дежур декорацияләрдән котылып, һәр спектакль өчен махсус бизәлеш әзерләргә мөмкинлек туа.

Сәхнә бизәлешенең нинди булуына карамастан, Г. Кариев иҗатының барлык чорларында да сәхнәдә гәүдәләндерелгән геройларның эчке дөньялары игътибар үзәгенә куела.

Озак еллар Г. Кариев «Сәйяр»нең җитәкчесе һәм сайлап куелган директоры, ә В. Мортазин-Иманский режиссеры булып исәпләнәләр. Шулай булса да труппада төп режиссерлык эшен Г. Кариев алып бара. Алар башкарган вазифаларны, бүгенге көнгә күчергәндә, баш һәм чираттагы режиссерлар эшенә тиңләп булыр иде.

Татар театрының милли драматургиядән башка үсүе мөмкин түгеллеген яхшы аңлаган Г. Кариев репертуарга татар әсәрләрен күбрәк кертүгә зур игътибар бирә. «Сәйяр» труппасы үсешенең беренче бишьеллыгында язылган милли пьесалар аның репертуарга ихтыяҗын тулысынча диярлек канәгатьләндереп килә. Ләкин труппа даими эш урыны белән тәэмин ителгәч һәм «Нур», «Ширкәт» труппалары да төзелгәч, татарча пьесалар җитмәү нык сизелә башлый. Атна саен куелган спектакльләр өчен яңадан-яңа әсәрләр кирәк була. Бер үк пьесаларның төрле труппаларда уйналуы да аларның матди хәлен яхшыртуга алып бармый. Бу хәлдән чыгу юлын эзләп, режиссер, моңарчы куелырга рөхсәт булмаган барлык әсәрләрне туплап (алар барысы егерме икегә җыела), матбугат эшләре идарәсенә җибәрә. Шушы пьесаларны куярга рөх-

сәт сорап, гариза да яза. Шулай акрын-акрын татар театры репертуары Г. Камалның «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре», Ф. Әмирханның «Яшьләр», «Тигезсезләр», М. Фәйзинең «Галиябану», К. Тинчуринның «Соңгы сәлам», «Беренче чәчәкләр» кебек сәнгатьчә эшләнеше ягыннан югары әсәрләр белән тулылана.

Г. Кариев татар халкының күп кенә танылган драматурглары белән тыгыз элемтәдә була, кемнең нинди әсәр язуын, пьесаның чама белән кайчанрак тәмамланасын алдан белеп тора. Тормышта очраган кызыклы характерлар турында драматургларга сөйли, яңа темалар күрсәтә. 1914 елның бишенче гыйнварында «Йолдыз» гәзите аның «Милли театр хакында» исемле шактый күләмле мәкаләсен бастыра. Бу хезмәтендә автор милли драматургларның азлыгы, алар иҗатына тиешле игътибар, рухи һәм матди ярдәм кирәклеге турында яза.

Башка шәһәрләрдә яшәүче драматурглар да аның игътибарыннан читтә калмый – ул алар белән дә хәбәрләшеп тора. Әгәр нинди дә булса әсәрнең уңыш белән баруы ишетелсә, шунда ук авторга хат белән мөрәҗәгать итә. Җибәрелгән пьеса Г. Кариевны канәгатьләндерсә, ул репертуарга кертелә. Г. Кариевның Ш. Камалга «Хаҗи әфәнде өйләнә» комедиясен куярга рөхсәт биргәне өчен рәхмәт юллап, пьесаны көтеп калуын әйтеп язган хаты сакланган. Шундый ук хат алышу М. Фәйзи белән дә булганлыгы билгеле.

1917 елның җәендә пьесалар кытлыгын бетерү өчен Г. Кариев халык тормышыннан алынган пьесаларга конкурс игълан итә. «Кояш» гәзите битләрендә басылган конкурс шартлары режиссерның драма әдәбиятына карашын, таләпләрен аңлау өчен мөһим документ булып торалар.

Конкурс яхшы нәтиҗәләр бирә. Ул моңа кадәр билгеле булмаган берничә язучы белән таныштыра. 1917 елның 14 августында «Сәйяр»дә Фәтхи Бурнашның «Адашкан кыз» драмасы буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы була. Бераздан соң Миргазиз Укмасиның «Наместник урыны өчен көрәш», Әхмәд Мөнирнең «Солтан Фатыйх» пьесалары сәхнәгә күтәрелә. Танылган язучылардан Мирхәйдәр Фәйзи, Шәриф Камал конкурска үзләренең яңа әсәрләрен тәкъдим итәләр.

Г. Кариевның татар драматургиясенә күрсәткән аеруча зур хезмәте – К. Тинчуринны «Сәйяр»гә кабул итүе һәм аны сәхнә хезмәткәре итеп тәрбияләве. Труппага өйрәнчек актер итеп алынган К.Тинчуринның артист, режиссер, драматург буларак тәүге адымнары ихлас күңелле, таләпчән Г. Кариев күзәтүендә ясала. Октябрь революциясеннән соң «татар театрының атасы» үзе төзегән театр мәктәбе традицияләрен, атап әйткәндә, режиссура мәктәбе принципларын инде сәхнә сәнгатен тирәннән белүче, шәхес буларак та өлгереп җиткән К. Тинчуринга тапшырып калдыра.

Революциягә кадәрге «Нур» һәм «Ширкәт» труппаларының режиссурасы «Сәйяр»нең сәхнәләштерү сәнгате башлап

җибәргән эстафетаны дәвам итә һәм параллель рәвештә үсә башлый. Уфада «Нур»ны оештыручы С. Гыйззәтуллина-Волжская да, Оренбургта «Ширкәт»не төзегән В. Мортазин-Иманский да – «Сәйяр» труппасында тәрбияләнгән кешеләр. Шуңа күрә дә С. Гыйззәтуллина-Волжская 1912 елдан, ягъни труппасы эшли башлаган көннән үк, Г. Кариев кебек, режиссураның сәнгать чараларын үзләштерүгә керешә һәм үзенең сәхнәләштерү эшчәнлеген татар режиссурасы үсешенең икенче этабыннан башлый. Ә яңа оештырылган «Ширкәт»нең режиссерлары В. Мортазин-Иманский һәм М. Мутин алдында бу проблема тормый. Чөнки революциягә кадәрге татар драматик труппаларының өченчесе дөньяга килгәндә инде режиссураның сәнгать мөмкинлекләрен үзләштерү процессы соңгы стадиясенә кадәр җитеп бара. В. Мортазин-Иманский Г. Кариев һәм С. Гыйззәтуллина-Волжская белән беррәттән, милли репертуарны баету өстендә эшли. Татар драматургиясенең классик үрнәкләре дип танылган әсәрләрдән М. Фәйзинең «Галиябану»ын, Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә»сен һәм башкаларны беренче булып сәхнәләштерү шәрәфенә «Ширкәт» труппасы ия була. 1915 елдан башлап татар мәдәниятенең өч үзәгендә – Казанда, Уфада һәм Оренбургта – бер-берсенә ярдәм итешеп һәм бер-берсен баетып өч труппа яши. Һәм «Сәйяр», «Нур» һәм «Ширкәт» режиссерларының тәҗрибәсе алга таба татар театрының сәхнәләштерү сәнгатенең бердәм хәзинәсендә туплана.

Татар театрының беренче сәхнәләштерүче-режиссеры булып хаклы рәвештә Габдулла Кариев санала. Югары культуралы, заманы өчен тирән белемле, татар профессиональ театрын оештыруның иҗтимагый һәм сәяси әһәмиятен яхшы аңлаган кеше булуы өстенә, ул шул ук вакытта искиткеч зур актерлык талантына, оештыру сәләтенә, бик яхшы режиссер һәм педагог сыйфатларына ия була.

Тормыш хакыйкате принцибы Г. Кариевның актерлык һәм режиссерлык эшчәнлегендә төп принцип була. Шуның өстенә, режиссерлык тәҗрибәсендә ул һәрвакыт драматик материалны нигез итеп ала һәм аннан читкә тайпылмыйча, аны мөмкин булган кадәр тулы итеп сәхнәдә гәүдәләндерергә тырыша. Әмма образларның чишелешендә ул беркайчан да драматик материал белән генә чикләнми. Тормыш аның өчен бетмәс-төкәнмәс байлык, иҗат потенциалының алыштыргысыз чыганагы булып тора. Әгәр аның эмоциональ хәтерендә эш өчен кирәкле материал булмаса, ул пьесада тасвирланган мохит кешеләре арасына чыгып китә. Персонажларның реаль прототипларын җентекләп өйрәнгәннән соң гына ул эшен яңадан дәвам итә. Үзе күзәтүчән кеше буларак, ул үзенең актерларын да шуңа өйрәтә. Актерлар белән эшләгәндә Кариев шәхси тормышыннан кызыклы эпизодлар турында сөйли, әдәби тәңгәллекләр китерә, теге яки бу башкаручының ролендә берәр деталь

килеп чыкмаганда, ахыр чиктә, күрсәтү алымнарын файдалана.

Реалистик юнәлеш режиссеры буларак, Г. Кариев сәхнәдә «тормыш кисәген» бөтен тулылыгы белән гәүдәләндерергә омтыла. Шуңа күрә аның спектакльләрендә сәхнә бизәлеше һәрвакыт тормыш хакыйкате принцибына туры килә: әйтик, әгәр бу интерьер икән – ул көнкүрештәге кебек ышандырырлык, артык вак детальле түгел, әлбәттә, чөнки күчмә театр шартлары купшылыкка мөмкинлек бирми. Сәхнәдә һәрвакытта диярлек актерларга уен барышында зарури әйберләр генә була. Милли режиссура үсешенең беренче чорында Г. Кариев куйган спектакльләр, нигездә, камера характерында булалар. Ләкин масштаб, тышкы бизәлеш ничек кенә булмасын, эшчәнлегенең барлык этапларында да Кариевның игътибар үзәгендә персонажларның эчке дөньясы була. Һәр геройның психологиясен, характер үзенчәлекләрен, эш-гамәлләре акланышын төптән тикшереп, ул тирән реалистик, психологизм тулы сәхнә әсәрләре тудыра.

Әгәр Габдулла Кариевның спектакльне эшләү ысулын тасвирлап карасак, беренче чиратта, аның иң элек актер булуы һәм режиссурага актер иҗаты күзлегеннән каравы турында әйтергә кирәк. Спектакльне куюга керешкәндә Кариев күбрәк персонажларның характеры, язмышлары һәм үзләрен тотышы турында уйлый, драматик материалны тормыштан алынган күзәтүләр белән тулыландыра. Шуннан соң бөтен актерларның рольләрен уйнап күрсәтеп, аларны персонажларның эчке логикасы буйлап үткәрә. Кариевның режиссурасы гадилеккә, фикер төгәллегенә, тормышчанлыкка, дөреслеккә омтылышы белән аерылып тора. Аның спектакльләрендә мизансценалар ике төп таләптән чыгып төзелә: актер мәнфәгате һәм тормыш хакыйкате.

Г. Кариев, спектакль барышында рухланып, кабынып китүчән, импровизацияләргә бик тартым актер буларак, репетиция процессына да зур җанлылык һәм темперамент кертә. Ул әзер, эшкәртелгән план белән труппага сирәк килә. Шуңа күрә аның репетицияләре башта әкрен темпта барган шикелле. Ләкин бу озакка сузылмый. Әкренләп вакыйгаларга кереп китеп, рухланып һәм башкаларны да рухландырып, Г. Кариев актерларны тиешле иҗат халәтенә китерә. Бу этапта инде Г. Кариев актерларга ирек бирә. Режиссерның ихтыяр көче һәм фантазиясе белән хәрәкәткә китерелгән актерлар яңадан-яңа кызыклы детальләр, җайланмалар тәкъдим итәләр. Спектакльне куючыга башкаручылар уйлап тапканнарны сайлап алып ныгытырга гына кала. Әгәр репетициянең барышы тоткарланса, тукталып калса, шундук бер-бер артлы актерлар урынына уйнап күрсәтү, чын-чынлап тормышчан, көчле төсмерләр, чишелешләр, мизансценалар тәкъдим итү башлана. Шулай куәтләндерелгән иҗат процессы яңа көч белән дәвам итә, булачак спектакльнең аерым өзекләре, пәрдәләре туа. Ләкин кайвакытта репетицияләрдә иҗат

чаткысы кабынмый, спектакльгә әзерлек әкрен, сүлпән бара. Мондый очракларда Г. Кариевның берәр кичектергесез эше «исенә төшә», һәм алга таба репетиция процессын В. Мортазин-Иманский (ә ул труппадан киткәннән соң К. Тинчурин) алып бара. Г. Кариевның әйдәп баручы актер В. Мортазин-Иманский белән хезмәттәшлеге үзенчәлекле режиссерлар коллегиясе тәшкил итә, гәрчә беренчесе рәсми рәвештә труппаның җитәкчесе, сайланган директоры, ә икенчесе – режиссеры булып исәпләнә. Аларның бу коллегиясе озакка сузылган: 1907 елда Түбән Новгородта башланган һәм В. Иманскийның труппадан китүенә, ягъни 1915 елның җәенә кадәр дәвам иткән. Труппада хәлиткеч тавыш бирү хокукына Г. Кариев ия була, әмма ул иҗат мәсьәләләрен берүзе, башкалар белән киңәшләшмичә сирәк хәл итә. Бигрәк тә труппага яңа кешене кабул итүгә җаваплы карый. Революциягә кадәрге «Сәйяр» өчен актерлар сайлап алу һәм актер ансамбле булдыру, оештыру нәкъ аның тырышлыгы нәтиҗәсе.

Труппаның спектакльләре ансамбльнең тигез хокуклы әгъзаларының иҗади бердәмлеге, сәхнәдәге аралашуы нигезендә тудырыла. Труппада «премьер»лар да, аеруча өстенлекле актерлар да булмый, драматик материал таләп итмәсә, барысының да бер актерга буйсынуы да булмый. Пьеса үзе таләп иткәндә генә ансамбль «солист һәм хор» принцибында төзелә. «Сәйяр»гә биш ел тулганда труппаның актерлар коллективы тулысынча диярлек ансамбльлелек таләпләренә җавап бирә. Һәр актерның да репертуарда үзенә генә хас урыны була. Бу урын аның сәләтлелек дәрәҗәсе белән билгеләнә. Артистларның эчке мөмкинлекләрен белү труппа режиссерларына рольләрне дөрес бүлүдә ярдәм итә. Ә бу, үз чиратында, спектакльдә ансамбль булдыруга, аның идеяләрен, эчтәлеген тулы чагылдыруга булышлык итә.

Тиешле драматургия булмый торып театрның үсә алмаячагын бик яхшы аңлаган Габдулла Кариев театр репертуарын төзүгә гадәттән тыш нык игътибар бирә: талантлы драматургларның нәрсә язганнарын һәрвакыт белеп тора, аларга аерым характерларны тудыруда ярдәм итә, темалар күрсәтә. Г. Кариев актерларда даими рәвештә югары сәнгати һәм эстетик принциплар тәрбияли. Алар яңа театр бинасын төзү өчен фундамент ролен үтиләр. «Артист өчен театр – яшәү мәгънәсе». Үзенең тәрбия эшендә режиссер Кариев шул девизга нигезләнә.

Г. Кариевның режиссура гына түгел, ә гомумән, татар театрының барлыкка килүендәге һәм үсешендәге ролен бәяләп бетерү дә кыен. Яшәгәндә үк ул үз халкының бөек таланты буларак кабул ителә. Сәхнә эшчәнлегенең 5 еллык юбилеен бәйрәм итү көнне аңа бирелгән адреста түбәндәге сүзләр очраклы түгел: «Бу көндә татар халкы сезнең биш сәнә буенча «Сәйяр» труппасын ялыкмый идарә кыйлуыгызны, татар театрын тәрәккый юлында күрсәткән корбанлыгыгызны, тагы татар театры гамәлендә моңа кадәр нәзыйрсыз артистлык

талантыгызны тәкъдир кылып, сезне «татар театрының атасы» дип исемли».

Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, С. Гыйззәтуллина-Волжская һәм башкалар имзалаган бу юллар (барлыгы житмешкә якын кеше кул куйган) татар халкының алдынгы эшлеклеләре Г. Кариевны никадәр югары бәяләүләрен һәм яратуларын күрсәтә.

Габдулла Кариев, пәйгамбәрләр шикелле үк, бу дөньяга аерым миссия өчен китерелгән шәхес. Аның гомеренең төп бурычы – татар театрын тудыру, юнәлешен билгеләү, баштагы үсеш баскычларын үздыру булгандыр. Шушы миссияне үтәгәннән соң, ул бик иртә, 34 яшендә (бусы да пәйгамбәрләр яше диярлек) 1920 елда дөньядан китә. Китә, ләкин ул башлаган эш, аның тормышының мәгънәсе – татар театры кала. Шуңа күрә җир йөзендә татар халкы яшәгәндә Габдулла Кариев исеме дә онытылмаячак.

***Арсланов Мөхәммәтгали Гыйльмегали улы,***
*сәнгать фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире*

УДК 929

*Э.Х. Кадыйрова*

# ТЫНГЫСЫЗ ГАЛИМӘ

Статья посвящена научной деятельности доктора филологических наук, профессора Фанузы Шакуровны Нуриевой в области истории татарского языка.

**Ключевые слова:** Ф.Ш. Нуриева, татарское языкознание, тюркология, история языка.

Гыйльми эшчәнлекләре белән фән үсешенә зур өлеш керткән һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүдә күп көч сарыф иткән татар тел белеме галимнәре арасында Фәнүзә Шәкүровна Нуриева лаеклы урын алып тора.

Мәктәп укучысы – университет студенты – аспирант – ассистент – өлкән укытучы – доцент – профессор баскычларын жиңел генә узмагандыр ул. Әмма Фәнүзә Шәкүровна аларның һәммәсен лаеклы үтте.

Фәннәр докторы, профессор дәрәҗәсенә махсус әзерли торган уку йортлары юк. Ул дәрәҗәләргә ирешү өчен табигый сәләтең, эти-әниең салган холык, тырышлык, мәктәп биргән юнәлеш һәм югары уку йортында язмышыңда хәлиткеч роль уйнаучы остазыңны очрату мөһимдер. Фәнүзә Шәкүр кызы Нуриева Татарстан Республикасының Баулы районы Иске Чүти авылында 1956 елның 8 нче мартында туа. Баулы районы Кызылъяр урта мәктәбен бетереп, 1973 елны Казан дәүләт университетына укырга килгән Фәнүзәнең фәннәргә сәләтен ул вакытта тарих-филология факультетын һәм татар теле кафедрасын җитәкләгән Диләрә Гарифовна Тумашева күреп ала һәм аны индивидуаль уку планына күчерә. Шулай итеп, Фәнүзә студент елларыннан ук мавыктыргыч фән дөньясының тәмен татый башлый һәм бу кызыксыну аны 1983 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының тел белеме бүлегенә аспирантурага китерә. Анда инде Фәнүзә Шәкүр кызы тел белеменең иң авыр, шул ук вакытта иң кызыклы булган бүлеге – тел тарихы өлкәсенә кереп китә. Ул атаклы тюрколог Ә.Р. Тенишев һәм аның укучысы Ф.С. Хәкимҗанов җитәкчелегендә «Мәхмүт Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» (1358 ел) әсәренең тел үзенчәлекләре» дигән темага диссертация яза. Аспирантураны тәмамлагач, Фәнүзә Нуриева үзен белгеч итеп әзерләгән остазлары янына университетның көнчыгыш телләр кафедрасына эшкә чакырыла.

Ф.Ш. Нуриева 1999 елда басылган «“Нахдж ал-Фарадис” Махмуда ал-Булгари» [Нуриева, 1999] хезмәтендә Мәхмүд әл-Болгариның «Нәһҗел-фәрадис»

әсәренең тел үзенчәлекләрен, истәлекнең XIV гасыр Идел буе язма әдәби телен өйрәнүдәге урынын өйрәнә.

Галимәнең гасырлар дәвамында татар укымышлылары, халкыбыз саклап, укып килгән мәдәни мирасыбызны бүгенге көн укучысына кайтару өлкәсендә дә уңышлары бар. «Нәһҗел-фәрадис» әсәренең барлык табылган кульъязмаларын барлап, иң тулы нөсхә нигезендә аны гамәлдәге язуга күчереп бастыра. Филология фәннәре докторы Мәсгуть Гайнетдин, Фәнүзә Нуриева Мәхмүд Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрен нәшер иткәч, «Шәһри Казан» газетасында болай дип яза: «Чамасыз олы күләмле (440 бит) кульъязма белән эшләүдән дә, гасырлар тузаныннан да курыкмаган, алынган, Ялчыгу-талчыгуларга да чыдаган, эшен, зур күләмле авыр хезмәтне, ахырына җиткерә, олы мәйданга чыгара алган. Моны олы батырлык дип бәяләп була...Олы эшкә алынырдай сәләтле кызларыбыз булуга ничек куанмыйсың...». «Көрәшче, батыр ирләр хезмәте» дип бәяли ул авторның бу иҗат җимешен [Гайнетдин, 2002]. 2004 елда Казан дәүләт университеты нәшриятында басылып чыккан «Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золотоордынского периода» китабы [Нуриева, 2004] докторлык диссертациясенең нигезен тәшкил итә. Элеге хезмәттә Алтын Урданың ике йөз еллык әдәби-мәдәни мирасы күзаллана. Авторга күпчелек язма истәлекләрнеербөтен итеп карау һәм шул ук вакытта аларны чагыштырып та өйрәнү бу чор әдәби теле үзенчәлекләрен киң планда ярктыртырга мөмкинлек бирә. Җентекле тикшеренүләр Ф. Нуриевага күп кенә тел күренешләренә яңача килергә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, төрки тел белемендә кабул ителгән «катнаш тел» термины галимнәр тарафыннан төрлечә аңлатыла. Галимә аны «норма һәм вариантлык» итеп карау кирәклекне күтәрә. Бу чор өчен нормалар билгеләнмәгән, шунлыктан автор бик күп статистик күзәтүләр ясый, ягъни һәрберсе 200–300 биттән торган зур күләмле әдәби текстларны карый, алардагы норма һәм вариантлылыкны билгели. Ул d-тел, z-тел, j-тел терминнарын да d-графикалы текст, z-графикалы текст, j-графикалы текстлар дип атау кирәклекне фәнни дәлилләр белән раслый. Тугыз истәлекне бердәм таләпләр нигезендә тикшереп, Ф. Нуриева, караханид-уйгур традицияле әдәби телгә кыпчак формалары үтеп кереп, Алтын Урда чорында яңа региональ әдәби тел, иске татар әдәби теленең бер варианты барлыкка килүен нигезли.

Ф.Ш. Нуриева җитәкчелегендә авторлар коллективы 2012 елда Иероним Мегизерның «Institutiones linguae Turcicae libri quator» грамматикасын төрки халыклар тарихында беренче мәртәбә киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим иттеләр [Нуриева, 2012]. Төрки телләр институты тарафыннан хәзерләнеп 1612 елда Лейпцигта дөнья күргән, беренче төрки басма китап булып саналган бу хезмәттә яңа һәм иске дөньяның

актив кулланыштагы сүзләр җыелмасы тупланган. И. Мегизернең 750 биттән гыйбарәт булган бу сүзлегендә латин сүзләре күп телләргә тәрҗемә ителгән. Мәсәлән, abacus сүзе борынгы яһүд, халдей, гарәп, абиссиния, грек, яңа грек, итальян, испан, француз, португал, ретороман, сардин, алман, фламанд, борынгы алман, инглиз, дат, швед, гот, славян, төрек, әрмән, венгр, вельт телләренә тәрҗемә ителгән. Хезмәт авторлары И. Мегизерның төрки телнең барлык нечкәлекләрен белеп өйрәнгәнлеген әйтәләр. Мәсәлән, ул чагыштыру дәрәҗәсе -reck (-рәк) кушымчасы, артыклык дәрәҗәсе gajeth (гаять) кисәкчәсе ярдәмендә һәм аның сүзнең башына ялганып килүе турында яза. Шулай ук чагыштыру мәгънәсенең башка ысул белән ясалу мөмкинлеген дә күрсәтә. Мәсәлән, senden biuk (синнән зур), senden kutſchuck (синнән кечкенә) кебек мисалларда сыйфат чагыштыру кушымчасын алмый, чагыштыру объектына -дан/ -дән кушымчалары ялгана. Галимнәрнең И. Мегизер китабына җентекле анализ биргән бу хезмәте аның төрки тел белеме, төрки тел теориясе формалашуында тоткан ролен, шул ук вакытта XVII гасырда төрки халыкларның дөньякүләм тарихтагы урынын, дәрәҗәсен ачыклау өчен яңа материал булуын исбатлады.

Фәнүзә Шәкүровнаның киңкырлы фәнни эшчәнлегенең төп юнәлеше – әдәби тел тарихын өйрәнү өлкәсе – аңа халыкара абруй алып килә. Фәнүзә Нуриева дистәләрчә халыкара конференцияләрдә, конгрессларда, симпозиумнарда чыгыш ясый, мәкалә, китаплар бастыра. Фәнүзә Нуриева – 200 дән артык фәнни эш авторы. Аның югары фәнни тикшеренүләре төрки тел белемендә зур бәя ала, гомумтөрки мәсьәләләргә багышланган мәкаләләре чит ил басмаларында урын ала, коллектив монографияләрдә күп кенә махсус хезмәтләре басыла. Мәсәлән, галим тарафыннан әзерләнгән материаллар «Татар әдәби теле тарихы» [Нуриева, 2003], «Татар тарихы» [Нуриева, 2004], «Татар әдәбияты» [Нуриева, 2015] кебек күптомлы хезмәтләрдә урын алды. Шулай ук Казахстан Республикасы Фән һәм мәгариф министрлыгы Төрки академиясенең фәнни-координацион советы тәкъдиме белән Ф.Ш. Нуриеваның «Атрибуция языка письменных памятников золотоордынского периода» китабы Н. Назарбаевның кереш сүзе белән 2012 елда Астанада нәшер ителде [Нуриева, 2012]. 2015 елда Берлинда басылган «Interpreting the Turkic Runiform Sources and the Position of the Altai» җыентыкта Идел буендагы рун язулы истәлекләрне өйрәнгән хезмәте чыкты [Nurieva, 2015]. Ул элекке Болгар дәүләте тирәләрендә табылган унбер рун язуы үрнәкләре, аларны уку, өйрәнү һәм болгар теленең нинди булуын ачыклауга багышланган.

Фәнүзә Шәкүровна – Казан федераль университеты Лев Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм

мәдәнияте бүлеге студентларының яраткан укытучысы да. Ул, төрки тел белеме буенча билгеле белгеч буларак, аларга «Борынгы төрки телләр», «Төрки тел беленә кереш», «Татар әдәби теле тарихы» фәннәреннән дәресләр алып бара. Ф.Ш. Нуриеваның «Борынгы төрки тел» дәреслеге үзенең тулылыгы белән игътибарга лаек. Өч бүлектән торган бу хезмәттә орхон-енисей язмалары хакында тарихи белешмә бирелә, рун язулы текстларның фонетикасы, морфологиясе мәсьәләләренә игътибар ителә. Татар теленә тәрҗемәсе китерелгән текстлар урнаштырыла. Аны чит илләрнең югары уку йортларына да лекцияләр белән чыгыш ясарга чакыралар. 2014 елда Төркиянең Фрат университетында студентлар һәм магистрларга татар теле хакында лекцияләр укыды.

Эзләнүчән галимә җитәкчелегендә 10 ел эчендә 6 аспирант, гыйльми тикшеренү эшләрен нәтиҗәле алып барып, кандидатлык диссертациясен уңышлы якладылар.

Шул ук вакытта галимәбез ире, шулай ук филология фәннәре докторы, профессор Гәбдрәүф Салих улы белән, менә дигән ике ул үстерделәр. Олы уллары Әнәс, Казан дәүләт университетының юридик һәм экономика факультетларын, аспирантураны тәмамлап, фәннәр кандидаты дәрәҗәсе алды, ә Әннур геология факультетын тәмамлады. Икесе дә үз өлкәләрендә хезмәт куя. Оныклары көн саен һөнәрләрен арттырып, дәү әниләре һәм дәү әтиләрен сөендереп торалар.

Күренекле тел галиме, профессор, филология фәннәре докторы, педагог, Россия Федерациясе югары профессиональ белем бирүнең мактаулы хезмәткәре, Россия тюркологлар комитеты әгъзасы Фәнүзә Шәкүр кызы бу көннәрдә үзенең юбилеен билгеләп үтте. Без аны чын күңелдән туган көне белән котлыйбыз. Бу матур гаиләгә киләчәктә дә иҗади уңышлар, югары фәнни биеклекләр һәм һәр кешегә дә кирәк булган бәхет, сәламәтлек, муллык, якын дуслар теләп калабыз.

### Әдәбият

*Гайнетдин М.* Шәһри Казан. 2002. 20 сентябрь.

*Мегизер Иероним.* Institutions linguae Turcicae libri quator. Основы тюркского языка / Ф.Ш. Нуриева, М.М. Петрова, М.М. Сунгатуллина. Казань: Магариф-Вакыт. 2012. 288 с.

*Нуриева Ф.Ш.* «Нахдж ал-Фарадис» Махмуда ал-Булгари. Казань: Фэн, 1999. 218 с.

*Нуриева Ф.Ш.* Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка золотоордынского периода.

*Нуриева Ф.Ш.* Тюркоязычный памятник «Ана вә угыл дастаны» // История татарского литературного языка. Казань: Фикер, 2003. С. 136–144.

*Нуриева Ф.Ш.* Исторические и лингвистические условия формирования тюрко-татарского литературного языка периода Золотой Орды. Казан: Изд-во Казан. ун-та, 2004. 375 с.

*Нуриева Ф.Ш.* Золотоордынский литературный язык // История татар с древнейших времен. Т. III. Улус Джучи (Золотая Орда). XIII – середина XV в. Казань: Институт истории АН РТ, 2009. С. 668–676.

*Нуриева Ф.Ш.* Атрибуция языка письменных памятников золотоордынского периода. Рекомендована научно-координационным советом Тюркской академии Министерства образовании и науки Республики Казахстан. Астана: Сарыарка, 2012. 201 с.

*Nurieva F.Š.* Old Turkic Runic Monuments of the Volga Area // Interpreting Runic sources and the Altay corpus / Nevskaya, I. Erdal, M. (Eds.). Berlin: Klaus Schwarz Verlag, 2015. С. 112–121.

*Нуриева Ф.Ш.* Мәхмүд әл-Болгари һәм аның «Нәһҗел-Фәрадис» әсәре // Татар әдәбияты: сигез томда. Т. I. Казан, 2015. Б. 330–339.

***Кадыйрова Энҗе Хәнәфи кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Казан (Идел буе)*
*федераль университеты доценты*

УДК 811.512.145'282

*М.Р. Булатова*

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ЯҮШТӘ-ЧАТ СӨЙЛӘШЕ

(*2015 елда Томск өлкәсенә булган экспедиция материаллары буенча*)

В статье дана краткая этнолингвистическая характеристика эуштинско-чатского говора в сравнении с татарским литературным языком. Прилагаются образцы речи, в которых сквозь призму лексики и языковых особенностей местного говора рассматриваются материальная и духовная культура сибирских татар. Материал подготовлен по результатам комплексной экспедиции, предпринятой в 2015 г. Институтом языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ в Томскую область РФ.

**Ключевые слова:** комплексная экспедиция, диалектология, сибирские татары, материальная и духовная культура, эуштинско-чатский говор, фонетика, грамматика и лексика.

Татар халкының рухи һәм милли-мәдәни мирасын туплау максаты белән Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты төрле төбәкләргә фәнни экспедицияләр оештыра. Институтның бер төркем галимнәре һәм аспирантлары Себер регионында көн күрүче татарларны да өйрәнү нияте белән 2014–2015 елларда Омск һәм Томск өлкәләрендә булып кайтты.

Томск өлкәсенә оештырылган комплекслы экспедициядә катнашучылардан филология фәннәре кандидаты, диалектолог Миңнира Булатова себер татарларының тел үзенчәлекләрен, филология фәннәре кандидаты, экспедиция җитәкчесе Олег Хисамов төбәкнең топонимикасын өйрәнсә, филология фәннәре докторы Илсөяр Закирова һәм аның аспиранты Гөлнара Яхшисарова халык авыз иҗатын, филология фәннәре кандидаты Илһам Гомәров борынгы кульязма китапларны җыйды, яшь белгеч Алсу Борһанова себер татарларының алтын куллы осталары тудырган иҗат җимешләрен туплады.

Җырларында данланган Том елгасы тирәли сибелеп утырган Абытай (рус. Черная речка), Казан (Казанка), Калтай, Кирәк, Кызыл Каш (Тахтамышево), Умаул/Омайыл (Барабинка), Яңавыл (Березовая речка), Яүштә (Эушта) исемле татар авылларына һәм Томск шәһәренең «Татар Бистәсе»енә экспедиция уздыру милләттәшләребезнең гореф-гадәтләрен, көндәлек һәм мәдәни тормышларын яктырткан материаллар тупларга һәм тел үзенчәлекләре җәһәтеннән фәнни нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек тудырды.

Томск шәһәренең «Татар бистәсе» XVII гасыр башында ук барлыкка килгән. Аның төп урамы

«Татарская» дип атала. Бу урам башыннан ахырына кадәр искиткеч матур итеп бизәкләп эшләнелгән, агачтан салынган ике катлы йортлардан тора. 1914 елга кадәр бистәне шәһәрдән Исток дип аталган кечкенә ерганак аерып торган. Хәзер бу Исток җир астыннан агып, Том елгасына килеп кушыла. Аның тирәли шушы өлешен Заисток дип атаганнар.

Татар бистәсенең М. Горький урамындагы 35 нче санлы йортта татарларның төп җыелу урыны – «Татар мәдәни үзәге» бар. Ул 1906–1910 елларда ук салынган,ерактан ук күз явын алып торырлык зәңгәрсу төстәге «Кәрим бай йорты»нда урнашкан. Замандында сәүдәгәр, хәйрияче, җәмәгать эшлеклесе Кәрим Хәмитов аны үз гаиләсе өчен салдырган булган. Бай атлар үстерү белән шөгыльләнгән, рус-япон сугышы чорында патша гаскәрен дә атлар белән тәэмин итеп торган. 1919 елда, Кәрим Хәмитов үлгәч, гаиләсе башка урынга күченә. Йорт дәүләткә кала һәм биредә 1920 елдан Төрки-татар укыту семинариясе, ә 1930 елдан Төрки-татар педагогия техникумы вакытлыча эшләп алалар. Кәрим байның үз проекты буенча төзелгән бу йорт хәзерге көндә федераль дәрәҗәдә саклана торган архитектура һәйкәле дип санала. Боларны безгә Татар мәдәни үзәге хезмәткәре Сафиуллина Елена Шәүкәт кызы сөйләп ишеттерде. Татар мәдәни үзәгенең барлыкка килүенә 20 ел, ә Кәрим бай йортына алар 1996 елда килеп урнашалар икән. 1994–2005 елларда үзәкне Әбдрәшитов Йосып Якуп улы, ә 2005 елдан Сабирова Флюра Гафур кызы җитәкли. Мәдәни үзәкнең гөрләп алга китүенә 1970 елда оешкан «Халкым моңнары» вокаль ансамбле ныклы этәргеч була. Биредә тагын зур уңышлары белән сөендереп, «Нур» хор ансамбле эшләп тора. Бу йортта татар мәдәниятен саклау белән шөгыльләнә торган 15 тән артык берләшмә эшли. Өлкәннәр өчен «Замандашлар» ретро-клубы, «Ялкын» вокаль-инструменталь ансамбле, яшьләр өчен «Айнур» бию төркеме, «Дуслык» клубы һ.б. бар. Кәрим бай йортына кушылып ук урнашкан бинада Себер, Томск, Заисток районы тарихына караган төрле материалларга бик бай «Заисток» музее бар. Татар Бистәсе һәм Кәрим бай белән кызыксынучыларга музейны 30 елдан артык җитәкләүче Лидия Васильевна Муравьева бик тәфсилләп сөйләп бирәчәк.

Томск шәһәренең Татар бистәсендә ике мәчет тә бар: ак мәчет һәм кызыл мәчет. Халык әйтүенчә, татарларның күпчелеге кызыл мәчеткә йөрсә, башка милләттәге мөселманнар ак мәчеткә агыла.

Том авыллары халкы безне ачык йөз белән каршы алдылар. Хәтта Татар мәдәни үзәгенә 10–15 ләп «Нур» (берничәсе «Халкым моңнары»ннан) ансамбле апалары җыелышып безне көтеп утыралар иде. Алар үзләренең туган якка мәхәббәтләрен көй-моңнары, җыр-биюләре аша җиткерделәр. Ярымтүгәрәк итеп тезелешеп утырып, Себер ягы, аның халкы, көнкүреше турындагы төрле хәлләрне, легенда, бәетләрне сөйләп ишеттерделәр.

Гомумән, фәнни экспедиция вакытында бай һәм бик кызыклы материал тупланды. Җирле сөйләш үзенчәлекләрен яктырткан, традицион культура, авыллар тарихы, гореф-гадәт, йолаларга караган этнолингвистик материаллар һәм күпләгән лексик берәмлекләр җыелды. Җирле сөйләш үзенчәлекләренә килгәндә, аралашу, әңгәмә алып бару вакытында шул күзгә ташланды: 60 яшьтән түбәнрәк информантларыбыз әдәби телдәрәк сөйләшә һәм рус сүзләрен рәхәтләнеп кулланалар, тәрҗемәсен әйтә дә алмыйлар. Өлкәнең тел үзенчәлекләрен беренчеләрдән булып ныклы өйрәнүче тел белеме галимәсе Д.Г. Тумашева һәм аннан соңгы буын фән докторлары Д.Б. Рамазанова, Ф.С. Баязитова үз хезмәтләрендә биредә том диалектының яүштә, чат һәм калмак сөйләшләре таралган дип исбатлыйлар. Д.Б. Рамазанова яүштә-чат сөйләшен Д.Г. Тумашева хезмәтләренә таянып һәм үзе 1996, 2005 елларда уздырылган экспедиция вакытында туплаган материалларына нигезләнеп «Татар халык сөйләшләре» (Казан, 2008) дип аталган китапта тасвирлый. Шунда ук Т.Х. Хәйретдинова, Ф.С. Баязитова белән берлектә 2003 елда уздырылган экспедиция материаллары нигезендә, аның тарафыннан калмак сөйләше дә тәфсилләп языла. Әлеге сөйләшләрдәге үзенчәлекләр күбрәк өлкәнрәк яшьтәге әби-бабайлар сөйләмендә сакланган. Күрәсең, сөйләш вәкилләренең үзара аралашып яшәве, татар әдәби теленең, совет чорында көчәеп килгән татарлар сөйләше борынгыдан себер җирендә көн күргән «себерәкләр» сөйләшенә ныклы тәэсир иткән. Алар Татарстаннан башлап көнбатышка таба территорияне «Казан як» дигәннәр. «Безнеңке мамау-бабаулар (*әбибабайлар*) Казан йактан (*ягыннан*) килгәннәр» дип сөйлиләр. Монда Түбән Новгород, Пенза, Сергач якларыннан күпләп мишәрләр дә килгән һәм алар себер сөйләше йогынтысына бик бирелмәгән. Мәсәлән, Мөхәррәмов Фәсхетдин Кәлимулла улы сөйләвенчә, башта киржаклар яшәгән Кирәк авылына Сергач районының Парчалы (хәзер Тукай дип атала) һәм Бозлау авылларыннан мишәрләр гаиләләре белән күченеп килеп утырганнар.

Түбәндә информантлар белән аралашкан вакытта яңгыраган том диалекты яүштә-чат сөйләшенең төп үзенчәлекләре тәкъдим ителә.

## Фонетик үзенчәлекләр

***Сузыклар.*** Яүштә-чат сөйләше сузык авазлар составы ягыннан әдәби телдән, нигездә, аерылмый. Ә калмак сөйләшендә *а* авазы мишәр, себер һәм урта диалектның кайбер сөйләшләрендәге кебек иренләшмәгән: *қатыштыру* – әдәби ка°тыштыру (чагыш.: тевриз сөйләшендә, ягъни янәшәдәге Омск өлкәсе татарларында, сүз башындагы *а* авазына, әдәби телдән аермалы буларак, бик көчле иренләштерү хас, ул *о*$^{а}$, хәтта *о* рәвешендә дә әйтелә: *қо*$^{а}$*пқа* – әд. ка°пка).

Сузыклар өлкәсендәге үзенчәлекләр төрле тәңгәллекләргә, комбинатор үзгәрешләргә кайтып

кала. **а~ы** (*ы* авазы урынына *а* авазын куллану): *суwақ* – әд. суwык (суык), *аwырап йатты* – авырып ятты; **ы~а:** *туйғынча* – туйганчы, *йаңы* – йаңа (яңа); **ө~о:** *йөн* – йон; **о~у:** *тоғыс* – тугыз, *зор* – зур, *қоанды* – куанды; **ө~ү:** *көптән* – күптән, *өскәру* – үзгәрү; **ү~и:** *күгүwөн* – кигәвен, *үтек* – итек һ.б.

Әдәби телдәге *-ый/-ий* дифтонгына *-ай/-әй* дифтонгы тәңгәлләшә: *сөйләй* – әд. сөйли, *теләй* – тели, *барлый* – барлай.

3 нче зат хәзерге заман хикәя фигыльләрнең *-а/-ә* кушымчасы да *-ай/-әй* дип яңгырый: *төшәй* – әд. төшә, *үсәй* – үсә, *күренәй* – күренә һ.б.

***Тартыклар*. ц~ч:** *мәцет* – әд. мәчет, *кецкенә* – кечкенә, *ацық* – ачык, *перенце* – беренче, *цыпцық* – чыпчык; **п~б:** *пийыл* – быйыл (быел), *пала* – бала, *поронғы* – борынгы; **б~п** (алынма сүзләрдә): *былау* < плов – пылау; **м~б:** *малан* – балан, *йарабый* – йарамый, *әйбә* – әйеме; **з~с** (ике сузык арасында): *кизеп* – кисеп, *баразың* – барасың; **с~з:** *қасылған* – казылган, *барабыс* – барабыз; **й~җ**: *йеләк* – җиләк, *йыр* – җыр; **ж~ш** (ике сузык арасында): *тажы* – ташы, *қыжсын* – кышын; *быжырақ* – пычрак; **қ~х:** *қатын* – хатын, *бәркет* – бәрхет һ.б.

Кушымчадагы башлангыч *л* авазының үзеннән алда килгән тартыкларга (*п, к/қ, т, с, ш, ц, ч*) охшашлануы:

а) күплек кушымчалары: *қунақтар* – әд. кунаклар, *орыстар* – урыслар, *қоштар* – кошлар, *кирпецтәр* – кирпечләр;

б) сүзъясагыч *-ла/-лә, -лык/-лек* кушымчаларында: *баштаған* – әд. башлаган, *көстек* – күзлек;

в) сыйфат ясагыч *-лу/-лү (-лы/-ле)* кушымчасында: *тәрәстү* – әд. тәрәзәле, *ике йаташту* – ике йаташлы (ике катлы) һ.б.

Уңай ассимиляция күренеше: *с, қ, к, р, п, т, ш, ц* тартыкларыннан соң килгән төшем һәм чыгыш килеш кушымчаларындагы *н* авазы *т,* ә сонорлардан соң *д* авазы белән тәңгәлләшә: *сөтте* – әд. сөтне, *мәктәпте* – мәктәпне, *бестеке* – безнең, *тамырдың* – тамырның һ.б. *Йәштәргә кирәк клупты эшләткәле* – Яшьләргә клубны эшләтергә кирәк.

### Морфологик үзенчәлекләр

Иялек килеше, әдәби *-ның/-нең* кушымчасы белән беррәттән, *-ныңы/-неке* кушымчасы ярдәмендә дә ясала: *Калхустықы* (әд. колхозның) *ысклат иде. Бу атамныңқы* (әтиемнең) *бер туған сестрасы. Бы орысларныңқы* (урысларның) *заимкасы. Ишмәй бабамнықы* (бабамның) *өйөндә ул. Менә бу Тумаулныңқы* (Тумавылның) *халығы – инәмнеңке туған йере.*

Компонентлары нисбәтлек мөнәсәбәтендә торган исем-исем сүзтезмәләрне (әбинең күлмәге, урам коесы һ.б.) кушымчасыз куллану: *Қасан йақ* – Казан ягы һ.б. *Сез йақта* (әд. сезнең якта) *сөйләйләр инде. Анда Воронин йақтан* (ягыннан) *килеп урлағаннар. Аwыл йанында Қазанцево заимка* (заимкасы) *булай. Икенце атнада тегендә туй, йегет йақта* (егет ягында) *туй.*

1 нче һәм 2 нче зат алмашлыкларның юнәлеш килеше *мәңа/мағa/маңа/миңә, сәңа/сағa/саңа/*

*сиңә* формаларында ясала. *Син баштай* (әд. башла), *мин сиңә* (сиңа) *булышырым* (булышырмын). *Син миңә* (миңа) *әйт кенә сүзләрен. Миңә* һәм *сиңә* формалары Башкортостанда яшәүче татарлар сөйләшләрендә, бигрәк тә курмантау сөйләшендә, бик актив.

Сорау алмашлыклары: *кем/ни/нимә* – әд. нәрсә*, қандый* – ничек, нинди, *қайсы, қанца* – ничә, *қацан* – кайчан. *Қандый* (әд. ничек) *әйтим инде. Әйтәй син монда килен булып килденмәле, урлап килгәннәрмә, нимәй итеп, қандый* (нинди) *булғансың, сөйлә.*

*Анца* – ‘шуннан бирле, шул чаклы, шул хәтле’ рәвешен куллану: *Алтмышынцы йылда тормошқа цығып, анца* (аннан < шуннан бирле, ул чаклы) *торам инде. Анца* (шул хәтле) *қазлар, ике ат, өцәр сыйыр буладаған.*

Сыйфатлар азагындагы *-ы/-е* сузыклары *-у/-ү* белән тәңгәлләшә: *терлү* – әд. төрле, *йәмнү* – ямьле, *йарлу* – ярлы, *сикемнү* – сөйкемле һ.б.

Сөйләштә *-дый/-дий (-дәй/-дай*) кушымчасы белән рәвешләр ясау актив: *Элеккеләрдә генә сандық булған, бездий* (әд. безнең кебек) *халықта булбаған. Әнийемнеңке күлмәкләр бөдрә-бөдрә итеп, халадай* (халат кебек) *йеңнәре киң, итәкләре қатқат, қуштанлы* (бәбәй итәк) *итеп тегелгән.*

*-а/-ә/-ый/-и* кушымчалы хәзерге заман, нигездә, әдәби телдәгечә: *сизәм/сизәмен, сизәсең, сизә; сизәбес, сизәсес/сизәсеңнәр, сизәләр.* Мисаллар: *Мин китәмен циткә, йырақларға. Бесне ташлап китәсес* (әд. китәсез). *Вечерға урыс аwылыннан да қызлар киләләр. Шулай итеп донйа көтәбес* (көтәбез). *Ул аwылға да барасыңнарба* (барасызмы)?

Чат урынчылыгында 2 нче зат күплектә *-сыңнар* кушымчасына *-ңнар/-ңдар* кушымчасы тәңгәл килергә мөмкин: *Йәш wақытта қандай* (әд. нинди) *уйындар уйнағанды искә төшөрәңдәрбә* (искә төшерәсезме)*?* – Яшь вакытта нинди уеннар уйнаганыгызны искә төшерәсезме? *Сес қайа бараңнар, дийеп әйтәй* – Сез кая барасыз дип әйтә (сорый). *Нигә қороға эцәңнәр* (эчәсез)*? Йетешегез, ашаңнар* (ашагыз), *эцеңнәр* (эчегез)*, тип қыстайбыс қунақтарды.*

Көнчыгыш диалектларга хас *-ты/-те* кушымчалы хәзерге заман хикәя фигыль күбесенчә *-ди* формасында кулланыла: *борадим – әд.* борам, юклыкта – *борбайдим* – бормыйм; *борайдиң* – борасың, *борбайдиң* – бормыйсың; *боради/бораты/борат* – бора, күплектә *борадиләр/борадылар/бораттар* – боралар.

3 нче заттагы нигез форма (*күрә, килә*) *-әй* кушымчасы белән дә ясалырга мөмкин (*күрәй* – күрә, *киләй* – килә) һәм аңа *-ди* күрсәткече ялгана. Берлектә – *күрәйди*, күплектә – *күрәйдиләр.* Юклык формасы: *күрбәй* – күрми, һәм шуларга *-ди* күрсәткече ялгана: *күрбәйди*. Мисаллар: *Килбәйдем* – килмим. *Минзифаға булышай* (әд. булыша). *Қунаққа киләйдиләр* (киләләр). *Оцрашуға килбәйди* (килми).

Күптән үткән заманның ике формасы күзәтелә: *-ған/-гән/-қан/-кән + иде* формасында (*барган иде*) һәм *даған* сыйфат фигыль + *ите* ярдәмче фигыле

ярдәмендә (*барадағанар ите* – бара торганнар иде). *Минем атам бик матур йырлыйдаған ите* (әд. җырлый торган иде). *Урамда, су буйында йәйен йөридағаннар, уйныйдағаннар иде* (йөри, уйный торганнар иде).

Ул *-адаған/-отоған* (-а торган) формалы хәзерге заман сыйфат фигыльгә нигезләнеп тә ясала. Үткән заманда даими булып тора торган, гадәти булган эшне белдерә: *Лисичканы, груздасын йыштырма* (җыеп) *қайтып, тостап қышқыга әзерлидәгәнбес. Фронтовикларға дип бәйлидәгәнбес бийәлий, наски. Өцәр сутый ашлыққа йер қазыйдағаннар көнөнә.*

Бер юнәлеш урынына икенче юнәлеш формасын куллану: *Мамаwына* (әд. дәү әнисенә) *барышып* (барып) *килделәр. Салқын мунцаға кереп тә йуыша* (юына) *идем. Цәйе суымаған* (суынмаган). *Көлөшләнәбес* (көлешәбез) *шулай. Хәйер өләп* (өләшеп), *мулла цақырайлар. Тотондым йылашқалы* (< йылағалы – еларга). *Кецкенә цақта мунцада мине инәм йуыша* (юындыра) *торған иде. Мат' мачеха йыштыра* (җыя) *идем.*

Әдәби телдәге *-ырға/-ергә* формасындагы инфинитив белән беррәттән барлык себер диалектларындагыча *-ғалы/-гәле* формасы хас: *Сөйләйгәле қушай сиңә* – Сиңа сөйләргә куша. *Тыңнағалы* (әд. тыңларга) *ғына йаратам. Мин мишкә* (гөмбә) *йыштырғалы* (җыярга) *йөрим. Көйөм дә йуқ йырлағалы* (җырларга). *Ғыйлмима мамай* (әби) *ике сәғәткә қәдәр йомға көннө йуwашқалы* (юарға) *йарабый, мондой эште эшләгәле* (эшләргә) *йарый дийә ите. Қайа уңай сатқалы* (сатарга) – *барадағанмын. Ышкулға килгәле* (килергә) *тийеш.*

Сыйфат фигыль: *-адаған/-атаған/-атқын* (әд. *а торган*): *Он саладаған саwыт* – Он сала торган савыт. *Чәчкә тағадағаннары йуқ. Элек әнийемнең әйберләр, кийемнәрде саладаған сандығы қалған иде. Пецән цабадаған* (чаба торган) *йергә китәй.*

*-ганчы/-гәнче* формалы хәл фигыль сөйләштә *-ғынцы/-генце, -ғанцақ/-ғынцық/-генцек* вариантларында кулланыла: *Доғалықты ышкулға барғанцақ* (әд. барганчы) *йөрәдағаннар тағып. Мин килгенце* (килгәнче) *қайтып киткән.*

Бәйлекләр: *менән/мынаң/мењәң/белән* – әд. белән: *Аның менән* (белән) *күгемәйгә йөрөй дәгәнбес. Циләк менәң йөгөреп-йөгөреп су ташыйдағанбыс. Мин абам* (апам) *мынан вечерға йөрбәйдем.*

Сорау кисәкчәсе *-ба/-бә/-ма/-мә/-бы/-ме* вариантларында күзәтелә: *Хәер қуйдым, доға қылырсыс, әйебә* (әйеме)? *Синең элекке әйберләрең барма* (әд. бармы), *фотоға төшөргәле? Қызың бар түгелбә* (түгелме) *инде*?

Сөйләштә *ғуй/ғой/қуй* (рус. ведь) раслау кисәкчәсе кулланыла: *Циккән цепрәкттәрде музейға бирдем ғуй* – Чиккән чүпрәкләрне музейга бирдем бит. *Куршеләр қуй* (бит), *кереп курәрбес.* Омск өлкәсе татарлары белән чагыштырганда, яуштә-чат сөйләшендә бу сирәк күренеш.

### Синтаксик үзенчәлекләр

Исем-исем сүзтезмәләрдә, компонентлары нисбәтлекне белдерсә, бәйләнеш бернинди

кушымчасыз да була: *Сез йақта* (әд. сезнең якта) *пешергәле осталарма* (осталармы)? *Қызылқаштан* (авыл исеме) *урлады иртән қорбан бәйрәм көн* (көнне). *Бестә Черна Речка мулла* (мулласы) *йөрәй көбесенцә. Менә тиз* (тиздән) *булай Ураза бәйрәм* (бәйрәме).

Сыйфат-исем сүзтезмәләрдә сыйфатның кушымчасын төшереп калдыру: *Ул ал урамда* (әд. алгы урамда) *торай иде, без арт урамда* (арткы урамда) *торай идек. Цийған* (чегән) *қаш* (тау) *пашында ал урамда* (алгы урамда) *торадаған ите. Пестеке Садоwайа, ал* (алгы) *урамнықы – Берегоwайа, анан ар* (ары) *урыс аwыллары.*

Хәрәкәтнең төшем яки урын-вакыт ноктасын белдерә торган исемнәр баш килештә куллану очраклары да бар: *Бабайым ишеғалды* (әд. ишегалдында) *нәрсәдер йасап тора икән. Ишеғалды* (ишегалдын) *йабабыс бит – ул сарай.*

Кайбер фигыльләр башка килешне таләп итәләр: *Бала берас айақтан* (әд. аякка) *баса башласа, утыра башласа, ағац крават инде. Аwылда* (авылны) *пычратмаңнар* (пычратмагыз), *күл йанына килмәңнәр. Чигү белән ун йәшләрне* (яшьләрдә) *булғандыр. Без бәләкәй булғанда Рәхим бабай безне* (безгә) *әйтәй иде: «Кеменәр йақшы йөгерәр, айылны* (авылны) *түгәрәккә әйләнеп кем алдан чықса, аңа бер камфит» тип.*

Җөмләдә *туу, тудыру* сүзендәге аермалыклар: *Ә мин бер бала менән икенце балам, икене тудым* (тудырдым/таптым) *Байазитовтан. Бу аwылда туылып* (туып), *монда үстем. Пала тудым* (тудырдым), *қайнинә сем'асын қарадым. Тетка дүрттебиште туған* (тудырган), *ул белә инде.*

«Син ничәнче елгы?» дигән сорауга, *-ғы* кушымчасы урынына *-нықы* кушымчасын куеп әйтү: *Мин қырық беренце йылнықы* (елгы). *Минеке әби белән бабай 1887 йылнықы* (елгы) *берсе. 1931 елнықы* (елгы) *мин булған.*

### Лексик үзенчәлекләр

***Затларны белдерә торган сүзләр:*** *баба* – авыл бабайлары, *баба/бабау* – дәү әти, *мамай* – әби, карчык, *мама/мамау* – дәү әни, *нәнәм/нәнә/инәй/инә* – әни, *тәтә/тәтәм/әттә/ата* – әти, *күкәм/күкәләр* – энем, сеңлем, *аба/абам* – апа, *әкә* – абый, *инә/әни* – ирнең әнисенә дәшү, *ата/әти* – ирнең әтисенә, *кендегәц әби* – кендек әби.

***Тормыш-көнкүреш белән бәйле сүзләр:*** *тора* – шәһәр, *йаташту/йаташлы йорт* – катлы (этажлы) йорт, *сарай* – ишегалды, ябык йорт алды, *аран* – сарай, *синек* – ишегалды, веранда, *көпкә* – кечкенә җылы абзар (тавыклар, бозау асрар өчен), *кәзүнкә/кәзүңке* – чолан, *кәтәк* – кетәк (рус. курятник), *әцәлдек* – туалет, *басмақ* – күперчек, *пиц* – мич, *кәцәк* – тәрәзә кырые (эчке яктан), *терәстү* – тәрәзәләр, *чанақ* – кечкенә чана, *табатан* – таба, *шимовка/чимовка/цимовка* – күмер ала торган соскыч, *келүкә/қыйчауғач/кәкре тимер* – кисәү агачы (кочерга), *цумец* – чүмеч, *суқма* – киле, *сәкәлүк/цәкәлүк/ықлау* – уклау (рус. скалка), *туқмақ* – төйгеч, *типшә* – он иләр өчен агач савыт, *түбә* –

түшәм, *цәй тәринкәсе* – чынаяк тәлинкәсе, *шама* – чәй чүбе (рус. остатки заваренного чая, чаинки), *шәрәмнек* – сукыр лампа, *өстәл* – урындык, *зур өстәл* – өстәл, *себерке* – миллек, *тырмаwыц* – тырма, *могол* – чүмәлә.

***Кием-салым, чүпрәк-чапрак:*** *пима* – киез итек, *сырға* – алка, *қуштақлы итәк* – бала итәкле, *мәрцән* – мәрҗән, *кибәц* – кәпәч, түбәтәй, *байбақ* – оек, *тағыйа* – бүрек, *қоршау* – тәрәзә пәрдәләре, *күчәгә* – чаршау, *йастық* – мендәр, *фәрдә* – пәрдә.

***Аш-су:*** *қазы* – казылык, *күч/күшт* – ит, *чегелдәк* – бавырсак, *туач* – паштет, *лүпсә* – киптереп төелгән шомырт, яисә шуңа шикәр кушылып ясалган ашамлык, *бәдер* – черек бәрәңге күмәче, *хәлвә* – камырын токмач рәвешендә кисеп ясалган чәкчәк.

***Терек һәм терек булмаган табигать:*** *боға* – үгез, *кәзә* – кәҗә, *песи/мыжық* – мәче, *көцек* – эт, *қуй/мәшкә* – сарык, *әтәц* – әтәч, *цебен* – черки, *майған* – үрдәк, *цыцқан* – тычкан, *цалца* – талпан, *утрац* – утрау, *эт борны* – гөлҗимеш, *күгәмәй* – кара җиләк, *күк йеләк* – кара бөрлегән, *қарлыған/қарағат* – карлыган, *малан* – балан, *таш* – төш (рус. косточка), *күбергән* – кыр суганы, *ләпләк* – чөгендер, *қы(з) цылца* – кызыл чөгендер, *мәшкә/мишкә* – гөмбә, *пыяс* – суган, *мәркүп* – кишер.

***Эш-хәрәкәтне белдерә торган һ.б. сүзләр:*** *йетешегес* – ашагыз, *йыштырғалы* – җыярга, *әкиләләр* – алып киләләр, *қырсый* – кисә, *тиргәү* – җыю, әзерләү, бизәү (мәсәлән, бирнә әзерләү, йортны кирәкле әйберләр белән бизәү), *қурқыған* – курыккан, *туған* – тудырган, *йаман* – начар, *төнен* – төнлә.

Түбәндә экспедиция вакытында яуштә-чат, калмак сөйләше вәкилләреннән язып алынган, авыллар тарихын һәм халык традицияләрен чагылдырган материалларның кайберләре тәкъдим ителә. Себер татарларының фонетик, грамматик, лексик үзенчәлекләре һәм аларга хас булган гореф-гадәт, йола һ.б.лар сөйләү үрнәкләрендә аеруча тәэсирле яңгырый. Текстларда сүзләрнең әйтелеше транскрипциядә бирелә. *Я, ю, е* хәрефләре урынына [йа], [йә], [йу], [йы], [йы], [йе] авазлары, өстәмә билгеләрдән [w] – ирен-ирен өрелмәле тартык аваз һәм [қ], [ғ] – тирән тел арты тартык авазлары кулланылды.

### Авыллар тарихыннан

***Омайыл/Умаул авылы.*** Орысца ул Барабинка, ә татарца – Омайыл дип аталадый. Аилның (әд. *авылның*) исеме Ом – судан цыққантыр, ул порон заманнан су буйында торадый. Ом-су Том-суға Қафтан аилдан йырақта төгел ағып батай (*төшә*). Омаил бек поронғы аил. Аны 1575 йылда Пономаревтарың (муәзин ул булған) бабайларнықы бабайлары баштаған дип әйтәдийләр. Анықы (*аның*) тоқомнары аилда бестеке заманға қәдәр торадыйлар. «Йарти Омаил – Пономаревтар, йарти – Абанейлар», – дип келеп әйтеп қуйабыс. Алардан башқа аилда көп (*күп*) «килгән кешеләр»: Измайловтар, Қамаловтар, Сайдашевтар Қазан йақтан (*ягыннан*), «тоболоқтар» Абанейлар, Орта Азийадан –

Хайровтар, аннан соң Муксуновтар Томаулдан (*авыл исеме*), Айбаттар, Сайфамлүковтар. Бик көп Үтәгәновтар, Мамашевтар һәм башқалар. Аилдағы йорттар бетеннәй электән үқ ағацтан салынғаннар. «Тора (*Томск шәһәре*) булбаған әле, ә бестеке Омаил булған», – андый бабайлар бескә сөйлидиләр. XX ғасырнықы башында, Омаил бек зор, йәмнү (*зур, ямьле*) аил болған: ике йаташту (*катлы*) йорттар, зор матур терәстү (*тәрәзәле*), йалт иткән тимердән өй баштары – бай аил! 1929 йылдан соң аилыбыс йарлу булды. «Раскулачивание», «саботаж», «колхоз», «сослать» – йаңы сөстәр (*сүзләр*), йаңы кежеләр (*кешеләр*), йаңы рәистәр аилыбысты йелгә тараттылар. Мәцетте йаптылар. Мәцеттеке қәләмнәренә (*келәмнәрен*), циккән кийестәрнә, паластарны, қораннәрнә арбаларға тийәп исполкомга әкиттеләр. Аил өскәрде (*үзгәрде*). Хәзер аилда көп орыстар, цит иллә́рдән килгән кешеләр торадыйлар (*торалар*). Бәребер минеке аилым иң матур, йәмлү, йанға, күскә (*күзгә*) сикемнү (*сөйкемле*).

*Умаул авылында яшәүче*
*Абанеева Әминәдән*
*язып алынды. 2015 ел*

***Тахтамыш (Кызыл Каш) авылы.*** Борон заманда бестең бабаларыбыс йырақ йерләрдән күцкилгәннәр (әд. *күчеп килгәннәр*). Йахшы йерләр эстәгәннәр (*эзләгәннәр*). Анда-монда туқтап қарағаннар. Ошаған урын тапмағаннар. Ту йере йәмсес, ту суы тәмсес булған. Зур, киң сулар буйлап та барғаннар, күлләрне дә үткәннәр. Бара торғац, бер матур урынға кил'еткәннәр. Бер йақта зур су ағай (*ага*) икән, аңа чип-чиста кецкенәрәк суның тамағы төшәй икән. Шул кецкенә суға Ауды дип исем биргәннәр дә, аның тамағыннан үргә киткәннәр. Бик матур, бийек йарлу урынға килеп йеткәц, шунда туқтағаннар. Су буйлап йеләктәре пешкән шоморттар, қызарған эт борно (*гөлҗимеш*) үсәй икән. Суы бик циста да, тәмнү (*тәмле*) дә икән. Бийек йардан тире-йақтар ап-ацық күренторай икән. Бестең татарлар белән қала урысы килгән булған. Ул сораған: «Где дома будете ставить?». Болар әйткәннәр: «Бу йердә туқтамышбыс». Шуннан урыс қала башлығына «Юрты Туктамышевы (Тахтамышевы)» дип йасқан. Бу аwылның исеме булқалған (*булып калган*).

*Кызыл Каш авылында яшәүче*
*Әбдрәшитова Зөмәрә Минһаҗ*
*кызыннан (1936 елгы) язып алынды.*
*2015 ел*

***Омайыл/Умаул (Барабинка) авылы.*** Теге йақтан, Булгарийа йақтан килгәндә тегүцеләре килгән. Икеме-өцме семйа ғына килгән. Чуқындырғаннан қацып килгәннәр бесненңке (әд. *безнең*) Умаулға. Скрипачи килгәннәр. Бай кешеләре килгән: Сөләймановлар, Исмәғыйлевлар... Аннан инде Сөләймановлар Понамаревка әйләнгән. Мәзем булып эшләгән мәчеттә. Исмәғыйлевлар Измайловка әйләнгән. Урыслар әйләндергәннәр. Аннан инде қушылғаннар. Қурчақлар килгән. Қурчақ уйнауцылар менә Барабинскийда. Цепрәктән матур

қурчақлар йасап уйнағаннар. Башта чучелодан, ағацтан йасауцылар булған. Монда килбәгәннәр алар. Мәчет салғанар. Тахтамышта булған оноғы, Чиңгизханның оноғын озатқан. Тыңнамаған күрәсең. Йасақ түләгәннәр мондағылар Тахтамышқа. Тахтамыш ханы булған. Мангуллар нимәгә (*нәрсәгә*) табынғаннар. Чучело йасағаннар. Безнеңкеләр қушыла башлағаннар алар менән. 605 йыл аларға. Безгә дә еде йөзме йыл, Умаулға.

Безнекеләр килгәндә алар матур бүрәнәлү йорттар салғаннар. Алар зоны йердән килгән. Ә болар йурты булған. Шул Тахтамыш ханнары. Ә тегеләр инде йорт салғанар тиз генә. Монда барып, Тахтамышқа қаршы урнашқан булғаннар. Костерларниләр, монда матур йер. Мәчет, Том (*елга*) күренә матур йердән – йарда – бийек йердә. Цүпләр, әллә ниләр чүбәннәргә атып-атып киткәннәр. Болар булған инде. Болар монда йеннәр икән дип, тегендә киткәннәр, Умаулға түбәндәрәк. Скрипачлар, музыкантлар, тегүчеләр булған. Орыслар (*урыслар*) соңрақ килгән. Килә-килә килеп йеткәннәр монда. Мәскәүдән, Қазан йақтан килгәннәр. Матур қалық (*халык*) булған безнеңкеләр. Зәңгәр күслү (*күзле*), бийек. Ә болар өләнешкәннәр, Томныңқы теге йағында инде Кемеревский област'тән. Берсе инде қалмақлар. Алар да төркөй ғуй (*төрки бит*). Берас йәшелрәк күслү. Рыжоватый. Матур төгелләр. Алар бер-берсе беләән қушылғаннар. Ә черкеслар матурлар. Минең бабамныңқы хатыны үлгән. Ул аны алған. Өләнгән. Шул черкесларныңқы. Шул токомға мин киткәнмен.

*Умаул авылында яшәүче*
*Әгъләмова Шәрфүк Рәҗәп*
*кызыннан (1933 елгы)*
*язып алынды. 2015 ел*

### Өйләнешү, туй йоласы

Мамауныңкы (эд. *дәү әниемнең*) матур әкәсе (*абыйсы*) булған. Өләнергә (*өйләнергә*) кирәк ғой (*бит*). Ә өйләнергә барғалы үзләре танышмай. Әнисе-әтисе барып сорашай. Үстәре дә бай. Байырақ кирәк дигәннәр. Күзләгәннәр. Бу байның ике қызы бар дигәннәр. Шулай булған электә: болай танышу йуқ, инәй-аталар барып күрә. Қызларын күрсәткәннәр матуррағын. Сөләшәләр (*сөйләшәләр*). Аннан сон (*соң*) малайына әйтәйләр. Малайны китерәйләр. Сөләшеп қуйалар. Ниқахқа киләйләр. Ә олосы шадра икән. Малай күрбәй әле аны. Халық инде белә кемне биререн. Бер-берсен күрмичә (егет белән кыз) свидетели йаwап бирәй: «Ризама?» – «Риза». Аннан суң бикләп қуйалар қызны. Қызлар башта киләй. Кийендереп утыртып қуйалар. Монда бите йабылған. Йегетләр гармошка менән киләләр, йырлайлар. Йегетне қалдырып цығып китәләр. Бу килгән дә: «Йөзөңне күрсәт инде, қатыным», – дигән. Ачса, шадыра рыжий нивиста утыра...

Аннан соң икенце көннө кийендергәннәр инде. Алйапқыц менән. Самавар артында утырай, цәй салып торай килен. «Инде әйдә, – ди, әбийем сөйли, – килегезнең қулыннан цәй эцегес». Әйдәгес, дийә. Кердек, битемнән как будто ошпарили дийә. Утыра

шадыра ҡыз дийә. Менә шул. Йегеткә ошамай инде. Ә йарамый кире боролғалы. Апҡайтып китәләр. Икенце атнада тегендә туй, йегет йаҡта (*егет ягында*) туй. Придан менән ҡыз килә. Болар инде апкиттеләр придан менән. Аннан икенце килгәндә кодалар киләдаған. Туй була. Әпкитәләр ҡызны йегет менән теге йаҡҡа, ҡунаҡҡа. Ҡунаҡтан ҡайталар – син мин любов' аларның бик була. Соңыннан ул йегет балыҡчы бабай булды. Килгән кешеләргә цәй ҡайнап торай. Күңелле йәшәделәр. Алар йеде бала туды (*тудырган*). Без аны йараттыҡ әби wаҡытында. Әйбәт әби иде ул. Бабайы матур иде. Матур-матур балалары туа. Шадра балалар булбый. Йегет кеше (бабайыбыз) ҡарараҡ иде. Бу йаҡҡа тартҡан. Әби дигән шадра ак-рыжоватый ҡыз – ҡалмаҡ иде.

*Умаул авылында яшәүче Әгъләмова Шәрфүк Рәҗәп кызыннан (1933 елгы) язып алынды. 2015 ел*

### Яңа туган бала белән бәйле йолалар

***Баланы тәрәзә аша чыгару йоласы***. Гел мамайлар (*әбиләр*), кендегәц әбиләр (*кендек әби*) менән бәбәйләдем. Ике рәт игезәкләр булды. Торбай балаларыбыс. Бәбәйлим дә дөрт ай йарымда, пиш ай торайлар. Йәш тә еде көн тордо Ҡадиморат исемле малайым. Аннан ике игезәк малайларым булды. Менә дөртенце ҡысым. Менә Сабирҗанны алладан сорап башҡа әбидән китердем. Тәрәсәдән ҡысымны. Бәбәйләгәц тәрәсәдән алды бабайым. Менә теләп алған балам. Шуннан монысы йәшәп китте.

***Бәби туйы.*** Шул исем ҡуштырабыс инде анда. Бер атнаданма (*атнаданмы*), ике атнаданма. Хәйер өләп (*өләшеп*), мулла цаҡырайлар.

*Яүштә авылында яшәүче Кабеева Факизә Абдулла кызыннан язып алынды. 2015 ел*

### Кием-салым, бизәнү әйберләре

Бүректе тағыйа дийәйләр иде элеккеләр. Элекке хатыннар монда матур энҗеләр менән шапкалар кийәйләр иде. Оцон цуҡлы аҡ шәлләр йабыналар иде. Цәцләренә үреп тәңгәләр тағалардаған. Бишмәт бар иде. Музейға бирдем ғуй. Минең йеңле. Муйынца тағадаған. Монда цигелгән. Әнийемнеңке бишмәте булған. Ул придан белән килгән. Аныҡы асты колонок, сары ул. Күлмәкләр бөдрә-бөдрә итеп. Халадай (әд. *халат кебек*) йеңнәре киң. Итәкләре кат-кат, ҡуштанлы (*бәбәй итәк*). Әбийемнең сандығыннан бишмәт алып, колонокларын сүттем. Ике ҡулны тығып йөрә (*йөри*) торған муфта тегеп утырайлар иде. Ә бу бархат. Монда мех белән. Собол' йәнлегенеңке. Мин теккәле (*тегәргә*) өйрәнгән идем шапкалар. Башларға мех менән эшләтелгән бүрекләр. Ҡалфаҡ, түбәтәй циктем. Оста цигәйдем. Ҡатыннар шәлләр, йаулыҡлар йабынадаған. Шәлләр кәзә, сарык йөнөннән (*йонынннан*). Кәзә тотучы булбады. Бер әбей генә оста тотто. Сез (*сезнең*) йаҡта кәзәләр тоталар. Шәлләр йахшы. Киндер утыртылған. Теге йаҡтан, Булгария йаҡтан килгәндә цигүцеләре килгән. Икеме-өцме сем'йа ғына

килгән. Цуқындырғаннан қацып килгәннәр бестеке Умаулға. Бездә лапти кигән кеше булмады. Пима (*киез итек*), галош кигәннәр. Ойык кисәк инде, ойықты байбақ дийә иделәр. Сестә тула ойоқ. Бестә йуқ тула ойоқ.

*Абытай авылында яшәүче*
*Юнысова Зөрия Гали*
*кызыннан (1931 елгы)*
*язып алынды. 2015 ел*

Инәмне (әд. *әниемне*) белмим, но мамам (*дәү әнием*) чәченә үреп тәңкә тағай иде. Безнең чәчебес осон (*озын*) буладаған. Хәзер қайчы алам да, қырц(ш)ыйм-кырц(ш)ыйм (*кисәм*) да атам. Қолаққа сырғалар (*алкалар*) кийәләр иде. Мәрцән (*мәрҗән*) бар иде. Батинкы, түфлә, үтек (*итек*) кийә идек. Үтекне йәй, йаз, көс кигәннәр, қыжын (*кышын*) – пима (*киез итек*). Мамайлар осон күлмәкләр кийәдаған ите. Башқа түбәтәй кийәдаған ителәр. Йаулық бәйләп. Қыш көнө ирләр тун кийәдағаннар, без – тиләгрейкә, бишмәт. Сарық йөнөнән үсем (*үзем*) эрли идем. Йөн наскиләр кидек. Орцық менән эштәп. Тәрәзәгә қорғалы фәрдә, түл'. Кыржуалар бәйлий идем. Минеңке инәм (*минем әнием*) пал'то тегә иде ул. Пал'то тегеп сатып, бесте ашатты.

*Казан авылында яшәүче*
*Гобәйдуллина Гашурә Исмәгыйль*
*кызыннан (1928 елгы)*
*язып алынды. 2015 ел*

### Аш-сулар

***Хәлвә, цәк-цәк, самса...*** Бәйрәмнәрдә самса пешерелә. Уратылған. Зур пәлеш пешерәләр иттекен, бәрәмәц, пирошкилар. Йә цәк-цәк кемдер пешерә инде. Хәлвә қатыралар. Цәк-цәкне қандый (әд. *ничек*) пежерәсен (*пешерәсең*), хәлвәне дә. Хәлвәгә, например, пиш күкәйгә мондый кружоктар йасыйсың да, аны йәйәсең дә, әз генә қоротасын. Аннан кисеп-кисеп лапша кебек, майны жарит' иттеләр. Хәлвә пер майда ғына пешерелә. Ә цәк-цәк өц майда пешерелә. Перенце ақ майға саласың, аннан суң әз эссүгә (*эссегә* < *кызуга*) саласың, аннан инде бик эссүгә саласың. Пер майны жарит' итеп алсаң, лапшасын да кисеп-кисеп әзерләп аласың да, сал да сал, сал да сал. Озонлықта тотбыйцы (*тотмыйча*) ғына. Палды (*балны*) қайнатасың да петерә пешереп алғац, палға бутыйсың, саwытқа саласың да, тапап-тапап қуйасың. Пер чәшкегә пер чәшке шикәр саласың икән, пер паллитрга пер паллитр шикәр саласың. Палны қайнатасың. Суwақ (*суык*) суға салып. Күрәсең, суwақ суда ойышса, өстенә паливат' иткәле. Қайнамаған палны қойсаң, таралып торай. Йәбешбәй (*ябышмый*) пер-персенә. Палны қаладан алабыс. Алтайскины.

*Яүштә авылында яшәүче*
*Курбаева Румәнә Әхмәтвәли кызы*
*(1950 елгы) һәм Касанова Тәнзилә*
*Сәрвәретдин кызыннан (1941 елгы)*
*язып алынды. 2015 ел*

***Церек бәтер.*** Элек церек бәтер (әд. *черек бәрәңге күмәче*) ашағаннар. Көзөн қалған бәрәңгене йыwасын, әрцисен. Тосын-нийен саласын да, менә сиңә (*сиңа*) бәтер. Аны табатанда (*табада*) бешерәсең. Бер өц бәрәңгене қырадаған, аннан икесен бергә басып, қаладаған.

***Балык тостау, кыздыру.*** Балық каптит итәдаған. Бабайым балықцы иде. Аппарып сатасың. Қалаға да апарғалый даған. Қайа уңай сатқалы (*сатарга*). Анда бит тотайлар. Қацып-қотып сатайлар. Элек разрешенйы булмыйдаған. Сөт битонына тутырадаған да, көйәнтәләп барадаған, йәнәсе сөт апарадаған. Аны сатадаған. Бабай балық тотадаған, мин каптит итәдаған. Ул эштәгәц, берни эштәй албайдим (берни эшли алмый идем). Фермада скотник иде бабайым. Қайта да миңә қалдырай (*балыкны*), үзе эшкә китәй. Мин инде монда балықны йә тостыйм, йарит' итәм, каптит' итәм. Шундый йәшәдек инде – ацтан үлмәстән (*үлмәс өчен*/*үлмәскә*).

***Мишкә, клюква йыштыру.*** Абам (*апам*) менән (*белән*) клюквага йөрөйдәгәнбес. Қышқыға әзерләйдәгәнбес азық. Мишкә (*гөмбә*) йыштырма (*җыеп*) қайтып, тоздыйдағанбыс. Ә клюкваны сатқалы. Кәрәсин, сабын – андый ниләр алғалы (*алырга*). Ул бақытта бит бернимә (*бернәрсә*) йуғ иде.

***Лүпсә.*** Шоморттан лүпсә (*киптереп төелгән шомырт*) йасай идек. Сатқалы аны. Лүпсә қышқыға пешергәле. Хет пирошки йаса. Лүпсәгә элек сукма булалған. Элек сукма (*киле*) мынан лупсаны йасаған. Шоморттты мисарубкадан крутит итә дәгәннәр сөйәкләре (*төшләре*) калсын өцөн. Wақ булалған. Суғып ала торған. Шомортқа, қарлығанға йөрәдәгәннәр. Аларны қалаға саттық.

*Яуштә авылында яшәүче*
*Сәйфетдинова Мөнирә*
*Мифтахетдин кызыннан (1925 елгы)*
*язып алынды. 2015 ел*

***Урама.*** Ураманы майда пешерәләр. Ун күкәйгә 150 грамм май саласың. Қаймақ. Шикәр әз генә. Тозын, әчетке саласың әз генә, қабартасың. Бер қабарып чықтымы, аннан әwәләп, җәйеп-кисеп. Көрәк шикелле тайақ белән урыйсың. Шуның белән қайнап торған майға төшөрәсең. Менә бес инде ураза бәйрәменә пешерәбес, алла бирса. Аны монда ғына пешерәләр. Пәрәмәч, пылау да пешерәләр.

*Калтай авылында яшәүче*
*Фәхретдинова Рәйхана Файзрахман*
*кызыннан (1938 елгы) язып алынды.*
*2015 ел*

### Ышанулар

***Суныңқы ийәләре*** йәшәй. Әйтәләр иде, ышанбай идем. Бер-wақыт Е(и)патоwаға шышкаға киттек. Безнең каблацок бар иде, утырдық өцебес киттек тә. Калароwаға йетеп утырғанда, суда безнең көймәне бер нәрсә йебәрми. Без килеп йеттек Калароwоға. Қазанаулға безгә төшкәле кирәк. Йебәрми. Фәхри әйтә: «Менә монда йегерме тийенгә йөзөк йасаған идем», дийә. Алды да мондый терп (*иттереп*) төшөргән иде, киттек тә қалдық – су анасы бесне йебәрде. Ату әйтәй иделәр, мин ышанбай идем. Су инәсе бар. Менә анандый будық, орехка бардық. Ипатоwо йырақ бит. Өц цақрым тау пашына мендек. Көймәне қуйдық та Нуриман безне апкитте. Йәйәү апкитте, анда мендек. Быйақтан анда безне бәйрәмгә дә апарғаннар иде. Савхузлар қушылышқанда. 1953 йылда Иптоwада булдық бәйрәмдә.

Менә Линнур да күрде микән су анасын. Аннан телсез булып

қайтты, су анасы тотты дип қайтты берwақытны. Аннан суң аны «Мат' воды» дийә атый башладылар. Су анасы аны тотоп, ул нишләгән. Ул анда йатып сөйләшәлмичә. Анандый қайтты бит.

***Урман ийәсе*** адаштыра. Эшләп йөргән wақытыбыс иде әле. Нәрсәгәдер ойоштырғалы бардық. Кафтаннан ары киттем. Хәмидәләр қайтып китте. Мин барам. Билцән күленә йетәм. Анда су анасы бар дип тә әйтәйләр иде. Билцәндә адаштыра. Мин тағын китәм дә, Умауыл артына қәдәр барып йетәмен. Өц мәртәбә көн буйына адашып йөрдөм. Билцәнгә йетәм. Тағын башым әйләнеп, бер минуттан тағын китеп қалам. Аннан соң әйттеләр: «Билцән бик йенле, йаман», диделәр.

*Кызыл Каш авылында яшәүче Әмирханова Гәфифә Галиәскар кызыннан (1928 елгы) язып алынды. 2015 ел*

### «Вечерлар» уздыру

Элек клуптар, шкуллар булбаған. Шкулларны кешеләрнеңке өйләрендә уқытқаннар. Өйләрен биргәннәр. Йуғары өйнеке йортында шкул була торған. Без анда уқыдық инде. Вечер үткәрергә дә өйләрен биргәннәр мамайлар (әд. *әбиләр*). Утын китерсәләр, вечер итеп уйыннарны қышқы wақытта уздырғалы (*уздырырга*) дип биргәннәр. Йәш балаларға әйтәләр: «Улым, бар пер ат менән урманға барып утын китер». Китереп бирсәләр, ул сиңә өйөн бирәйдаган. Исмай бабаңныкы әнисе Фәрхияба гел өйөн бирәй иде. Вечер йасатай. Бес, бәләкәй балалар, вечерға цақырып йөрәбес. «Кемдә булай?». «Ишмәй бабамныкы өйөндә». Менә өй сайын бес цақырып йөрәй идек.

Элекке мамайлар шулай қыйландырғаннар. Йуқ торғаннар инде мескеннәр: утын китереп өйләрен биреп, вечерлар йасатқан. Мамай утырып торай. Балалар шыр-шыр, шыр-шыр киләй. Ишекте ацып торай, йабып торай. Ул мамайым әйтәй: «Үзем андый ницек утырған». Балалары нийе бергә уйнайлар. Әбей қарап утыра инде, ташлап цықмай өйөн. Әбейләр кереп, тезелешеп, йәшләрнең уйнағанын, күреп утырған. Тотон қуйып (*тотынышып*), йырлап, йыр мынан, йыр мынан. Бию көйөн уйнасалар, төшөп китәрләр бийергә балалар. Ике кеше қара-қаршы бийерләр. «Күпер», «Круг», «Третий лишний», «Алды сулар»н уйныйдағанбыс. Кем йөргәннәр, кем танышқаннар. Цигүләр цигеп, бәйләнеп утырғаннар. Мендәр аwыстарын бәйләп, кидереп ақ материалға, простын'аға бәйләп. Кыружыwалар бәйли идек.

*Абытай авылында яшәүче Юнысова Зөрия Гали кызыннан (1931 елгы) язып алынды. 2015 ел*

***Булатова Миңнира Рәхим кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре*

УДК 069.5

*Р.Р. Солтанова*

# БОЛГАР ДӘҮЛӘТ ТАРИХИ-АРХИТЕКТУРА МУЗЕЙ ТЫЮЛЫГЫНДАГЫ «БОЛГАР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ. МЕҢЬЕЛЛЫККА СУЗЫЛГАН ЮЛ» ИНСТАЛЛЯЦИЯСЕ

В статье дается характеристика художественной экспозиционной инсталляции «Болгарская цивилизация. Дорога длиною в тысячелетия» Музея Болгарской цивилизации (г. Болгар).

Автор раскрывает приемы использования современного искусства (инсталляции), созданного из различных элементов – предметов, текстовой, визуальной, видеоинформации. Доказывается, что сплав различных художественных решений, где присутствуют предметные объекты, документы, графические и объемные воспроизведения исторических образов, создает цельный визуальный спектакль. Указывается точность выбора пластических средств для раскрытия темы становления и развития болгарской цивилизации от ее истоков до времени Казанского ханства, образов и сюжетов Великого Болгара в золотоордынскую эпоху, истории изучения древнего Болгара (монументальные композиции из стекла, «объемные картины», видео, коллажные инсталляции).

Особое внимание уделяется световому оформлению, цветопластическому решению монументальных композиций, использованию витрин, декоративных ширм, макетов в создании образа восточного города.

**Ключевые слова:** Музей Болгарской цивилизации, музейная экспозиция, синтез искусств, инсталляция, артефакт.

2013 ел Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгында «Болгар цивилизациясе» музеен ачу белән тарихка кереп калды. Бу дөньякүләм әһәмияткә ия булган тарихи объектны реконструкцияләү, реставрацияләү һәм саклау буенча эшләнгән проектның катализаторы Татарстанның беренче президенты М.Ш. Шәймиев җитәкләгән ТР-ның тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен яңадан торгызу Республика Фонды булды. Музейның концепциясен Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, Казан (Идел буе) федераль университеты, А.Х. Халиков исемендәге Археология институты белән берлектә эшләде һәм гамәлгә ашырды. Иҗат төркемендә галимнәр Р.Р. Хәйретдинов, А.Г. Ситдыйков, Д.Г. Бугров, рәссамнар: И.Н. Артамонов, А.П. Леухин, Ф.Р. Вәлиуллин, Р.С. Шиһабетдинов, И.В. Щетининнар.

«Болгар цивилизациясе. Меңьеллыкка сузылган юл» экспозициясе Идел ярларының биек ландшафтына тәңгәл килерлек урында, алты катлы бинаның ике этажын алып тора. Болгарга керү юлында тантаналы «капка» ролен үтәүче монументаль архитектура корылмасы елга вокзалы белән музей функциясен берләштерә. Аның бурычы бирегә килүчеләрне Болгар шәһәрчеге

территориясенә күтәрелүне тәэмин итү генә түгел, ә иң мөһиме – бөек цивилизациянең тарихы белән таныштыру.

Гадәттә рәссамга экспозиция төзегәндә объектларны бизәү (витриналар, стендлар, экспликацияләр, диварларны декоратив-эчтәлекле бизәү һ.б) кебек икенче пландагы эшләр бирелә. Ә монда төрле элементлардан торган заманча инсталляция (табигать объектлары, текстлы, визуаль, видео мәгълүматлар) иҗади музей төзелеше өлкәсендә өр-яңа сүз.

Бу экспозициядә төрледән-төрле стильдәге (объектлар, тарихи документлар, археологик артефактлар тулаем бер визуаль спектакль тудыра. Тамашачы үзен картиналардагы тарихи вакыйгаларның үзгәреп, алмашынып торган үзәгендә кайнаган кебек хис итә. Экспозициянең барлык состав өлешләре дә үзара тыгыз элемтәдә, һәр аерым элемент бербөтенлек принцибы буенча хәл ителгән. Витриналарның композициясе, декоратив монументаль паннолар, мәгълүматка бай интерактив панельләре арт-объектлар итеп күзаллана, әмма шул вакытта алар барысы да аерым сәнгать әсәренә хас булган характерлы билгеләре белән мега-инсталляция элементларын тәшкил итәләр.

«Болгар цивилизациясе. Меңьеллыкка сузылган юл» композициясе өч бүлектән тора – «Төрки цивилизациянең чыганаклары», «Борынгы Болгар: шәһәр тормышы», «Болгарны ачу һәм өйрәнү тарихы». Өченче катта урнашкан мәйданда Болгар цивилизациясенең барлыкка килүе һәм Казан ханлыгы чорына кадәр үсеше тасвирлана. Дүртенче катта урнашкан композициядә Бөек Болгарның Алтын Урда чорындагы күтәрелешенә кагылышлы сюжетлар, борынгы Болгарны ачу һәм өйрәнү тарихы.

Инсталляция авторларының бәхәссез уңышы – тамашачыларда билгеле бер эчтәлекле контекст тудыруга ярдәм итүче пластик чараларны төгәл сайлау. Мәсәлән, «Төрки цивилизациянең чыганаклары» бүлегенең темасын ачу өчен дала культурасы образы кулланылган. Шуңа да экспозиция тарихи археологик артефактлар, борынгы карталарның фрагментлары ярдәмендә формалашкан, ә гомуми пластика стилистикасы петроглифлар белән билгеләнә. Композициянең бер өлеше стена буенча тезелеп киткән һәм анда «картографик кыйпылчыклар», пыяладан эшләнгән монументаль композицияләр, күләмле картиналар, сурәтләре алышынып торучы видео панельләр, асылташлар бер җепкә тезелгән кебек, чиратлаштырып урнаштырылган. Монда композиция төзүнең мөселман сәнгать дөньясы өчен хас булган универсаль принцибы кулланылган – һәр энҗе бөртеге дә кадерле, әмма алар бербөтеннең аерым бер өлешен тәшкил итәләр. Экспозиция декоратив элементларны гына бәйләп калмый, ул хронологик тәртиптә төзелгән һәм тамашачыны тарихи вакыйгалар буйлап сәяхәткә алып китә. Шул ук вакытта периметр буенча төзелгән композиция болгар цивилизациясенең матди байлыгына багышланган залның «кыршавы»

ролен дә үти. Үзәк композиция үзе өч өлештән тора. Беренчесе борынгы төзелеш эзләрен хәтерләтүче экспозицион платформадан гыйбарәт. Андагы горизонталь һәм вертикаль витрина блокларыннан төзелгән корылмалар, табигый тере дөньяны тою хисен тудыра. Объектларны төрле яктан тамашачыга тулаем күрсәтүдә утларның роле аеруча зур. Композициянең икенче өлешендә видео-проекцияле тугыз метрлы экран урнаштырылган. Ул экспозициягә динамик төсмер бирә, күзаллау мөмкинлекләрен арттыра. Өченче өлешне форматлаштыручы төп элемент булып декоратив плафон тора. Ул – күк символы, анда көнчыгыш миниатюр тасвирый сәнгатенең сюжетлары аша җир ланшафтының катлаулы мозаикасы чагыла. Залның бизәлешендә җирне хәтерләтүче төсләр (охра, умбра) кулланылган. Биредә колористик төзелеш бик мөһим, ул барлык цивилизацияләргә дә башлангыч көч бирүче тарихи чыганакларыбызга ишарә итә.

«Борынгы Болгар: шәһәр тормышы» бүлегендә цивилизациянең чәчәк ату, рухи күтәрелеш символы булган яшел төс өстенлек ала. Декоратив панно охра колоритында эшләнгән, әмма яшел фонда ул «алтын» төсмерен ала. Монда да ике өлешле композиция схемасы кулланыла – периметр буенча һәм үзәктә. Периметр сәнгать реконструкцияләре, предметлы композицияләр һәм тематик бүлекләр буенча ритмик бәйләнештә булган декоратив–монументаль паннолардан тора. Әгәр өченче катта инсталляция образының нигезен дала культурасы тәшкил итсә, монда исә үзенең бөтен тормыш-көнкүреше белән көнчыгыш шәһәре образы гәүдәләндерелгән. Биредә бөек Болгар монументаль «планографиясе» белән тематик бүлекләр аша танышырга мөмкин. Тамашачы бер күренештән икенчесенә күчә, Бөек Болгарга багышланган китап битләрен ачкан кебек, аның күз алдында шәһәр тормышы төрле яклап ачыла – дәүләт һәм дин тормышы, шәһәр халкы, аның көнкүреше, һөнәрләре һ.б. Залның үзәк өлеше турыпочмаклы подиум-постамент рәвешендә. Болгар дәүләте «бинасының» логик һәм бербөтен төзелешен символлаштыру өчен, подиум залның архитектура колонналары белән пластик рәвештә бәйләнгән. Подиумның почмаклары, билгеле бер символик мәгънә бирү өчен, болгар шәһәрчеге һәйкәлләренең декор композициясе элементлары белән тоташтырылган. Постамент мәйданчыгына колонна почмаклары буйлап килүче, борынгы шәһәр силуэтларын чагылдырган, декоратив пыяла панель-пәрдә нокта куя. Пыяла аңлы рәвештә кулланылган. Ул инсталляция витриналары һәм сәнгать эшләнмәләре арасында стилистик бөтенлек булдырырга ярдәм итә. Подиумда урнаштырылган алты горизонталь витрина аның дәвамы буларак кабул ителә һәм безне борынгы шәһәрнең үзәк мәйданында итеп тоярга мөмкинлек бирә. Тамашачы үзен дөньяның төрле почмакларыннан килгән товарларга бай булган базарда йөргән кебек хис итә. Моңа ирешергә

витриналарның эчендәге халыклар һәм мәдәниятләрне чагылдыручы образлары белән бергә урта гасырлар картасы да ярдәм итә. Яшел төс, бу очракта да, үз максатына ирешә, төрле витриналар һәм декоратив пәрдәләр ярдәмендә келәм-подиумга әйләнеп, болгар шәһәрчегенең макеты урнашкан композиция үзәгенә тантаналы төсмер өсти.

«Болгарны ачу һәм өйрәнү» дип аталган өченче бүлектә Болгар шәһәрчегенең тарихи планда эшләнгән күренешләре урын алган, аның өйрәнелү тарихы хронологик тәртиптә бирелгән. Композиция горизонталь витриналар һәм коллажлы инсталляцияләрдән тора. Витриналардагы экспонатларның дәвамын археологик рельеф катламнары аша чагылучы сәнгать «тасвирламаларында» күрергә була.

Һәрбер объект, экспозицияләр авторларның бергәләп, иҗади эшләү процессында туган. Монда һәммә деталь, фрагмент, композиция бөтен яктан да уйланылган – тарихилык, сурәтләрне кабул итү дәрәҗәсе, ассоциацияләр тудыру сәләте. – «Болгар цивилизациясе. Меңеллыкка сузылган юл» инсталляциясе тарихи материалны сәнгати тасвирлау чаралары аша чагылдыруның гүзәл үрнәге, бер максат белән янып эшләүче команданың фидакарь хезмәт нәтиҗәсе.

Билгеле, бу – дөньякүләм танылган музейлар дәрәҗәсендәге мәдәни корылма безнең горурлыгыбыз.

ИКОМОС (международный совет по сохранению памятников и достопримечательностей) хисабында Болгар цивилизациясе музее хакында болай диелгән: «он обеспечивает соответствующее и высококачественное представление территории объекта, уже решительно направленное на предполагаемую Выдающуюся Всемирную Ценность г. Болгар…»

**Инсталляция** (англ. installation – урнаштыру, кору, монтаж) – хәзерге заман сәнгать формасы, төрле элементлардан корылып, сәнгать бөтенлегенә ирешкән композиция.

**Әдәбият**

*Шульгин П.М., Иванова И.Г., Калуцков В.Н., Штеле О.Е.* Концепция развития Болгарского государственного историко-архитектурного музея-заповедника // Наследие. Информационный сборник. Вып. 17. М.: Институт Наследия, 2010. С. 93–105.

***Солтанова Рауза Рифкать кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире*

УДК 76:929

***О.Л. Улемнова***

# РӘССАМ ТАВИЛ ХАҖИӘХМӘТОВНЫҢ ИҖАТ ЮЛЫ

(*тууына 80 ел тулу уңаеннан*)

В статье раскрываются этапы профессионального становления, творческого пути и особенности художественного языка народного художника РТ, лауреата Государственной премии им. Г. Тукая Т.Г. Хазиахметова. Отмечается разнообразие видов и жанров изобразительного искусства, в которых он работал: станковая и книжная графика, гравюра, портретная и пейзажная живопись, театрально-декорационное искусство. Подчеркивается глубокий и постоянный интерес художника к национальной теме, поиск им новых форм, новых выразительных средств. Особое внимание уделяется его работе в области оформления книги, где особенно ярко проявились основные особенности его художественного языка, базирующегося на глубоком интересе к татарской культуре и быту, своеобразной интерпретации традиций татарского народного искусства – резьбы по дереву, ювелирного искусства, вышивки, каллиграфии.

**Ключевые слова:** Изобразительное искусство, станковая и книжная графика, гравюра, живопись, театральное искусство, национальная тема.

Тавил Гыйният улы Хаҗиәхмәтов (3.02.1936–25.05.2007) XX гасырның икенче яртысында татар рәсем сәнгатен үсешкә этәргән рәссамнар буынына керә. Ул сынлы сәнгать, портрет һәм театр өлкәсендә эшләүче рәссам, китап һәм графика буенча остаз. Т. Хаҗиәхмәтов Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән 100 дән артык китапка рәсемнәр, татар телендә нәшер ителүче журнал һәм газеталарга иллюстрацияләр, шулай ук төрле техник алымнар белән иҗат ителгән 100 дән артык гравюр (металлга, сөяккә яки агачка чокып рәсем ясау) эшләре белән татар сәнгате тарихында тирән эз калдырды. Аның 40 елга сузылган мөстәкыйль иҗат юлы илебез тарихының төрле этаплары – «Хрущев җепшеклеге» «Брежнев торгынлыгы», «Горбачев үзгәртеп корулары» аша узды. Т. Хаҗиәхмәтов югары профессиональлеге, иҗади иреге, мөстәкыйль рәвештә үзе сайлаган яки заказ буенча алынган бихисап темаларга интерпретация ясаганда ихлас булуы, авторның теге яки бу чорда иҗат иткән әсәренең идеясен төгәл җиткерү өчен туктаусыз яңа сәнгать алымнарын эзләве белән аерылып тора. Татар халкына гына хас булган менталитетны, милли башлангычны әсәрләрендә чагылдыру өчен адекват формалар эзләргә омтылу, аның бөтен иҗат юлында кызыл җеп буларак бара. Болар барысы да рәссам ирешкән уңышларның нигезен тәшкил итте, тарихыбызның төрле этапларында аның казанышларын һәм иҗади мөмкинлекләрен танылуга китерде. 1974 елда ук инде Т.Г. Хаҗиәхмәтов ТАСС Югары Советы

Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде, 1978 елда аңа ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, 1984 елда ТАССРның халык рәссамы дигән мактаулы исемнәр бирелә, 1987 елда Г. Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт бүләгенә лаек дип табыла.

Тавил Хаҗиәхмәтов Саба районының Йосыф-Алан авылында туа. Балачактан рәсем белән мавыгу аны 1952 елда Казан сәнгать училищесына алып килә. Аның педагоглары – Татарстанның рәсем сәнгате осталары В.И. Куделькин, В.С. Подгурский, В.К. Тимофеев. 1957 елда училищены тәмамлагач, ул Ленинградтагы СССР Сәнгать Академиясенең И.Е. Репин исемендәге Сынлы сәнгать, скульптура һәм архитектура институтының графика факультетына укырга керә, станок һәм китап графикасы (гравюра) өлкәсендә эшләүче белгеч һөнәрен үзләштерә. Биредә уку елларында ук яшь рәссам милли темалар белән кызыксына башлый. Диплом эше итеп Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр» романына иллюстрацияләр эшли һәм профессор М.А. Таранов җитәкчелегендә аны уңышлы яклый. Институтта ул гравюра өлкәсендә күп эшли – офорт, литография, линогравюра, ксилография (агачка гравюра) кебек төрле техник алымнарны үзләштерә. Аның үзенә, авылда туып-үскән, йортлар, капкалар, коймалардагы бизәкләрне күргән кеше буларак, агачка чокып рәсем ясау күңеленә аеруча хуш килә.

1963 елда институтны тәмамлап, Т.Г. Хаҗиәхмәтов Казанга кайта һәм актив рәвештә республиканың иҗади тормышына кереп китә. Ул иҗат эшен, күргәзмәләр оештыру, укыту һәм иҗтимагый эшчәнлекне киң җәелдерә. 1963–1964 елларда Татарстан китап нәшриятында рәссам булып эшли һәм аннан киткәч тә бу оешма белән хезмәттәшлеген гомер буена дәвам итә. 1964–1967 елларда «Яшь ленинчы» газетасында, 1967 елдан «Ялкын» журналында эшли башлый, Чаян (1961 елдан), «Азат хатын» (1963 елдан) журналлары белән хезмәттәшлек итә һәм аларда төрле темаларны үз эченә алган берничә йөз рәсемнәре басыла. Моннан тыш ул газета-журнал укучылары белән үз һөнәренең серләре белән дә уртаклаша һәм аның «Яшь рәссамнарга киңәшләр», «Рәсем ясарга ничек өйрәнергә?», «Мин ничек рәссам булдым?» һ.б. мәкаләләре дөнья күрә. 1980 еллар башында үзе белем алган Казан сәнгать училищесында укыта. 1970 елларда театрлар белән дә хезмәттәшлек итә, күп кенә спектакльләрнең рәссамы була. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелган Н. Фәттахның «Кол Гали» (1973) Т. Миңнуллинның «Бәхтияр Канкаев» (1975) спектакльләренә театр костюмнары эскизлары эшли. 1976 елда Г. Тукай әсәре буенча сәхнәләштерелгән «Кәҗә белән сарык» спектакленә курчакларның, костюмнарның һәм декорация макетларының эскизларын эшли һәм аларны үзе үк гамәлгә ашыра.

1969 елда Т.Г. Хаҗиәхмәтов СССР Журналистлар берлегенә,

1971 елда СССР Рәссамнар берлегенә әгъза булып керә, 1971–1975 елларда Татарстан Рәссамнар берлегенең идарә әгъзасы була. Республика, бөтенроссия, бөтенсоюз күргәзмәләрендә актив катнаша. Шәхси күргәзмәләрен Казанда (1967, 1977, 1978, 1984) оештыра, 1971 елда Мәскәүгә, «Юность» журналы үткәргән күмәк күргәзмәгә, үзенең иҗат эшләрен җибәрә. Рәссамның күпсаны әсәрләре Татарстан музейларында – ТР сынлы сәнгать музеенда, Милли музейда, А.М. Горький музеенда, «Казан» милли-мәдәният үзәгендә, Кырлайдагы Тукай музеенда, Әлмәт Картиналар галереясында лаеклы урын алган.

Тавил Хаҗиәхмәтов эшләгән жанрларның төрлелеге – станлы һәм китап графикасы, сынлы сәнгать, театр сәнгате, портрет, пейзаж, көндәлек һәм тарихи жанрлар – аның һәрвакыт милли темага булган кызыксынуының тирән һәм даими икәнлеген күрсәтә. Шуны тормышка ашыру өчен ул әледән-әле яңа формаларга, яңа сурәтләү чараларына мөрәҗәгать итә. Рәссам борынгы тарихи вакыйгаларга мөрәҗәгать итәме яки бүгенгене тасвирлыймы, ул андагы тормыш-көнкүрешне, яшәү рәвешен, куллану әйберләрен сурәтләү белән генә чикләнми, ә бәлки татар халкының вакытлар узу белән дә үзгәрмәгән милли характерын, холкын чагылдырырга тырыша. Татар культурасы традициясенең бай катламнарына нигезләнеп, рәссам ювелир сәнгате, чигү, каллиграфия өлкәләрендә, сәнгать манерасының үзенә генә хас үзенчәлекләрен ачарга ярдәм итүче чаралар уйлап таба. Аның иҗатында шартлылык, гомумиләштерү дәрәҗәсенең югарылыгы, стильләштерү һәм декоративлылык, ягъни академик рәсем мәктәбенең нигезен тәшкил иткән формалар үз мөмкинлекләреннән тулысынча файдаланырга ирек бирә. Юморлы ноталар белән үрелеп баручы халык тормышының поэтикасы, рәссамның лубоктан төшереп алынган рәсемнәренең эстетикасы аша чагылдырыла (Г. Галиев «Котбетдин Мәргән», 1971), салават күперенең барлык төсләре белән баетылган милли бизәкне, таләпчән ритмик нәкыш аша, агачка уеп ясау (Р. Хафизова «Курай малай маҗаралары», 1969; Ш. Галиев «Кызык», 1970, «Хезмәт Батыр», 1973), татар милли чигүе һәм ювелир бизәнү әйберләренә хас булган хикмәтле орнаментлылык һәм полихромия аша (Ж. Тәрҗеманов «Кызыклы сабантуй», 1973), гарәп хәрефләрен керештереп таләпчән язу алымы. (Кол Гали «Кыйссаи Йосыф», 1983).

Т. Хаҗиәхмәтов, Ленинградта уку чорында гравюра өлкәсендә тирән белем алу нәтиҗәсендә, Казанда беренчеләрдән булып, ксилографиягә (агачка гравюра) һәм тактаны линогравюрада эшкәртү буенча техник алымнарны кулланып, китап бизәү өлкәсенә гравюраны кертте. Татар авылларында киң таралган агачка уеп ясалган орнаментларны кулланып, рәссам китап графикасында файдаланылучы, үзенә генә хас бизәү алымын тудыра. Аның татар халык әйтемнәре

буенча эшләнгән «Слово народа правдиво» (1969, агачка уеп ясалган гравюра), «Танец татарских девушек» (1970, линогравюра), Н. Исәнбәт әсәре буенча эшләнгән «Мырау батыр» (1976, агачка гравюра) һ.б. серияләре тамашачыларга яхшы таныш.

Тавил Хаҗиәхмәтов китап бизәү өлкәсендә эшләгәндә авторларның үзләре белән дә тыгыз элемтәдә була. Андый авторларның исемлеге чикләнгән, әмма алар рәссамның күңеленә хуш килгән икән, әлеге каләм ияләренең китапларына иллюстрацияләрне ул күп тапкырлар эшләгән. Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил, С. Хәким, Ш. Рәкыйпов, Р. Хафизова иҗатларын яраткан. Бигрәк тә Ш. Галиев белән күп хезмәттәшлек иткән. Авторның йомшак юморы, лирикасы рәссам күңеленә аеруча хуш килгән. Шуңа да ул Ш. Галиевнең 10 китабына рәсемнәр ясаган.

Тавил Хаҗиәхмәтов төрле форматтагы китаплар – зурлары белән дә, кечкенәләре белән дә, бер дәрәҗәдә тырышлык куеп эшләгән. 1970 елларда аеруча популяр булган миниатюр сувенир китаплар аңа зур уңыш китерә. 1975 елда рәссам М. Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»нә ясаган рәсемнәре өчен Бөтенроссия сәнгать конкурсының дипломына лаек була, ә шул ук авторның «Җырларым» китабы өчен 1976 елда аңа РСФСР Госкомиздатының II дәрәҗә дипломы бирелә.

Рәссамның зур иҗади уңышы итеп Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре буенча эшләнгән 4 сериялек берничә еллык хезмәтен санарга була. 1971 елда ул агачка уеп әсәрнең беренче сериясен эшли. Әсәрнең полиграфик эшләнеше исә бераз соңрак, 1983 елда поэма башта татар телендә, 1985 елда рус телендә басылып чыккач гамәлгә аша. Бу басмаларда гравюралар фарзацларда (икегә бөкләнеп яртысы китап тышының эчке ягына ябыштырылган, икенче яртысы буш калган бит) бирелгән һәм ксилографиядәге (агачка чокып төшерелгән рәсемнәр) куе кара төсләр, йомшак көрән төсләргә алыштырыла. Шушы ук төсләр китап элементларын бизәгәндә виньеткаларда (китапта бүлек башына яки ахырына урнаштырыла торган кечкенә бизәк) һәм рамкаларда кулланыла. Ә болар исә китапка декоратив бергәлек һәм лирик характер өсти.

Тавил Хаҗиәхмәтов иҗатының иҗтимагый әһәмияткә ия булган янә бер хезмәте – татар телендәге дәреслекләрне эшләү. Р.Г. Вәлитов һәм С.Г. Вәгыйзова әзерләгән «Әлифба» китабы 1963 елда И.Л. Язынин рәсемнәре белән 30 тапкыр басыла. 1980 елларның уртасында башланган үзгәртеп корулар дулкынында милли тарих һәм мәдәнияткә кызыксыну арткач, «Әлифба» китабын да яңартыр вакытлар җитә. Тавил Хаҗиәхмәтов тәкъдим иткән вариант [Вәлитова, Вәгыйзов, 1986] яңа буын мәктәп укучыларына якын булган, мультипликацион эстетиканы хәтерләтүче сәнгати стилистикасы белән аерылып тора. Ә иң мөһиме, яңа «Әлифба» да милли тема, татар халкының көнкүреше, мәдәнияте тарихи һәм бүгенге көн аспектыннан чы-

гып тасвирлана. Т.Г. Хаҗиәхмәтов шушы принципларны эзлекле дәвам итеп, эксперимент рәвешендә, латин графикасы [Wağizov, Wəlitova, 2000] нигезендәге «Әлифба»ны бизи, әмма объектив сәбәпләр белән ул киң җәмәгатьчелеккә тарала алмады.

Тавил Хаҗиәхмәтов гомеренең соңгы көннәренә чаклы иҗади эшчәнлегеннән аерылмады, татар нәшриятлары белән хезмәттәшлек итте, акварель, темпера белән эшләде, яңа технологияләрне, шул исәптән компьютер графикасын да үзләштерде. Гомер буе үзенең төп иҗади бурычына – милли башлангычны иҗади формада тормышка ашыру юлларын эзләүгә – һәрчак тугры калды. Тавил Хаҗиәхмәтов китап рәссамы, рәссам-график, милли үзаңның чагылышын күрсәтү өчен төрле вариантлар тәкъдим итүче, татар халык сәнгатенең гасырлар буена килгән традицияләренә нигезләнгән оригиналь график стиль тудыручы буларак та татар сәнгатендә үзенең ныклы урынын алды.

**Әдәбият**

*Wağizov S.Ğ., Wəlitova R.Ğ.* Latin qrafikası niqezendə Əlifba: Экспериментал уку ярдәмлеге. Казан: Мәгариф, 2000.

*Валеева Д.К.* Искусство Татарстана (XX век). Казань: Туран, 1999. С. 6, 58, 67, 87, 204–209, 274.

*Вәлиева Д.* Үткәннәргә олы ихтирам // Социалистик Татарстан. 1986. 8 фев.

*Елькович Л.Я.* Из вечного родника // Советская Татария. 1984. 1 апр.

*Вәлитова Р.Г., Вагыйзов С.Г.* Әлифба. Дүртьеллык башлангыч мәктәпнең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 1986.

*Егорова М.Р.* Хазиахметов Т.Г. // Татарская энциклопедия. Т. 6. Казань: Институт Татарской энциклопедии, 2014. С. 158.

*Зарипов Э.Я.* Художники книги // Здравствуй, книга! Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. С. 175–176.

Искусство книги Татарстана. Первая Республиканская выставка. Казань. 8–20 апреля 2008 года. Каталог / Авт. вст. ст. и сост. каталога О.Л. Улемнова. Казань, 2013. С. 5–6, 9, 36.

*Червонная С.М.* Искусство Советской Татарии. М.: Изобразительное искусство, 1978. С. 102, 201, 208–211.

*Червонная С.М.* Хазиахметов Т.Г. // Художники Советской Татарии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. С. 362–366.

*Шаһиева Р.* Чыңла көмеш! // Мәңгелек гөлләре = Розы вечности. Казань: Заман, 2015. С. 208–210

*Юзеев Н.* Мудрость поэта // Литературная Россия. 1983. 14 окт.

***Улемнова Ольга Львовна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 745

***Л.М. Шкляева***

# КАЗАН СӨЛГЕСЕ – ТИМЕР ҺӘМ АГАЧТАН

*(рәссам Ринат Әхмәтов иҗатына күзәтү)*

Статья посвящена творчеству одного из ярких представителей декоративно-прикладного искусства Татарстана Рината Хаметлатифовича Ахметова. Он разработал свою авторскую технику в таких видах художественного творчества, как резьба по металлу и дереву. С 2012 г. стал активно экспонировать свои произведения на выставках различного уровня. Р. Ахметов отдает предпочтение изображению популярных национальных сюжетов и тем. Символом родной самобытной культуры для художника стали вышитые полотенца.

**Ключевые слова:** татарское декоративно-прикладное искусство, Р.Х. Ахметов, резьба по дереву, резьба по металлу, Казанское полотенце.

Татарстан декоратив-гамәли сәнгатенең күренекле вәкилләренең берсе Ринат Хәмәтлатыйф улы Әхмәтов Казан шәһәрендә туган. 1989 елда Н. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесын тәмамлый. Яшьтән үк тимер һәм агачка уеп, чокып, сырлап бизәк төшерергә ярата. Озак елларга сузылган экспериментларга һәм тәҗрибәсенә нигезләнеп, Р. Әхмәтов сәнгать өлкәсенең бу төре буенча үзенә генә хас алымын тудырган.

2012 елдан башлап оста үзенең иҗади эшләрен төрле дәрәҗәдәге күргәзмәләргә куя башлый: 2012–2013 еллар – республика күргәзмәләре; 2015 – «Архитектура Дизайн. Современные тенденции»; 2013 – «Большая Волга» төбәк күргәзмәсе; 2014 – «Моя Родина Татарстан» төбәкара күргәзмәсе, 2015 – «Посвящение Татарстану», «Идель-Арт –3»; 2015 – «70 лет Победы» халыкара күргәзмәсе.

Р. Әхмәтованың үзенә генә хас булган шәхси эш алымнары кулланып иҗат иткән әсәрләренең асыл кыйммәте – кулдан эшләнүендә. Шул ук вакытта бу эш бик күп көч, югары дәрәҗәдәге осталык таләп иткән технологиягә корылган. Мастер үз стилен булдырган. Аның әсәрләре пропорцияләрне яраштырып сайлау һәм композициянең үзенчәлекле булуы белән аерылып тора. Р. Әхмәтов популяр булган милли сюжет һәм темаларга сурәтләр ясауга аеруча өстенлек бирә. Рәссам узган гасырның башларында әбисе чиккән сөлгене милли мәдәният символы итеп сайлый, шуңа да әсәрләр сериясен «Казан сөлгесе» дип атый. Аның эшләре милли гореф-гадәткә кагылышлы булган сабантуй, туган авыл һ.б. традицион образларны берләштерә.

Сабантуй бәйрәме булачак рәссамны кечкенәдән үзенә җәлеп итә. Вакыйга әйләнә формасын хәтерләтүче мәйданда бара. Тамашачылар шуның әйләнә-тирәсенә тезелешеп утырганнар. Бәйрәмнең төп вакый-

гасы – әлбәттә, көрәш. Шуңа да рәссам хезмәтенең композицион үзәген көрәшчеләрне тасвирлау тәшкил итә. Әсәрнең гомуми сюжетын автор төрле традицион уеннар һәм тамашалар ярдәмендә тулыландыра. Кара фонда агачтан эшләнгән кырлар, аның янәшәсендә тимердән коеп эшләнгән кеше фигуралары. Мастер төрле фактураларның ярашуын оста куллана: ялтырап торучы җиз һәм бакыр караңгы, кытыршы агач яссылыкта уңдырышлы җир образы буларак кабул ителә. Кояш нурлары бәйрәмдә катнашучыларның ритмлы итеп бирелгән силуэтларына җиңеллек, шатлык төсмере өсти. Аерым торучы фигуралар нәфис каллиграфия ысулы белән язылган хәрефләрне, ә төркемдәгеләр – төрле рәсемнәрдән төзелгән арабесканы (яфрак, чәчәк, геометрик фигура рәсемнәреннән төзелгән орнаментны) хәтерләтә. Панно мәйдан образында, әйләнә формасында эшләнгән. Сабантуйның кульминация мизгеле булган ат чабышлары мәйдан әйләнәсеннән читтә уза.

«Туган авылым» эше «Аулак өй»ләрдә катнашучы яшьләрнең халәтен күз алдына китерергә ярдәм итә. Композиция горизонталь форматта эшләнгән. Рәссам Ринат Әхмәтов тамашачыга кояш баю күренешен тасвирлый. Көндәлек эшләр тәмамланган һәм, ниһаять, яшьләргә вакытларын бергә уздыру өчен мөмкинлек туа. Автор фикере буенча, стенадагы күләгәләр өйдәге вакыйгаларны гәүдәләндерә. Эзлекле төстә авыл бәйрәменең күренешләре ачыла: биюләр, төрле уен коралларында уйнаулар. Силуэтларда «Аулак өй»гә килүчеләрнең традицион татар милли киемнәрен дә шәйләргә була. Рәссам өйнең эчке һәм тышкы күренешен берьюлы күрсәтү алымын куллана. Р. Әхмәтов авылдагы агач архитектураның матурлыгын, аның декоратив бизәлешен Казан татарлары иҗатында киң таралган орнаментлар ярдәмендә күрсәтә алган (соляр билгеләр һ.б.). Татар чигүе өчен характерлы булган чәчәк-үсемлек мотивлары чынбарлыктагыча күренә. Сабантуйның төп атрибуты – сөлге – композициянең үзәк урынын алып тора.

Рәссамның эре форматлы эшләре татар халкының аутентик сәнгатен, эстетик кыйммәтләрен гәүдәләндерә, аларның идеясе эчке төзелеше белән табигый бәйләнештә һәм шул ук вакытта авторның эмоциональ холкын да чагылдыра. Панно рамнар, ритмик бизәкләр белән эшләнгән. Ринат Әхмәтов татар халкының традицион сәнгать төрләрен үстерүгә зур өлеш керткән шәхес.

***Шкляева Людмила Михайловна,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 782:821.512-2

***Э.М. Галимова***

# ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТ ДРАМАЛАРЫНЫҢ МУЗЫКАЛЬ БИЗӘЛЕШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Статья посвящена выявлению музыкальной специфики произведений татарского драматурга Тази Гиззата и композитора С. Сайдашева «Наёмщик», «Бишбулек», «Священное поручение», «Настоящая любовь», «Алая заря», написанные в жанре музыкальной драмы. В статье характеризуются музыкально-интонационные особенности композитора С. Сайдашева, выраженные в драматических произведениях Тази Гиззата. Яркое совместное творчество двух выдающихся личностей послужило ориентиром для поступательного развития татарского музыкального искусства.

**Ключевые слова:** Т. Гиззат, С. Сайдашев, музыкальная драма, музыкальные особенности, музыкальное искусство, история татарской музыки.

Таҗи Гыйззәт үз халкының тормышын тирән чагылдырган драматургларның иң күренеклесе. Аның тирән эчтәлекле реалистик драматургиясе татар театры репертуарында үзәк урынны алды. Татар артистлары аның әсәрләрендә уйнап, зур сәхнә образлары иҗат иттеләр. Сер түгел, драматургиядә яки прозада, кабатланмас яңа драматик ситуация, яңа сюжет, һәр чорга хас зур типик образ-характер табу – ул зур фәнни ачышка тиң. Мәкаләнең төп темасын ачарга керешкәнче, композитор Салих Сәйдәшев һәм драматург Таҗи Гыйззәтнең татар театры үсешенә көчле йогынты ясаулары һәм тирән эз калдырулары турында әйтәсем килә. Ике шәхеснең иҗади дуслыгы нигезендә музыкаль драма жанрына караган «Наёмщик» (1928, икенче редакция 1948), «Бишбүләк» (1933), «Изге әманәт» (1944), «Чын мәхәббәт» (1948), «Алсу таң» (1950) кебек әсәрләр сәхнәгә чыга.

Музыкаль драма жанры – музыканың драматик сәхнә хәрәкәтенә зур йогынты ясавы белән аерылып тора. XIX гасырга кадәр опера жанрын әлеге термин белән атаганнар. Кайбер сәхнә мисалларында музыкаль драма жанры операга һәм сүзле драмага хас элементларны үз эченә ала. Шуңа күрә, 1920 елларда татар театры спетакльләрендә музыкага зур урын бирелә. Бу хәл исә татар музыка культурасын үстерүдә һәм киләчәктә татар милли опера театрын төзүдә зур роль уйнады: музыкаль әсәрләрне башкару өчен жырчылар, музыкантлар әзерләнә торды, оркестр барлыкка килде, яшь композиторлар үсеп чыкты, музыкаль драма һәм опера әсәрләре иҗат ителде. Шундый яңа жанрларның берсе – Таҗи Гыйззәтнең 1928 елда куелган «Наёмщик» драмасы. Бу әсәр, беренчедән, 1923–1926 елларда куелган «Талир тәңкә» драмасыннан соң, Таҗи Гыйззәтнең үткен каләмле һәм тирән фикерле дра-

матург булып җитлегүен раслады. Икенчедән, Салих Сәйдәшевның киң диапазонлы талант иясе булуын күрсәтте. Шушы спектакльдән соң әлеге ике шәхеснең иҗат дуслыгы егерме биш ел буе, гомерләренең соңгы көннәренә кадәр дәвам итте.

«Наёмщик» спектаклендәге уннан артык музыкаль номерлар – дуэт, хор, симфоник оркестр өчен язылган марш, кереш өлеш һәм бию көйләре, Батырҗан һәм Гөлйөзем арияләре спектакльнең идея-эмоциональ көчен тирәнрәк ачарга ярдәм итәләр. «Гөлйөзем ариясе»ндә драматик рухтагы кереш өлеш тыңлаучыга көчле тәэсир ясый. Гадәттә, кушымта алдыннан темп әкренәя бара һәм контраст кызу темп белән кушымта дәвам итә. Бу төр музыка ысуллары барлык спектакльләрдә дә төп рольне уйный дип әйтергә мөмкин. «Батырҗан белән Гөлйөзем дуэты» мәхәббәт хисе белән уралган лирик ария. Гомумән, композиторның тамашачы хәтерендә калырлык көй язар өчен секвенция музыка ысулын куллануы беркемгә дә сер түгел. Әлеге дуэт та секвенция кулланып язылган көйгә нигезләнгән. Өч кисәкле музыкаль калып, башта Батырҗанга, аннары Гөлйөземгә музыкаль характеристика бирергә ярдәм итә. Лирик эмоцияләргә бай тагын бер музыкаль номерга тукталыйк – «Гәрәй ариясе». Әлеге ария өч чирекле музыкаль үлчәмдә язылган. Бу – ир кешенең мәхәббәт хисен чагылдыру өчен бик үзенчәлекле ысул. Гармония ягыннан карасак та бик кызыклы. Тоника гармониясеннән соң доминанта куллану ул гадәти күренеш. Ә Салих Сәйдәшев киңәйтелгән доминанта (ягъни увеличенная доминанта) ярдәмендә, әсәрнең кереш өлешендә үк тематик ярма салып куя. Контраст темп куллану композиторның үзәк идеяләреннән берсе һәм дуэт, ариозо, арияләргә музыкаль характеристика бирергә һичшиксез ярдәм итә. «Батырҗанның хор белән җыры» секвенция кулланып язуга янә бер мисал. Драматик рухта язылган кереш өлеш Батырҗанның ир-атка хас булган сыйфатларын сурәтли. Хор партиясе рус классик операларына хас булган ысуллар белән язылган: дүрт тавышка үзенчәлекле итеп яңгыраш бирү – әлеге бүлекнең саллы дәлиле. Инструменталь музыкаль бүлекләргә килгәндә, «Наёмщик» музыкаль драмасының халык күңеленә үтеп кергән һәм дан казанган кереш өлешен – бию һәм вальсны атарга була. Вальсны драманың бөтен лирик хисләрен үз эченә алган музыкаль өлеш дип әйтергә була. Биюгә килгәндә, әлеге музыкаль өлеш халык арасында бик популяр. Әлбәттә, бию темасы вариация музыкаль форма ярдәмендә эшкәртелә. Лирик урта өлеше дә бар һәм ул өч чирекле музыкаль үлчәмдә язылган. Биюнең өченче өлеше ике чирекле үлчәмгә әйләнеп кайта һәм төп тема полифония ярдәмендә тавышлар арасында бара. Гомумән, Салих Сәйдәшев пьесадагы бию өлешен халык рухын чагылдырып яза һәм башка хореография өлешләрен контраст итеп классик балет сәнгатенең сюита жанрында иҗат итә. «Наёмщик» әсәре белән Таҗи Гыйззәт тамашачылар

алдында талантлы драматург булып танылa.

«Бишбүләк» Таҗи Гыйззәтнең үз иҗаты өчен дә һәм шул чор драматургиясе өчен дә яңа, оригиналь образларга бай әсәр. Драматургның башка әсәрләрендәге кебек, «Бишбүләк»тә дә персонажлар күп, биредә дә хәлиткеч вакыйгаларга бәйләнешле булган берничә сюжет сызыгы үстерелә. Салих Сәйдәшев «Бишбүләк» пьесасындагы кызлар хоры – «Өмә җыры» белән «Партизаннар җыры»н аеруча яраткан. Пьесаның өч төрле кереш варианты була. С. Сәйдәшев соңыннан икенче вариантын сайлап алды, дип язалар аның турындагы истәлекләрдә. «Бишбүләк»нең премьерасы зур уңыш белән уза, ә пьесадагы җырлар соңыннан халыкның яратып җырлый торган көйләренә әверелә.

«Маһинур белән Тимеркәй» дуэты «Бишбүләк драмасының» иң матур музыкаль кисәкләренең берсе. Мелизмнарга бай вокал партиясе абыйсы белән сеңлесе арасындагы үзенчәлекле мөнәсәбәтне һәм шул ук вакытта якты киләчәккә омтылу хисләрен чагылдыра. Ике чирек белән дүрт чирекле музыкаль үлчәм контраст формасында чиратлашып кулланыла. Беренче куплетта ук мелизмга бай тема яңгырый, ә кушымта исә марш жанры тәэсирендә языла. Гармониягә килгәндә үзенчәлекле ысул буларак: F-dur һәм D moll тональностьләре чиратлаша һәм аны әлеге мисал белән дәлилләп була: T-VI-D#-T; T-VI-III-D7-T. Кереш өлешендә тоника һәм киңәйтелгән доминанта бик кыю яңгыраш бирә. «Бишбүләк» музыкаль драмасында шулай ук үзәк урын алып торган комиссар Башкуватовның ике ариясенә дә аерым тукталырга була. Беренчесе – «Партизан җыры» – туган якка сагыну хисләрен чагылдыра, ә икенче ария төп геройның эчке шәхси уйларын драматик рухтагы вокаль партия ярдәмендә сурәтли. Шундый ук планда Маһинур ариясе дә язылган. Сюита жанрына якынлаштырып берничә бию номерлары да иҗат ителгән. Ләкин инструменталь өлешләр һәм хор өчен язылган номерлар юк дәрәҗәсендә. Бу хәл оркестр булмау һәм артистларның вокал мөмкинлеге чикле булуга бәйле. Бары тик баш рольләрне башкаручы артистлар гына музыкаль белемгә ия була.

Таҗи Гыйззәт пьесаларының төзелешендә бер әһәмиятле үзенчәлек бар. Драматург катлаулы тормыш күренешләреннән бер-ике сюжет сызыгы алу белән генә чикләнми. Ул чынбарлыктагы киеренке вакыйгаларны, персонажлар арасындагы күп төрле мөнәсәбәтләрне күрсәтә. Нәтиҗәдә, әсәрдә сурәтләнгән тормыш күренешләре, образлар гаҗәеп тирән, тулы булып күз алдына килеп басалар. Донбасстан алып кайткан материаллар нигезендә язылган «Изге аманәт» драмасында язучының бу осталыгы аеруча ачык күренә. Музыкаль анализга килгәндә, әлеге әсәрнең иң матур өлешләре итеп Наҗиянең беренче һәм икенче җырын атарга була. Салмак темпта үзенчәлекле гармония кулланып язылган җырлар зур яңгыраш табалар. Беренче җыр мәхәббәт турында булса, икенчесе җиргә булган

хисләрне белдерә. Әлбәттә, әлеге теманы сурәтләү гармонизациядә дә сизелә, һәм гармония алымнарында да чагыла.

Ватан сугышы чоры вакыйгаларыннан алынып язылган «Чын мәхәббәт» әсәрендә (1947) драматург ул елларны тылда эшләгән кешеләрнең тормышын күрсәтүне бурыч итеп куя. Язучы тылда эшләүче кешеләргә хас булган тирән патриотизмны төрле характердагы образлар аша бирсә, композитор Салих Сәйдәшев әлеге рухны бирү өчен кварта, квинта интерваллары куллана, европалашкан кыю гармония ярдәмендә, шул ук вакытта милли интонацияләр белән баета. Гөләндәм образы да әсәр буена бик күп үзгәрешләр кичерә. Музыка ысуллары ярдәмендә, композитор нәкъ менә әлеге сәхнә образын бөтен яклап тасвирларга тырыша. Нәтиҗәдә, ил, халык язмышы өчен тормышын да кызганмаган герой хатын-кыз образы барлыкка килә.

1950 елда дөнья күргән «Алсу таң» әсәре психологик драма планында язылган. Әсәрнең нигезенә хисләр, характерлар конфликты салынган. Әлеге әсәр – драма һәм музыка ягыннан да, беренче чиратта, персонажларның эчке тормышын, кичерешләрен ачуга игътибар бирә.

Нәтиҗәдә, алда әйтеп үтелгәнчә, композитор Салих Сәйдәшев музыкаль драма әсәрләрен милли интонация кулланып, классик вокал көйләргә якынайтып яза. Композитор иҗатына татар халкының «озын көй» җанры зур йогынты ясый. Мажор-минор лад калыбы, кереш тоннар, пентатониканың төрле ладларын куллану – татар музыкасы өчен новатор караш һәм кыю яңгыраш бирә. Марш һәм вальс жанрларын инструменталь номерлар өчен куллану шулай ук кыю адым. Композитор С. Сәйдәшев әлеге ысулны – рус, европа классикасы музыкасына якынайту теләге белән куллана. Музыкаль драмаларның симфоник-инструменталь кисәкләре киләсе буын композиторлары өчен үрнәк һәм аларны европа гармониясен куллануда практик яктан тәҗрибә дип атарга була. Цитаталар куллануны композитор хуп күрми, ә бары тик стилистик яктан халык җырларына якынайтып язарга омтыла. Салих Сәйдәшев татар музыкасының новатор буларак үзенчәлеген билгели һәм шул ук вакытта үзенең милли композитор булуын да саллы иҗат мирасы белән раслый.

Салих Сәйдәшев һәм Таҗи Гыйззәт. Алар икесе дә бөек шәхесләр һәм уртак иҗатлары чын мәгънәсендә татар халкының күңелендә зур урын алып тора. Алар иҗат иткән музыкаль драмалар яңа чынбарлыктан, бүгенге заманнан аерылгысыз һәм милли мәдәниятебезнең алтын фондын тәшкил итә. Әлеге әсәрләрне саклау, өйрәнү һәм яшь буынга җиткерү – иҗат әһелләренең, музыка белгечләренең һәм фәнни хезмәткәрләребезнең җаваплы бурычы.

***Галимова Эльмира Мөнир кызы,***
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре*

# ӘДӘБИ МИРАСЫБЫЗ ТАГЫН ЙӨЗ ЕЛГА ЯКЫНАЙДЫ

## («Татар әдәбияты тарихы»ның 3 нче томы басылып чыгу уңае белән)

Кешене зыялы итеп санар өчен үзенең җиде буын бабасын белү шарт итеп куелуын барыбыз да яхшы белә. Әмма үзеңне зыялы милләт вәкиле итеп тояр өчен ничә буын бабаңны белү кирәклеген безгә әлегәчә беркемнең дә әйткәне булмады. Әмма «Татар әдәбияты тарихы» сигезтомлыгының шушы өч томы дөнья күрү безгә инде бу сорауга да җавапны шактый төгәл, ачык итеп бирү мөмкинлеген ача. 25 ел саен яңа буын алышына диеп алсак та, ике мең елны үз эченә алган бу өч томлыкта безнең 77 буын бабайларның рухи мирасын телгә алып фикер йөрткәнебез ачыклана. 77 буынлы милләт культурасы, милләт әдәбияты турында сүз барганда, аны инде бүрек белән генә бәреп егып булмаячагы яхшы аңлашыла. Әлеге басманың ике томы дөнья күрү халыкара, төркикүләм узган форумнарда башкаларга да безнең җирдә югалмавыбызны, дөньяда үз йөзебез, үз фикер-карашыбыз яшәгәнлеген, тыйнак, әмма саллы гына терсәкләребез дә булганны, һәрхәлдә, безнең белән санашырга кирәклекне яхшы төшендерде.

Беренче томда без ерак гасырлар тирәнлегенә сузылган үзебезнең кодрәтле әдәби тамырларыбызны барласак (ә бит бу – милләт тарихы турында коры теоретик фаразлау гына түгел, ә бәлки конкрет тоемлы материал-чыганакка таянып эш итү нәтиҗәсе), икенче томда шулай ук үзебезнең иң олы һәлакәттә дә юкка чыгарып бетереп булмаган рухи мәдәниятле халык икәнлегебезне расласак, яңа басылып чыккан өченче томда бүгенге көннәргә без тагын да йөз елга якыная төштек. Мондагы тарихи шартлар инде алдагы томнардагыча алай ук кырыс һәм караңгы түгел, алар бөтенләй икенче рухлы. Бу том милләтебез үсешендә нинди текә үрләр яулап алуга сәләтле булуын бик ачык күрсәтә торган гыйбрәтле чорны үз эченә ала. XIX йөз татар әдәбияты безнең бүгенге көнебез өчен дә ифрат кадерле, ул милләтебезнең балачагыннан безнең көннәргә сузылган ныклы, ышанычлы рухи күпере!

XIX йөз татар тарихы – Европа демократик карашларының Россиягә дә үтеп керә башлавын, Патша империясендәге рус булмаган милләтләрне турыдантуры юкка чыгару һәм көчләп чукындыру сәясәтенең тәмам уңышсызлыкка очрап, хөкүмәтнең кайчандыр Алтын Урда мирасын үзләштерүдәге тулы хокуклы төп көндәше – үзгә бер кыйблалы татар-мөселманнарны яңабаштан мөстәкыйль кавем-культура вәкиле итеп тануын, аларга йөз белән борылырга, алар белән санашырга мәҗбүр иткәнлеген раслаучы фактор буларак кызыклы [Юзеев, с. 38].

Бу – татар халкының, дәүләтен юкка чыгарып, үзен рәхимсез изеп килгән зур империядән

беренче кешелекле мөнәсәбәт даулап алуы. Кечкенә генә үзгәрешләр дә аңа, берничә гасыр дәвамында җыелып килгән җан сыкрануын эчкә йотып, әлеге ил халкы белән бер сулышны тоеп яшәү шарты бирә һәм, әлбәттә, Россия хөкүмәтенә дә үзенең алдагы тышкы һәм эчке сәяси яшәешендә – бигрәк тә солдат хезмәте, корбан соралган яңа яулап алу-сугыш хәрәкәтләрендә, буш кул таләп ителгән барча авыр төзелеш эшләрендә мөселманнарны ышанычлы, карусыз үз халкы, үз милке итеп файдалану мөмкинлеге тудыра. XVIII–XIX йөздә ил күләмендә узган һәрбер зур вакыйгаларга татарлар, элеккечә үк ач-ялангач, хокуксыз, ярымкол рәвешендә, үзен дәүләт чиновникларының аерым эчке каныгу объекты икәнлеген тоеп яшәүләренә карамастан, шушы ил вәкиле – Россия кешесе буларак катнаша башлый.

Татар милләтенең ерактан килгән катлаулы һәм фаҗигале үсеше яңа гасырда үзенчәлекле заман әдәбиятын формалаштыра. XIX йөз татар әдәбияты ул – милли мәдәният үсешебезнең кинәт буйга тартылып киткән үсмер чагын хәтерләтә. Озын булып тоелган балачак инде артта калган. Үлем янавы һәм чит-кырыс куллардагы ятимлек чоры үтеп, кыерсытылу, җан җәрәхәтләреннән арына башлаган... милли аңының, ай үсәсен көн үскәндәй, конкрет җирлек, тормыш-яшәүгә ябышырга өлгергән, ахирәттә һәм дөньялыкта дөрес яшәр өчен, кыйбласын расларга керешкән дәвере.

Бу гасыр гомуммәдәни үсештә әһәмияте ягыннан әдәбиятыбызның «алтын чоры» саналган XX йөз башы дәвереннән һич кенә дә калышмый. Зур мәдәниятнең өзелгән җирдән кабат ялганып бөреләнгән үсентесе буларак, әдәби җимешләре, казанышлары әле дөньякүләм дәрәҗәдә яңгыраш тапмаса да, аның тамырларындагы яшәү дәрте, иман ныклыгы, үткәндәге традицияләргә, кыйбласына тугрылыгы ягыннан XIX йөз хәтта үзеннән соң килгән чорга караганда да күбрәк сокландыра. Ул – фаҗигале XVI–XVII гасырның караңгы бушлыгын кичеп, изге мәчетләре тоташ утка тотылган аяусыз XVIII гасыр афәтләреннән (Лука Канашевич чоры репрессияләре нәтиҗәсендә, 1740 елларда 80% мәчет юк ителә) исән калган, инде милли, социаль көрәшкә булган омтылышы көндәлек тормыш рәвешенә үтеп кергән, һәр сулышыннан тыелгысыз эчке яшәү энергиясе бөркелеп торган яңа әдәбият ялгысы. Бу – татарларның милләт буларак тууы, аның эволюцион җирлектәге үсеш башлангычы [Хабутдинов, с. 20–26]. Бу – татар рухының, олы милләтләргә генә хас булганча, дөньялыкта яңа милли фәлсәфә булып өлгереп җитүе [Юзеев, с. 46]. Бу – потенциал татар акылының фән өлкәсендә һәм һәр ике дөньяны үзләштерүдә нәзари-гамәли сикереш ясавы, милли аренага бер-бер артлы Г. Утыз Имәни, Г. Курсави, Шәмседдин Зәки, Г. Кандалый, Ш. Мәрҗани, Х. Фәезханов, К. Насыйри, И. Гаспралы, М. Акмулла, М. Акъегетзадә, З. Бигиев, Закир Һади, Шакир Мөхәммәдев, Р. Фәхреддин, Ф. Кәрими, Ф. Халиди,

Г. Исхакый, Й. Акчура, Габдерәшит Ибраһим, А. Баязитов, М. Бигиев, Г. Баруди, С. Максуди кебек оригиналь фикер ияләре һәм бөек шәхесләренең, талантлы әдипләренең кыю калкып чыгу дәвере. Бу – татар эстетик зәвыгының мең еллык традиция-тамырларына табигый тоташып, өр-яңа заман нәфис әдәбияты үрнәкләрен бирүгә сәләтлелеген күрсәтүе. Бу аның дөнья әдәбияты казанышларына кыю төстә юл яру өчен төрек һәм рус әдәбияты, алар культурасы аша Европа әдәбияты классикаларына да мөрәҗәгать итеп, аларны турыдан-туры татар укучысына җиткерү омтылышы, ягъни гасырның буеннан буена диярлек сузылган тәрҗемә жанрының да ныклап торып гамәлгә куелуы. Әдәби бәйләнешләр һәм тәрҗемә жанрына җентекле анализ ясаган Рифә Харрасовага без томда урынны бик иркеннән бирдек, аның ул мәкаләсе бу зур форматлы китапның да 46 битен тәшкил итә.

Шул рәвешчә, XIX йөз татар әдәбиятының гомум әдәбиятыбыз үсешендәге тоткан әһәмиятен һәм кайбер үзенчәлекләрен без, төп ориентир рәвешендә генә булса да, билгеләп уздык сыман. Биредә мин әлеге басманың структур төзелеше турында да берничә сүз әйтеп китү кызыклы булыр дип уйлыйм.

Алдагы басмада бу чор әдәбияты, нигездә, ике чорга (XIX йөзнең беренче һәм икенче яртысына) бүлеп күзаллана. Яңа исемнәр өстәлү, элеккеге материалларны яңача күзаллау безгә әлеге чор әдәбияты үсешендә аерылып торган дүрт этап булуын күрсәтергә мөмкинлек бирде. Шуның белән бергә әлеге этапларның эчке охшаш үзенчәлеген ачыклап, аларны кабат ике төркемгә җыеп бирүне (ягъни кабат ике чорга аерып карауны) отышлы дип таптык, әмма бу инде элеккеге бүленешкә кире механик әйләнеп кайту түгел, ә бәлки аны яңа мәгънә логикасы җирлегендә тәкъдим итү. Бер уңайдан шагыйрь Г. Утыз Имәни иҗат портретының нәкъ элеккечә, кабул булмаган ураза сыман, XVIII йөз әдәбияты томы ягында асылынып калуына да чик куелды. Тарихны бозып булмый, XVIII йөздә әле Г. Утыз Имәни безнең алда нигездә 1798 елга кадәр дәвам иткән шәкертлек елларын, иҗатка әзерлек чорын узып бетермәгән шәхес һәм 11 бала атасы буларак күзаллана, ә аның төп – өлгергән иҗат чоры, ягъни үлгәнчегә кадәр дәвам иткән 34 елы яңа – XIX гасырга карый. Аннан да бигрәк, ул иҗат гомум әдәби үсештә яңа бер күчеш этабын тәшкил итә. Димәк, аны алдагы гасырга күчләп кертеп калдыру бер яктан да үзен акламый. Хәер, аны XVIII йөздә күреп өйрәнгән галимнәр өчен дә, шагыйрьнең башлангыч чор иҗаты турында 2 нче томга да махсус яздырып алынган мәкалә урнаштырылды.

Ә гомумән, XIX йөз татар әдәбияты үсешен мәгърифәтчелекнең татар әдәбиятына үтеп керү тарихы итеп күзалларга мөмкин. Әйтүебезчә, ул ике чорга бүленә: **Беренчесе** XVIII йөз азагыннан 1860 елларга кадәр сузыла. Бу чорда без ничә гасыр буена татарларны чукындырып,

кысып-изеп килгән рус патшаларының сәяси кыйбласы үзгәреп, инде Екатерина IIнең мәчет салдыруга рөхсәт биреп кенә калмыйча, татарларга басма китап оештыру эше җаваплылыгын да үз өстенә алуын, үз исеменнән унлап басмада Коръән бастырып чыгаруын күрәбез. Китап белгече Әбрар Кәримуллин аның һәр басмасында 3600 нөсхә Коръән чыгарылуы турында хәбәр итә. Икенче олуг галимебез Мәсгуд Гайнетдинов исә, бу эштә арадашчы булып Исхак Хәлфин эшчәнлеге торуын безгә томда җентекләп күрсәтеп бирә алды. Бу чор мәгърифәтчелекнең Россиягә һәм татарлар тормышына Европадан үтеп керүе белән бәйле. Әмма кеше үзе әзер булмаганда, аңа акыллы сүзләр сөйләүдән генә әлләни файда юк. Аерым шәхесләр эшчәнлеге белән генә дә халыкны торгынлыктан чыгару мөмкин түгел. Милли рух, милли аңның үсүе өчен аңа үз җирлегендә өлгерү чоры үтү зарур. Ә андый **икенче чор** безгә XIX йөзнең алтмышынчы елларында килә! Үзебезнең Мәрҗани, Фәезханов, Насыйрилар плеядасы иҗтимагый-тарихи аренага чыгу әнә шуны күрсәтә. Шушы фәнни казанышлар, берничә дистә елда тел, мәгариф, әдәбият, культура мохитына да күчеп, XIX йөз азагында инде тулы канлы, күптармаклы, бөтен әдәби жанрлары да үсеп чыккан куәтле татар әдәбияты кәүсәсен барлыкка китерә.

Тукайның беренче көннән үк дөнья әдәбияты казанышларын үзләштерә башлавы һич гаҗәп түгел, аңа һәм алар буыны яшьләренә басып менәргә элгәреләре инде баскычны гасыр азагында ук әзерләп куюга ирешә.

Шулай итеп, без әдәбият тарихы өчен гаҗәп авыр булган беренче этапны – өч томнан торган, тәмам диярлек юкка чыгарылган, без белмәгән һәм шуңа да безгә чын мәгънәсендә фидакарь тарихи эзләнүләр аша килеп ирешкән әдәби хәзинәне яктырткан томнарны мөмкин кадәр җыеп, өйрәнеп, системага салып бастыруга ирештек. Әлеге юнәлештә алга таба да эзләнәсе, яңа исемнәр ачарга теләгән яшьләргә таянып эш башлап җибәрү өчен, минемчә, шактый ныклы, ышанычлы плацдарм яулауга ирешелде. Дүртенче томнан башланган әдәбият инде ул – яңа төр әдәбият. Бу – дөнья әдәбияты югарылыгына чыккан классиклар әдәбияты! Шуңа да алдагы 4–8 томнарда чагыласы материал ул, тарихтан да бигрәк, безнең өчен башлыча әдәби әсәрләрнең эстетик үзкыйммәте белән бәйле хәзинә.

3 нче томның басылып чыгуы шактый озакка сузылды, бу исә өстәмә кыенлыклар китереп чыгарды: текстны берничә тапкыр онытып, берничә тапкыр кабат искә төшерергә кирәк булуда гына да түгел хикмәт, Рифә (Р. Рахман) һәм Илһам (И. Гомәров) белән өчәүләшеп инде эшне бетердек дигәч тә, штатта үзгәрешләр килеп чыгып, текстка яңа күзаллау, өстәмә редакторлар кулы килеп кереп, соңыннан автор фикерен бозган бу төзәтүләрне кабаттан кайтарып һ.б. шундый кирәкмәгән өстәмә борчулар да шактый булды. Шиһабеддин, Ризаэддин кебек татар исемнәрен

әле *т* га, әле *д* га төзәтеп чыгу гына да бит 800 битле кулъязмада меңләгән төзәтүләр китереп чыгара. Үзебезнең рухи лидерларыбызның исемен бетдин, этдин формасында укучыга җиткерәсебез килмәде. Мондый тел культурасында хәл ителеп бетмәгән факторларга бәйле өстәмә эшләр дә байтак булды. Шөкер, исәнсау башкарып чыктык төсле.

Мин бүген барыннан да элек хезмәтләре бу томның нигезенә яткан Мәсгуд абый Гайнетдиновка чиксез рәхмәтемне җиткерәсем килә, аның томда унбер мәкаләсе урын алган. Китапта бер дистә мәкаләсе белән катнашып, томга өр-яңа яңгыраш биргән Рифә Харрасовага, дүрт мәкалә авторы Илһам Гомәровка шулай ук рәхмәт әйтми калдыру олы гөнаһ булыр иде. Рифә белән Илһам автор буларак кына түгел, томны башлап редакцияләү эшендә, аны билгеле бер калыпка салышуда да чиксез зур хезмәт куйдылар. Аларның хезмәтләре томның үзәк өлешен тәшкил итә. Бүлек кызларыннан томның җаваплы сәркатибе дип атыймммы икән инде, шулай ук томның исем күрсәткечен төзүче Фатыйма Миңнуллинага, исем күрсәткече төзешкән һәм томны фотоматериаллар белән бизәүдә төп эшне башкарган Диләрия Абдуллинага һәм томның фәнни редакторы Фоат абый Галимуллинга рәхмәтләремне җиткерәсем килә. Ниһаять, бу томның бербөтен төзек том булып чыгуына үзенең тырышлыгын, җан җылысын кызганмаган, зур тәҗрибәсен, сабырлыгын күрсәткән Татарстан китап нәшрияты редакторы Илсөяр Кадыйровага, томны барлыкка китерүдә үз өлешен керткән һәркемгә ихлас рәхмәтләребез барып ирешсен.

Мин инде, шөкер, сигезтомлыкның бу бездә иң аз эшләнгән чорга караган авыр өлешен уздык дип, җиңелрәк тә сулап куйган идем. Әмма 4 нче том белән булган хәлләр минем бик нык ялгышуымны раслап тора. Хәзер моның ни өчен шулай килеп чыгуын да аңлыйм төсле. Әйе, алдагы 4 томда да эшләр җиңелдән булмаячак. Төп сәбәбе шунда – безнең әдәбият галимнәре арасында әдәби әсәрне анализларга өйрәнгән белгечләр юк дәрәҗәсендә. Аерым темага диссертация әмәлләп чыгу әле ул – эшнең беренче яртысы гына. Шушы җыелган, билгеле бер яңалыгы булган материалны кызыклы итеп, укучылар укырлык итеп, 12–24 битлек мәкаләгә сыйдырып, иҗат портреты дәрәҗәсенә җиткерә алу – монысы аерым бер әдиплек таланты сорый. Әмма, ни кызганыч, әсәрнең эченә үтеп кереп, аны сүтеп-җыеп дигәндәй, иң әһәмиятлесе аңа лаеклы үз бәясен бирүгә теоретик һәм гамәли әзерлекле галимнәребез һәм әдәби иҗат кодрәтенә ия каләм ияләребез бармак белән санарлык. Монда, күрәсең, аларның әдәби тәнкыйть өлкәсендә бер-ике дистә ел кайнап чыгулары һәм билгеле бер танылу алулары мәҗбүрдер. Әлеге һөнәргә университетта һәм аспирантурада өйрәтмиләр. Моның өчен табигатьтән бирелгән нечкәлек, үзеңнең дә күпмедер иҗат газаплары кичерүең, эзләнүләрең, ныклы анализ тео-

риясе һәм тәҗрибә кирәктер. Ныклы теоретик әзерлегең, әдәби нечкә зәвыгың, редакторлык тәҗрибәң булмаганда бүгенге Язучылар берлеге 350 әгъзасы иҗатын ике томда ничек чагылдырып бетерергә кирәк?! Мине тагын бер борчыган нәрсә – әдәбият галимнәре арасында китап төзүчесенең вазифасын аңлап бетермәү. Бездә ул фәнни конференция җыентыкларын төзүчеләр белән бутап күзаллана. Фәнни конференцияләрдә, әйтик, йөзләп автор катнаша, аларның килгән материаллары, җыентыкның төзүчесе тарафыннан **төзелеп** түгел, ә бәлки **тезеп** бастырып чыгарыла. Шуңа ул җыентык дип атала да. Игътибар иткән булсагыз, бу мәкаләләрнең фән тармагы да, юнәлешләре дә, эшләнеш дәрәҗәләре дә, үзкыйммәтләре дә гаять төрле. Әлеге җыентыкка шушы күмәклек, шушы төрлелек, шушы чуарлык кирәк тә. Чөнки анда белгеч тә, профессор да, аспирант та бердәй хокуклы. Инде безнең томнарга килгәндә, монда хәлләр нәкъ киресенчә бит: том ул аерым бер чор үзенчәлеген чагылдырган бербөтен китап. Томга теге яки бу әдип иҗатын сайлап алу, аны дөрес чагылдыру өчен төзүче шушы йөз автор арасыннан бер хезмәтне сайлап алырга, китапның йөзен, пропорциясен җимермәс өчен аның күләмен дә, идея-фикер сөрешен дә төгәл билгеләргә тиеш. Еш кына бу йөз мәкалә арасыннан кирәкле мәкаләне тапмыйча, ул тагын да икенче, өченче бер белгечләргә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. Чөнки биредә төзүче китапның бөтен әдәби-эстетик яңгырашына, мәгънәви эчтәлегенә җаваплы кеше вазифасын башкара, әлеге автор-мәкаләләрнең үзенә күрә дирижеры – үз эшенә ул концертка кадәр түгел, ә концерттан соң җавап бирәчәк. Бездә, коллектив хезмәт дип, томга яңгыраш бирүдә берьюлы берничә дирижер эш итә башлый. Шулай итеп, Крылов мәсәленә килеп чыгабыз. Тукайга шигырьләрен язышырга, З. Бәширине димим инде, әйтик, М. Гафури, Г. Ибраһимов кебек тагын берничә классик язучыны да беркетсәк, моннан нәрсә килеп чыгар иде икән?.. Бөтен коллектив әгъзаларының да фикерен кушып эш итсәк, бу хезмәтнең иҗадилеге һәм яңалыгы ни дәрәҗәдә булыр иде?.. Кыскасы, алда әле безне тагын да авыррак тәҗрибәләр, сынаулар көтә дигән сүз.

**Әдәбият**


*Хабутдинов А.* От общины к нации: татары от средневековья к Новому времени (конец XVIII – начало XX в. Казань: Татар. кн. изд., 2008.

*Юзеев А.* Философская мысль татарского народа. Казань, 2007.



***Рахмани Равил Фәйзрахман улы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының әдәбият белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

# ВАЛИЕВА Л.Г. КАУЗАЛЬНОСТЬ В ТАТАРСКОМ ЛИТЕРАТУРНОМ ЯЗЫКЕ (Казань: ИЯЛИ, 2015. 174 с.)

Монография хәзерге лингвистика фәнендә актуаль юнәлеш – тел күренешләренең семантикасын фәлсәфи, логик, психологик аспектта анализлауга багышлана, татар әдәби телендә сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәте – каузальлек мәсьәләсен тикшерә. Мәгънәви мөнәсәбәтләрне өйрәнү, үз чиратында, телнең коммуникатив асылын ачарга мөмкинлек бирә.

Билгеле булганча, сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләре төрле өлкә (фәлсәфә, физика, тел белеме) галимнәренең зур кызыксынуын уята. Төрки телләрдә каузальлек мәсьәләсе әлегә кадәр чагыштырма планда гына тикшерелгән: О.Д. Абумова, Н.Н. Дробышева, М.Г. Сымулов, С.Ж. Тажибаева, Г.В. Хораськина, К.С. Чонбашев фәнни хезмәтләре билгеле. Татар грамматикаларында сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләренең аерым аспектларына А. Троянский, А. Казем-Бек, К. Насыйри, Җ. Вәлиди, Г. Ибраһимов, Г. Алпаров, В.Н. Хангилдин, М.З. Зәкиев игътибар итә. Л.Г. Вәлиева монографиясе лингвистикада мәгънәви-синтаксик категорияне тәшкил иткән сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләрен, татар телендә аларны белдерү чараларын җентекле тикшерү белән хәзерге чор татар тел белеме өчен зур әһәмияткә ия.

Монография өч бүлектән тора. Беренче бүлектә каузальлеккә фәлсәфи һәм тел категориясе буларак аңлатма бирелә, фәлсәфә фәне, гомуми, рус һәм төрки тел белемендә тоткан урыны, өйрәнелү тарихы анализлана. Шунысы игътибарга лаек: автор монографиянең теоретик өлешендә сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтенең функциональ-семантик кыры мәсьәләсенә аерым туктала. Икенче һәм өченче практик бүлекләрдә татар әдәби теле мисалында каузальлекнең гади һәм кушма җөмлә структурасында, аерым лексема һәм фразеологик берәмлекләрдә, керешмә һәм өстәлмәләрдә, текстта белдерүче чаралар, мәгънә төсмерләре, сәбәп һәм нәтиҗәнең позицион үзенчәлекләре, билгеле бер системага салынып, Л.Г. Вәлиева тарафыннан җентекле тикшерелә.

Монографиядә бирелгән һәм практик яктан әһәмияткә ия кушымтага тукталыйк. Фәнни хезмәт авторы тикшерү эше вакытында, куелган максат-бурычларга ирешү өчен, ягъни сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтенең татар әдәби телендә белдерелү үзенчәлекләрен, белдерү чараларын киң масштабта анализлау өчен, шактый күләмле картотека булдыра (3000 нән артык карточка), аны системалаштырып өйрәнә. Таблица формасында бирелгән статистик тикшеренүләр татар әдәби телендә каузальлекнең белдерелү үзенчәлекләрен ачык билгеләүгә хезмәт итә.

Фәнни хезмәт тел белгечләре, укытучылар, аспирантлар, магистрантлар, студентлар һәм татар теле синтаксисы мәсьәләләре белән кызыксынучыларга адреслана. Реаль чынбарлык бәйләнешләрен чагылдыручы һәм телдә лексик-синтаксик чаралар ярдәмендә белдерелүче киң колачлы универсаль категория тәшкил иткән каузальлекне комплекслы тикшерү татар тел белемендә фәнни яңалык булып тора.

***Данилова Рамилә Рафис кызы,*** *филология фәннәре кандидаты*

# ЯРУЛЛИНА Л.И. ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СУЗЫК ҺӘМ ТАРТЫК АВАЗЛАРНЫҢ (ВОКАЛИЗМ, КОНСОНАНТИЗМ) ЯЗУДА БИРЕЛЕШЕ: XIX гасыр һәм XX гасырның I чиреге (Казан, 2014. 335 б.)

Фәнни хезмәт тел белеменең үзенчәлекле өлкәләре булган фонетика, графика, орфография, тел тарихы мәсьәләләрен колачлый. Тикшеренү объекты автордан җитди әзерлек һәм тирән белем таләп итә. Монографиянең төп максаты итеп XIX–XX гасыр башында татар язма әдәби телендәге сузык һәм тартык авазларның графо-фонетик үзенчәлекләрен тикшерү билгеләнә. Куелган максатка ирешү өчен, хезмәтнең авторы билгеләнгән чорга караган грамматикалар, үзөйрәткечләр, әлифбалар, сүзлекләр һәм матур әдәбият әсәрләре телендә кулланылган фонетик берәмлекләр, аларны язуда белдерүче графемаларны анализлый.

Шунысын искәртү мөһим: тикшерү өчен алынган вакыт аралыгы – татар язу тарихында гарәп графикасы кулланылган чор. Мәгълүм булганча, гарәп язуы татар халкының иҗтимагый-сәяси, милли-мәдәни тормышында әһәмиятле тарихи вакыйгалар барган, милли үзаң һәм әдәби тел яңача үсеш алган чорда кулланыла. Моңа бәйле рәвештә, татар язу системасында булган башка язулар арасында гарәп графикасы иң бай язма мирас калдыруы белән билгеле. XIX гасыр ахыры һәм XX гасыр башы – иске төрки-татар язма әдәби теленнән яңа милли әдәби телгә күчеш этабы булганлыктан, орфографиядә бердәм язылыш нормалары, системалылык булмау белән характерлы. Бу җәһәттән хезмәт аваз-хәреф мөнәсәбәтен төрле язу системасы кулланылу шартларында тикшерү, татар милли әдәби теленең язу торышын һәм тарихын өйрәнүгә дә бик зур өлеш кертә.

Монография ике бүлектән тора. Беренче бүлек XIX гасыр һәм XX гасырның I чирегендә татар теленең вокализмын, аның язуда бирелешен өйрәнүгә багышлана. Икенче бүлектә әлеге чордагы татар теленең консонантизмы һәм аның язуда бирелеше тикшерелә. Автор проблеманың өйрәнелү тарихы буенча беренче татар грамматикаларыннан башлап XX гасырдагы торышына кадәр җентекле эзләнүләр алып бара, зур күләмдә фактик материал туплый, әлеге материалны күптөрле аспектта анализлый.

Практик яктан монографиядә бирелгән кушымталар игътибарга лаек. XIX гасыр һәм XX гасырның I чирегендә нәшер ителгән татар грамматикалары, үзөйрәткечләр, әлифбалар, сүзлекләр, матур әдәбият әсәрләре телендә сузык һәм тартык авазларны күрсәткән хәрефләрнең таблица формасында бирелүе әлеге дәвер вокализм һәм консонантизмының язуда бирелеше хакында ачык, конкрет күзаллау тудыра, статистик, чагыштырма тикшеренүләр алып бару өчен ныклы җирлек әзерли.

Әлеге хезмәттә урын алган теоретик карашлар төрки телләр грамматикасын чагыштырып анализлаганда фәнни яктан кызыксыну тудырырга мөмкин. Тикшеренү нәтиҗәләре фонетика, грамматика һәм татар әдәби теле тарихы буенча лекцияләрдә һәм практик дәресләрдә кулланыла ала. Монографиядә бирелгән бай материал студентларга, аспирантларга һәм галимнәргә кызыклы һәм файдалы булачак.

Гомумән, хезмәт татар әдәби теле формалашу, графема һәм аваз арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзенчәлекләрен билгеләү, телнең үсеш-үзгәреш закончалыкларын өйрәнү өлкәсендә төрки тел белеменә зур өлеш кертә.

***Хәбибуллина Лениза Газинур кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының лексикология һәм диалектология бүлеге фәнни хезмәткәре*

**11–22 январь көннәрендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә профессор А.К. Бустанов җитәкчелегендәге Санкт-Петербург Европа университеты магистр-тарихчылары археографик практика узды. Ислам диненең төрле аспектларын өйрәнүче студентлар Татарстан башкаласына кульъязма чыганаклар белән эшләү өчен гамәли күнекмәләр алу һәм мөселманнар тарихы буенча үзләрен кызыксындырган материаллар туплау нияте белән килгәннәр. Алар Үзәктә саклана торган кульъязма китаплар, язучылар, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренең фондлары һ.б. белән таныштылар. Эш барышында тарихчы Сәид Вахидинең (1887–1938) зур кыйммәткә ия булган фонды тулысынча электрон форматка күчерелде.

Кунаклар архив фондларындагы коллекцияләрнең байлыгына гаҗәпләнүләрен белдерде. Тарих фәннәре кандидаты Шамиль Шихалиев (Махачкала) узган гасырларда ук инде татар хатын-кызларының белем дәрәҗәсе югары булуын ассызыклады: «Сәид Вахиди фондында сакланган күпсанлы хатларны дин әһелләренең хатыннары, кызлары, сеңелләре язган. Хатларның стиле, язу рәвешләре, күбесенең шигъри формада булулары – аларның югары белемгә ия икәнлекләрен күрсәтә. Бу хатлар XVIII–XIX гасырларда татар җәмгыятендә хатын-кызларның тоткан урынын өйрәнүдә гаҗәеп чыганак ролен үти».

21 январь көнне Үзәктә практика нәтиҗәләре буенча «Түгәрәк өстәл» булып узды. Үзләрен җылы кабул итүләре, кульъязмалар белән танышырга бөтен мөмкинлекләр тудырылуы өчен кунаклар зур рәхмәтләрен җиткереп, киләчәктә дә хезмәттәшлекнең дәвам итүенә ышанычларын белдерде.

**11 январь көнне** ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов тәкъдиме белән Иннополис университеты каршында сәләтле балалар өчен мәгълүмати технологияләр лицее ачылды. Уку йортын ачу тантанасында ТР Премьер-министры урынбасары – ТР Мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, Иннополис шәһәре мэры Егор Иванов, Иннополис университеты директоры Кирилл Семенихин һ.б.лар катнашты. Э. Фәттахов сүзләренә караганда, бу – республикада сәләтле балалар өчен булдырылган 16 нчы уку йорты. Анда укырга теләк белдерүчеләрдән җәмгысе 600 гариза кабул ителгән, шуларның 105 е 7–10 нчы сыйныфларда уку өчен сайлап алынган. Лицейда республиканың сайлап алу конкурсы аша узган иң яхшы укытучылар хезмәт куячак. Моннан тыш, уку процессына Иннополис университеты профессорлары, мөгаллимнәре дә җәлеп ителәчәк. Биредә информатика, математика буенча көчле, үз тормышларын мәгълүмати технологияләр белән бәйләргә теләгән балалар белем алачак.

**14 январьга кадәр** ТР Фәннәр академиясе бинасында К.А. Тимерязев исемендәге Биология музееның (Мәскәү) «17 баш сөяге һәм теш, яки Вакыт агымында кеше үзгәреше» дигән күргәзмәсе

эшләде. Экспозиция Казан федераль университеты һәм ТР Фәннәр академиясенең А.Х. Халиков исемендәге Археология институты тарафыннан оештырылган «Генетика, этник тарих һәм антропогенез» дигән семинар кысаларында үтте. Күргәзмә соңгы 7 миллион ел эчендә кеше үсешенең төп стадияләре турында сөйли. Күргәзмә авторлары Россиянең башка бер генә музеенда да булмаган баш сөяге муляжлары коллекциясен җыйганнар.

**20–21 январь көннәрендә** Казан дәүләт медицина университеты гыйльми советының утырышлар залында Европаның әйдәп баручы трансплантологы Страсбург университеты профессоры Жильбер Массардның (Франция) лекцияләре узды. Күренекле галим беренче көнне «Үпкәдә яман шеш» дигән темага лекция укыды, эпидемиология, фаразлар, скрининг, анвазияле хирургия үзенчәлекләре турында бәян итте. Ә икенче көнне исә онкология һәм травматологиядә күкрәк читлеге хирургиясе турында сөйләде. Әлеге лекцияләр циклы ТР хөкүмәтенең «Алгарыш» гранты ярдәмендә КДМУның «Трансплантология: терапевт һәм хирург берлеге» белем бирү программасы кысаларында узды.

**2 февраль көнне** Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының коллегия утырышында Казан федераль университетының Социаль фәлсәфә фәннәре һәм массакүләм коммуникацияләр институты директоры Михаил Щелкунов журналистика бүлегенең «Югары журналистика һәм медиакоммуникацияләр мәктәбе» дип үзгәртеләчәген әйтте. «Казан университеты 50 еллык традицияләргә таянып, журналистика өчен кадрлар әзерләүгә һәрчак игътибар бирде һәм бирә. Университетта төбәкнең мәгълүмат өлкәсен тикшерү һәм Татарстанның массакүләм мәгълүмат чаралары тармагы өчен кадрлар әзерләү буенча атаклы үзәк барлыкка килде. Югары журналистика мәктәбе төзелүгә без аерым өметләр баглыйбыз, аның булган белем бирү программаларының һәм фәнни эшләнмәләренең җәлеп итүчәнлеген арттырып, республика журналистика мәктәбе имиджын көчәйтүенә өметләнәм», – дип белдерде ул.

**4 февральдә** Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов РФА Казан фәнни үзәгенең А.Е. Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институты базасындагы яңа халыкара фәнни-инновацион үзәктә булды. Шулай ук анда Фәнни оешмалар федераль агентлыгы җитәкчесе Михаил Котюков, Россия Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәге рәисе Олег Синяшин, ТР Фәннәр академиясе президенты Мәкзүм Сәлахов һ.б. катнаштылар. Бу үзәк 2014 елда А.Е. Арбузов исемендәге Органик һәм физик химия институты откан грант нәтиҗәсендә булдырылды. Ул чакта институт Россиянең иң яхшы уналты фәнни-мәгариф учреждениясе рәтенә кергән иде. РФАның Казан фәнни үзәге рәисе Олег Синяшин фикеренчә, әлеге проектның төп максаты – нейрохимия һәм фармакология буенча «Компетенцияләр үзәге» булдыру. Монда галимнәр

фундаменталь һәм гамәли дисциплинаара тикшеренүләр уздырачак. Яңа үзәктә медикаментлар булдыруның тулы инновацион циклын гамәлгә ашыру күзаллана, диде Олег Синяшин.

**8 февральдә** Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Казанда Югары медицина технологияләре мәгариф үзәгенең «Amtec Kazan» симуляцион үзәгендә булды. «Amtec Kazan» үзәге генераль директоры Леонид Галинский билгеләп үткәнчә, симуляторлар мәйданчыгы мәгариф үзәгенең икенче чираты булып тора. «Әгәр без гадәти шартларда 25 төрле белгеч әзерләсәк, хәзер тагын 6 юнәлеш буенча әзерлек алып барылачак. Без хәзер табиблар гына түгел, ә ординаторлар, интерннар һәм, хәтта, медицина вузларының өлкән курсларын да әзерләячәкбез», – дип сөйләде ул. Робот-пациентлар гастродуоденоскопия, ультратавыш һәм нурланыш диагностикасы, стоматология, реанимация, анестезиология, бронхоскопия һәм колоноскопия программалары нигезендә белгечләр әзерли алачак. Симуляцион үзәктәге җиһазларның Татарстанда җитештерелгән булуын да билгеләп үтик. «Алар характеристикалары буенча халыкара төрдәшләргә якын яки алардан калышмый», – дип ассызыклады Галинский. Хәзер мәгариф үзәгендәге укучылар саны 20 процентка артачак. Әгәр элек аның аша 3 меңгә кадәр кеше узса, хәзер бу санны 3,5–3,6 меңгә кадәр арттыру планлаштырыла. Генераль директор беренче төркемнәр туплануын билгеләп үтте.

**11 февраль көнне** Казан шәһәре «Ногай» кунакханәсенең «Тукай» конференц-залында Казан дәүләт университетының журналистика факультеты беренче деканы, педагог, бөтен гаммәви мәгълүмат чараларында эшләүче күп кенә журналистларның остазы булган Флорид Әгъзәмовны (1936–2005) искә алу кичәсе уздырылды. Анда олуг галим, журналист турындагы хатирәләргә багышланган «Үзәктә – кеше» дигән документаль фильм күрсәтелде, күпсанлы шәкертләре остазларын җылы хисләр белә искә алды.

**17–19 февраль көннәрендә** Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының ел йомгакларына багышланган чаралары узды. Әлеге чараларда ТР Фәннәр академиясе, фәнни оешмалар, ТР Дәүләт Советы, ТР Язучылар берлеге һәм матбугат вәкилләре катнашты. Россия Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең конференцияләр залында институтның 2015 елдагы фәнни эшчәнлегенә һәм Россиядә игълан ителгән Әдәбият елына нәтиҗә ясалды. ТР Фәннәр академиясенең кече залында «2014–2020 елларга ТР дәүләт телләрен һәм ТРда башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында басылып чыккан хезмәтләр һәм башкарылган проектлар тәкъдим ителде. Узган елда институтта түбәндәге хезмәтләр дөнья күрде: «Хәзерге татар теленең грамматикасы»; «Татар теленең лексикологиясе»; «Татар халык сөйләшләре сүзлеге»; «Татарстан Республикасы топонимнарының электрон картотекасы һәм

географик объект исемнәренең дәүләт каталогы»; «Татар теленең күпфункцияле палилингваль электрон лексикография фонды». Ел йомгакларына багышланган чаралар кысаларында шулай ук Г. Ибраһимовның 15 томлык академик басмасының план-проспекты хакында фикер алышынды, Г. Тукайның алты томлык академик басмасының 3–4 томнарын, рус телендәге 15 томлык халык авыз иҗаты җыелмасының 5 томын, «Татар театры» сүзлек-белешмәлеген һ.б. хезмәтләрне тәкъдим итү булды. Фәнни оешмаларның вәкилләре катнашында «Фәнни Татарстан» журналының киңәйтелгән редколлегия утырышы узды. Әлеге чараларда – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры ТР ФА хакыйкый әгъзасы К.М. Миңнуллин, ТР баш гыйльми сәркатибе, ТР ФА хакыйкый әгъзасы Д.Ф. Заһидуллина һ.б. катнашты һәм чыгыш ясады.

**24 февральдә** «Хәзинә» сынлы сәнгать галереясында Бакый Урманче исемендәге премияне тапшыру тантанасы булды. ТР Мәдәният министрлыгы тарафыннан гамәлгә кертелгән бу премия 1998 елдан бирле, ике елга бер тапкыр тапшырыла. IX тапкыр бирелүче премиягә быел 77 иҗат әһеле дәгъва кылды. «Сынлы сәнгать», «Графика», «Скульптура», «Декоратив сәнгать», «Сәнгать теориясе һәм тарихы, тәнкыйть, сәнгать белгечлеге» коминацияләрендә иҗади көч сынашучылар арасында танылган сәнгать әһелләре белән бергә яшь иҗатчылар да бар иде. Катнашучыларның географиясе дә шактый киң – Мәскәү, Пенза, Магнитогорск шәһәрләре, Оренбург өлкәсе, Пермь крае, Казакъстан, Төркмәнстан республикалары вәкилләре. «Сынлы сәнгать» номинациясендә «Из детства» триптихы өчен Александр Петров, «Графика» номинациясендә «Исторические города Татарстана» графика сериясе өчен Вера Карасёва, «Скульптура» номинациясендә «Тукай әкиятләре» сыннар композициясе өчен Рөстәм Габбасов, «Декоратив сәнгать» номинациясендә «Татар язуы тарихы» керамик панносы өчен Рөстәм Шәмсутов, «Сәнгать теориясе һәм тарихы, тәнкыйть, сәнгать белгечлеге» номинациясендә «Графический коллектив «Всадник». 1920–1924. Каталог выставки «Сметая веками насевшую пыль...» эше өчен Ольга Улемнова җиңүгә лаек булды. Җиңүчеләргә бүләкләрне ТР Мәдәният министры А.М. Сибгатуллин тапшырды.

***Мөхтәрәм авторлар!***

«Фәнни Татарстан» журналы татар теле, әдәбияты, тарихы, сәнгате һәм иҗтимагый-фәлсәфи фикере темаларын яктырткан мәкаләләрне бастырып, киң җәмәгатьчелеккә таратуны күздә тота.

Материалларга түбәндәге таләпләр куела:

Мәкалә тексты *.doc. форматында җыела, аерым хезмәтләрдән алынган өзекләр, сылтамалар автор тарафыннан җентекләп тикшерелә. Файл автор фамилиясе белән исемләнә (Әхмәтов. doc).

Мәкаләгә түбәндәге мәгълүматлар өстәлә:

— авторның фамилиясе, инициаллары

— мәкалә исеме

— аннотация (рус телендә)

— төп сүзләр (рус телендә)

— сылтамалар.

Мәкаләдән тыш, *.doc форматында аерым файлда автор турында мәгълүмат җибәрелә (исеме, этисенең исеме, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, эш урыны, вазифасы, электрон адресы һәм телефоны).

Сылтамалар текст азагында ГОСТ Р 7.0.5-2008 таләп иткәнчә алфавит тәртибендә урнаштырыла.

Мәкалә белән бергә аңа карата фән докторы яки фән кандидаты тарафыннан язылган рецензия җибәрелә.

Редакциягә килгән мәкаләләр шулай ук бәйсез рецензияләүгә тәкъдим ителә, мәкаләне басмага алу-алмау аның нәтиҗәсеннән чыгып билгеләнә.

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31, 3 нче кат, 101 нче бүлмә
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

*Уңышлар теләп һәм Сезнең белән хезмәттәшлек итүебезгә өмет баглап,*
*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе*

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**
На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**
2016. № 1

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 21.03.2016.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,25. Тираж 500. Заказ

Журнал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59, 292-71-80
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20